Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

05
май 2022
ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен рәсми кабул итүгә 1100 ел

Идел болгарларына ислам дине кайчан һәм ничек үтеп керә?

12 бит

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең Мирас 12 +

05
(341)
май 2022

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Кол Гали

ТАРИХИ МИРАС

4 Идел буе Болгар дәүләте халыкларының ислам динен рәсми кабул итүләренә 1100 ел тулу уңаеннан күренекле шәхесләребезнең мөрәҗәгатьләре

12 Идел болгарларына ислам дине кайчан һәм ничек үтеп керә? *Ф.Хуҗин*

20 Алтын Урда һәм суфыйлар. *И.Миргалиев*

24 Батырша мулла – татарның каһарман улы. *Р.Шәйхәйдаров*

32 «Күз күрде, гакыл белде...» *М.Госманов*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә

Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ильяс Җиһаншин
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Рүзәл Мөхәммәтшин
Данил Салихов
Индус Таһиров
Данис Шакиров
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм битккә салучы
Алмаз Фәйзуллин
(843) 222-09-83 (17-92)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энҗе Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-93)

SMM-белгеч
Ләйләгөл Сафина
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском и русском языках)

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

ТАТАР ГАМЕ

38 Без кем яки Бер китап тирәсендә уйланулар. *И.Таһиров*
44 Фәрит Мөхәммәтшин: «Иң мөһиме – кеше булып калу!»
49 «Безнең мирас» котлый!
50 Бүгенге имам – татарның рухи яңарыш әйдаманы. *Д.Шакиров*
52 Фәрит Бикчәнтәев: «Театр бүген бар, иртәгә ул – тарих»

ӘДӘБИ МИРАС

58 Рухи хәяттә дини әдәбият. *Р.Исламов*
62 Мизгел. *М.Галиев*
68 Әкрам Галләмов һәм аның шигырь дәфтәре. *Р.Мөбарәкшина*
70 Мөһаҗирлектәге милләттәшебезнең «Тәрҗемәи хәлем» әсәре. *Х.Миңнегулов*
73 «Тәрҗемәи хәлем». *Х.Хәмидулла*

ДИНИ МИРАС

75 Остазыбыз Исхак хәзрәт Лотфуллин. *И.Җиһаншин, З.Мингалиев*
80 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*
86 Матбугат ифтары
88 Ислам. Дини сүзлек
89 Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) хәдисләре. *Ә.Рәхими*
90 Дин дәресләре. *С.Бикбулат*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

92 Кара тәкъдир. *Р.Батулла*
94 Әдипләр һәм сәнгать әһелләре карары. *Л.Лерон*
96 Истә, һаман да истә!

СӘНГАТИ МИРАС

98 Асыл җырчыбыз. *А.Хәкимова*
103 Тарихта калган дусларны искә алып... *Н.Кәримова*
108 «Өй артында шомыртым» җыры

ТАБИГЫЙ ЯДКЯРЛӘР

110 Шомырт

СИХӘТЛЕ МИРАС

111 Шомырт дәвалый

ШАЯН МИРАС

112 Көлке куа килә...

БАЛАЧАК МИРАСЫ

114 Без барыбыз да – балачактан

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Май*

Заказ №О-1237. Тираж – 3200 данә. Формат 70x100 1/16
Басарга кул куелды: 29.04.2022. Чыгу көне: 06.05.2022.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе иркен.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә:
Болгардагы мозаик паннодан фрагмент. Анда Алмыш ханның Багдад хәлифәсе илчеләре белән очрашу тантанасы һәм бабаларыбызның рәсми рәвештә ислам динен кабул итү мизгеле тасвирланган.

Дога беләү гөнаһлылар ярлыканыр,
Ярлыкауга алар лаек булыр имди...

Кол Гали

Кол Гали. *Рәссам Тавил Хаҗиәхмәтов эше*

КОЛ ГАЛИ

(Якынча 1183-1236)

Мактау, шөкер һәм дан булсын бер Аллага,
Мөлке даим, Үзе мәңге ул мәүляга.
Мөлкәтенең эчендә юк тиңдәш Аңа, –
Аны бакый һәм бөек дип белдек имди.

***

Өмет итәм ярдәм Синнән мин зәгыйфь кол,
Теләгеңә җитә адәм, күрсәтсәң юл.
Әгәр, ярдәм бирим, дисәң, кодрәтең мул,
Бу бәндәңә бул юл күрсәтүчем имди.

***

Гәүһәр таш ул, ләкин һәр таш гәүһәр булмас,
Тикмә кеше гәүһәр кадрен аңлый алмас, –
Бу нәзымның кадерен һич ахмак белмәс, –
Гакыллылар тыңлар, аңлар, белер имди.

***

Каза килсә, күзеңне ул сукырайтыр,
Бәла килсә, күрү көче кулдан китәр.

***

Туганда кара туганны
Сабынлап юсаң, агармас.
Туганда кыек туганны
Тубыкка салсаң, тураймас.

*Текстны журналга **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

ИДЕЛ БУЕ БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕ ХАЛЫКЛАРЫНЫҢ
ИСЛАМ ДИНЕН РӘСМИ КАБУЛ ИТҮЛӘРЕНӘ 1100 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕННАН

Татарстан Республикасының Беренче Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе, Мәлик Фәйсал исемендәге Халыкара премия иясе Минтимер Шәймиев мөрәҗәгате

Идел буе Болгар дәүләтенең ислам динен ирекле һәм рәсми төстә кабул итүенә 1100 ел тулуны ил күләмендә бәйрәм итү – халкыбыз күптәннән көтеп алган тарихи вакыйга ул. Элегрәк без бу турыда хыяллана да алмадык. Моның өчен без ил җитәкчелегенә, Россия Федерациясе Президенты Владимир Путинга рәхмәтлебез. Бу – күпдинле илебез җитәкчесенең зирәк һәм тирән мәгънәгә ия карары дип саныйм. Шул ук вакытта ул – Россиянең һәм Татарстанның ислам динен тергезү һәм үстерү буенча күпьеллык уңышлы эшчәнлеге нәтиҗәсе дә. Бер яктан, без ислам дөньясы илләре белән дустанә һәм эшлекле элемтәләр булдырдык, икенче яктан – тарихи-мәдәни мирасыбызны торгызып, аның фәнни-тарихи яктан дәлилләп, хак тарихыбызның халыкара танылуына ирештек.

Иманым камил, әлеге истәлекле датаны дәүләти югарылыкка күтәрүдә, барыбыз бергәләп тотынып, борынгы Болгар шәһәрен торгызуыбыз хәлиткеч роль уйнады.

Аннары Болгар тарих-археология комплексын ЮНЕСКОның Бөтендөнья исемлегенә кертү аның бөтендөнья белгечләр бергәлеге тарафыннан «күренекле универсаль хәзинә» дип танылуын аңлата. Димәк, ата-бабаларыбызның 922 елда Болгар җирендә, хәзерге Россия биләмәсендә беренче булып, ислам динен кабул итү факты, дөньякүләм расланып, кешелек тарихына теркәп куелды.

Бу эшләребезнең күркәм чагылышы – ислам дине кабул ителгән изге Болгар җирендә әлеге истәлекле вакыйгага хөрмәтенә төзелгән зур, мәһабәт бина – Истәлек билгесе. Аның зур залына мөселманнарның изге китабын – Коръәннең дөньядагы иң зур басма үрнәген урнаштырдык. Зал диварына Багдад хәлифәсенең Ибн Фадлан җитәкчелегендәге илчелегенең Болгарга килгән юлы сызылып куелган. 922 елда Идел буе болгарларының исламны дәүләт дине итеп кабул иткән мизгелне тасвирлаган мозаик панно да эленеп тора бирелә. Болар барчасы татар халкының үз тарихын бәяләүче, саклаучы, ихтирам итүче, аның кадерен белүче үрнәк халык икәнен күрсәтеп тора. Әлеге игелекле гамәлләргә мөнәсәбәте булган һәркемгә һәм бу эшне күтәреп алган күпмилләтле халкыбызга олы рәхмәтебезне белдерәм.

ТР Дәүләт Киңәшчесе, «Яңарыш» Республика фондының Попечительләр Советы Рәисе, ЮНЕСКОның мәдәниятара диалог буенча Махсус илчесе М.Ш.Шәймиев һәм ЮНЕСКО Генераль директоры (2010-2017) Ирина Бокова. 20 август, 2014 ел

Быел ямьле май аенда, ата-бабаларыбыз мең дә бер йөз ел элек билгеләгән тарихи көндә узучы олуг бәйрәмебез Россиянең бөтен төбәкләрендә яшәүче дин кардәшләребез тормышында уңай чагылыш табар, күпмилләтле, күпдинле илебездә тынычлыкны һәм татулыкны ныгытыр дип уйлыйм.

Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы хөрмәтенә салыначак Җәмигъ мәчет исә ниятләребез ихласлыгын һәм тарихи дәвамчылыкны гәүдәләндереп торыр дип ышанабыз. ■

Русия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте рәисе, баш мөфти, шәйхел-ислам Тәлгать хәзрәт Таҗеддин мөрәҗәгате

بسم الله الرحمن الرحيم

الحمد لله وبه نستعين والصلاة والسلام على رسوله محمد و آله وأصحابه اجمعين

وعلينا وعلى عباد الله الصالحين التابعين لهم بإحسان إلى يوم الدين

Дин-мөбиндә мөхтәрәм газиз кардәшләрем, милләттәшләрем һәм кадерле ватандашларым!

Җөмләгезгә Аллаһ Раббыбызның бетмәс рәхмәт һәм бәрәкәтләрен, ике дөнья бәхет-сәгадәтләрен теләп сәламлим:

السلام عليكم ورحمة الله وبركاته

Яңадан «Изге Болгар шөкер җыены»на ашкына-ашкына әзерләнәбез. Бу ел дәүләтебез – Русия Президенты В.В.Путин карары буенча шәһри Болгарда гына түгел, бәлки, бөтен илебез төбәкләрендә Идел буе дәүләтендә ислам динен рәсми кабул итүнең 1100 еллык юбилеена багышланган зур бәйрәм тантаналары, халыкара җыелыш һәм чаралар үткәреләчәк. Илебезнең бөтен якларыннан, күрше ил һәм гарәп-ислам илләреннән кадерле кунакларны, дусларыбызны көтәбез.

Дөнья кайный, сынаулар олы, ләкин, шиксез, без – иманлы бәндәләр, пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.): «Бәндә чамалый – Аллаһ Үзе тәкъдир итә», – дигән сүзен

хәтерләп, яшәү дәвамына олы өмет белән бәйрәм итәбез. Бөтен илебез халыкларына бердәмлектә, татулыкта, тынычлык-иминлектә, шулай ук киләчәк буыннарга, балаларыбызга һәм оныкларыбызга да иман нуры илә ямьле тормышлар, дөнья-ахирәт бәхетләрен Аллаһ Раббыбыз насыйп итсә иде дип өмет итәбез.

1989 елдан бирле һәр ел Изге Болгарда җыелып, тәүбәләр итеп, борынгы бабаларыбызга хәер-догалар кылабыз. Һәр авыл һәм шәһәрләребездә яңа мәчет биналары, мәдрәсәләр, әлхәмдүлилләһ, төзелә. 33 ел үтеп, Болгар илендә яңадан олы бәйрәм мөбарәк булсын! Куанырлыгыбыз да бар, Аллаһка шөкер. Мәһабәт Ак мәчет һәм яңартылган тарихи ядкярлекләр, төзек юллар, музей, яңа елга порты соклангыч!

Боларның һәммәсендә дә халкыбызның диненә – исламга һәм туган илебезгә, аның тарихына булган ихлас мәхәббәте чагыла. Һичшиксез, моңа җитәкчелек итеп, тарихыбызда күренерлек олы эз калдыручы мөхтәрәм затлар – Татарстан Җөмһүриятенең Беренче Президенты, кадерле аксакалыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиев һәм вафалы шәкерте, эшлекле варисы – Татарстан Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов. Шуның белән бергә, аларның тырышлык һәм гайрәте белән бу изге эштә катнашкан меңнәрчә милләттәшләребез, эшкуарлар, бөтен халык кушылып, иман нуры күңел һәм йөзләрдә балкып, яшәү кадерен, туган ил кадерен тануга сәбәп булды.

«Кешеләргә, кылган хезмәт һәм яхшылыкларына шөкер һәм рәхмәтен әйтә алмаган – Аллаһка да шөкерен кыла алмас», – ди Рәсүле Әкрам (с.г.в.)

Бу изге хезмәтләрне оештырып, җан-күңелләребезгә кадерле булган туган илгә мәхәббәт, рухи кыйммәтләребезнең, тарих һәм мәдәниятебезнең әһәмиятенә игътибар уятучы мөхтәрәм затларыбызга, олы дәүләт, чиксез илебездә татулык һәм кардәшлектә, бердәм булып яшәвебезгә олы өлеш кертүче «Мирас» фонды һәм анда хезмәт итүчеләргә, фикере һәм хәленнән килгәнчә матди ярдәм күрсәтүчеләргә дә Раббыбыз Аллаһ сәламәтлектә, иминлектә, куаныч-шатлыкта бу бәйрәмнәрдә дә катнашырга насыйп итсә иде!

Әлхәмдүлилләһ! Бу – тарихи вакыйга, аның диннәр, халыклар арасындагы мөнәсәбәтләрне саклау буенча мөһимлеге бәхәссез. Шәһри Болгарның кадерен белеп, кайда гына булсак та, Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) чын өммәте булып гомер итүебезне, бөтен халыкларга, иң әүвәл балаларыбыз һәм оныкларыбызга изге үрнәк булып яшәүләребезне Аллаһ Раббүл-Гыйззә насыйп әйләсә иде! ■

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин мөрәҗәгате

Бисмилләәһиир-рахмәәниир-рәхиим.
Хөрмәтле дин кардәшләрем!
Газиз милләттәшләрем!
Әссәламү галәйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү!

922 елда Идел Буе Болгар дәүләтендә рәсми рәвештә ислам дине кабул ителә. Быел әлеге бөек тарихи датага 1100 ел тулды.

Динебездә иман шартларының берсе булып Аллаһының тәкъдиренә ышану тора. Һәр адәм баласы үз тәкъдире белән туа: Яралтучыбыз аңа Үзе язган язмышны һәм ризыкны бирә, ләкин гамәлләрдә һәм эшләрдә сайлау мөмкинлегенә дә ия итә. Шуңа күрә Кыямәт көнендә безнең һәркайсыбыз

сайлап алган һәр адымыбыз өчен җавап бирәчәк. 922 елда безнең халкыбыз да, дәүләт дине буларак исламны сайлап, үзенең язмышында иң мөһим карарын кабул итә. Ирекле, аңлы, ихтыярый карар була ул... Халкыбызның күпгасырлык тарихында иң дөрес карар! Шулай итеп, Аллаһы Тәгалә болгар бабаларыбызны һәм безне, татарларны, Үзенең иң бөек рәхмәтенә – сөекле рәсүлебезнең, кешелеккә җибәрелгән иң соңгы пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) өммәтеннән булу бәхетенә ирештерде.

Газиз милләттәшләрем! Аллаһы Тәгалә ни өчен безнең бабаларыбызны шушы мул җирләрдә, күптөрле диннәр, халыклар һәм дәүләтләр арасында урнаштырган һәм гарәп илчелегенең Болгарга кадәр ерак сәфәрләренә ни өчен юлларны ачкан икән? Хактыр ки, татарлар, болгарларның дәвамчылары, мөселман булсыннар һәм ислам диненә хезмәт итсеннәр өчен!

Ислам татарларга бай рухи мәдәният, мәгърифәт, Аллаһы Тәгаләнең изге әмерләренә нигезләнгән югары әхлак бирә. Күп гасырлар дәвамында динебез безгә тынычлыкта хезмәт итәргә һәм сугышларда Ватаныбызны сакларга ярдәм итә, кайгыда юаныч була, иманның татлылыгын тоярга насыйп итә, илһамландыра... Һичшиксез, авыр сынаулар вакытында да ислам татарларга милләт буларак сакланырга көч бирә. Әлегә кадәр без шушы какшамас нигездә басып торабыз, иман исә киләчәгебезне якты маяк булып яктыртып тора.

Идел буе Болгар дәүләтендә исламны кабул итүнең 1100 еллыгын каршылап, мин Раббыбыздан бөтен Россияне Үзенең чиксез Рәхмәте белән бүләкләвен, Ватаныбыз Татарстанга чәчәк атып үсүен һәм аның һәр гаиләсенә иминлек бирүен сорыйм. Хәерле һәм игелекле эшләрдә ниятләребез нык булсын! ■

Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти, шәех Равил хәзрәт Гайнетдин мөрәҗәгате

Мөхтәрәм дин кардәшләрем! Кадерле ватандашлар! Хөрмәтле милләттәшләрем!

Менә без Россия һәм халыкара күләмдә мөселманнар өчен тарихи, истәлекле ел буларак 2022 елда Бөек Идел буе Болгар дәүләте халыкларының ислам динен рәсми кабул итүләренә 1100 ел тулуны бәйрәм итәбез.

Милади ел хисабы буенча 11 гасыр элек Европа дәүләтләренең иң зурларыннан берсе булган Идел буе Болгар дәүләте үз илен һәм халкын Ислам дөньясының бер өлеше итеп таныта! Болгар дәүләте халкы Бер Аллаһка иман китереп, ислам һидаятенә ирешүләре һәм Коръән Кәрим, һәм Аллаһның хак илчесе Мөхәммәд (с.г.в.) сөннәтенә ияреп яшәргә ант бирүләрен игълан итә.

Идел буе Болгар иле инде сигез гасыр сәяси берәмлек буларак юкка чыкса да, без – 922 елда һәм аннан да иртәрәк исламны кабул иткән ата-бабаларыбызның дәвамчылары, Аллаһның чакыруына һәм Пәйгамбәребез (с.г.в.) юлына тугрылыкны саклап яшибез. Без тарихи хәтерне саклыйбыз, ата-бабаларыбызны һәм гасырлар дәвамына сузылырлык дан һәм тарихны, аларның Аллаһ ризалыгы һәм халык өчен кылган хезмәтләрен олылыйбыз.

11 гасыр, – әлбәттә, зур тарих, гаять күп вакыт. Бу – безгә тирән уйланырга бер сәбәп. Бүген без, кеше кабул иткән бер карарның әһәмияте үз тормышына гына кагылмыйча, һәр гамәле, һәр нияте, әйткән сүзе, һәрбер эше гасырларга уелып калуын аңлыйбыз.

Коръән Кәримдә Аллаһы Тәгалә:

فَمَن يَعْمَلْ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ خَيْرًا يَرَهُ

وَمَن يَعْمَلْ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ شَرًّا يَرَهُ

«Кем дә кем тузан бөртеге авырлыгы кадәр генә игелек кыла, аны күрәчәк. Кем дә кем тузан бөртеге авырлыгы кадәр генә начарлык эшләсә, аны күрәчәк», – ди («Әз-Зәлзәлә» сүрәсе, 7-8 аять).

Мөселман халыклары, 1100 ел дәвамында исламның әхлакый кануннары нигезендә иманнарын һәм гореф-гадәтләрен саклап, ватанпәрвәрлек белән аны илбасарлардан яклап, тугры юллары булган. Алар безгә бөек җиңүләр, архитектура һәйкәлләре, әдәби һәм фәнни хезмәтләр, сәнгать әсәрләрен мирас итеп калдырган; батырлык, намус, гаделлек төшенчәләрен тапшырган. Иң мөһиме – тарихи чорлар һәм фаҗигале көннәр аша алар мөкаддәс ислам динебезне күз карасыдай саклап, бүгенге көнгә кадәр җиткергәннәр.

Бүген без моннан 1100 ел элек безгә карата мәрхәмәт күрсәтеп, иман һәм хакыйкатьне тануны бүләк иткән, җир йөзендә мөселман булып яшәү дәрәҗәсен биргән, төрле дин, халык вәкилләренә төрле карашлы бар ватандашларыбыз белән үзара хөрмәт хисе һәм татулыкта яшәүне боерган Аллаһы Тәгаләгә шөкер кылабыз.

Ихлас күңелдән дәүләтебез башлыгы Владимир Владимирович Путинга, Идел буе Болгар дәүләте халыкларының ислам динен рәсми кабул итүләренә 1100 еллыкны олы бәйрәм итеп уздырыйк дигән тәкъдимебезне хуплавы өчен, рәхмәтебезне җиткерәбез. Бөек юбилеебыз Россия халыкларына бер-берсен таныргa, алар арасында аңлашу, хөрмәт һәм ярату хисләренең ныгуына булышыр дип ышанабыз.

Без бөек Ватаныбызның һәртөрле халык һәм дини оешма вәкилләрен бәйрәмебез шатлыгын уртаклашырга, тантаналарга кушылырга чакырабыз.

Кадерле дин кардәшләрем, хөрмәтле ватандашлар! Сезне Идел буе Болгар дәүләте халыкларының ислам динен рәсми кабул итүләренә 1100 ел тулу бәйрәме белән чын күңелдән котлыйм! Бөтен Россия халкына иманнарына тугры булып, гореф-гадәтләрне саклау һәм яңарту, акыл белән рухны үстерү, мең елдан артык тарихка катнашканлыкны, бердәм һәм бергәлекне аңлауларын телим.

Ихлас калебтән Раббыбыз Аллаһы Тәгаләдән илкөннәребезгә тынычлык-иминлек, үзебез һәм якыннарыбызга, гаилә һәм халыкларыбызга, туган җиребез – Бөек Ватаныбызга уңыш, үсеш һәм бәхет насыйп итүен теләп, иң изге теләктә һәм догада калам!

Ислам динебезнең Бөек Болгар дәүләтендә рәсми дин итеп кабул ителүенең 1100 еллык юбилее хәерле һәм мөбарәк булсын, амин йа Раббил Галәмин. ■

Идел болгарларына ислам дине кайчан һәм ничек үтеп керә?

Фаяз Хуҗин

Борынгы болгар бабаларыбызда ислам диненең таралу тарихын өйрәнү өчен тарихчылар кулында берничә төрле чыганак бар.

Көмеш догалык. 1869 елда Спас өязендә табылган.

Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.) хикмәтле таягы

Аларның беренчесе *халык авыз иҗаты* әсәрләренә карый. Идел буе Болгарында ислам динен кабул итүне Пәйгамбәребез (с.г.в.) сәхабәләре белән бәйләүче сюжет татар фольклорында еш очрый.

Риваятьләрнең берсендә, легендар Айдар хан идарәсе вакытында Болгар җиренә Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) сәхабәләре – Зөбәир бине Талкә, Зөбәир бине Җәдга һәм Габдерахман килеп киткәннәр, дип сөйләнә. Ерак якларга китәр алдыннан Пәйгамбәребез (с.г.в.) аларга, башыннан салып, үзенең чалмасын, таягын һәм кара савытын тапшыра, имеш. Бу сәхабәләр Айдар ханның ислам динен кабул итүендә хәлиткеч роль уйнаганнар булып чыга.

...Ул вакытта Айдар ханның Туйбикә исемле егерме яшьлек кызы озак вакытлар инде беркем дә дәвалый алмый торган начар авырудан интеккән, имеш. Сәхабәләр, ханга ярдәм итәргә теләп, кызны авыруыннан ничек коткарырга кирәклеген беләбез, дип мөрәҗәгать итәләр. Ханның ризалыгын алгач, алар Мөхәммәд (с.г.в.) бүләк иткән таякны җиргә кадап куялар. Габдерахман дога кылганнан соң, бу урында су пәйда була, ә аннары күз алдында ук каен агачы үсеп чыга. Каен ботакларыннан себерке җыялар һәм бу себерке белән авыру кызны мунчага алып барып чабалар. Туйбикә тиздән тулысынча терелеп бетә. Могҗиза өчен рәхмәт йөзеннән Айдар хан үз кызын Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) бер сәхабәсенә – Коръәнне яттан белүче Зөбәир бине Талкәгә кияүгә бирә. Алар егерме биш ел бергә яшиләр. Зөбәир бине Талкә, вафатыннан соң, Болгар шәһәрендәге Кече манара янында барлыкка килгән Изгеләр зиратына җирләнә, имеш. Сүз уңаеннан: нәкъ менә шушы урында соңгы елларда сәхабәләр истәлегенә багышланган таш стела куелды, элекке урыныннан күчерелеп, «Габдерахман коесы» яңартылды. Димәк, риваять яшәвен дәвам итә әле.

Күрәсең, шуңа охшаш риваятьләрне күз алдында тотып, XVI-XVII гасырларда яшәгән төрек язучысы Чокрыкчызадә үзенең «Алты бармак» исемле китабында Азов буе болгарларының Фарух бине Гамру Хизами исемле ниндидер легендар хакимнең ислам диненә табынуы турында хикәят урнаштырган. Аның яңа динне кабул итүе 629 елга ук карый, имеш. Кайбер галимнәребез, мәсәлән, профессор Г.Дәүләтшин бу хәбәрнең реаль нигезе булырга мөмкин дип саный.

Әмма Болгар илендә ислам дине таралу пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) заманында ук башлана дигән фикер объектив чыганаклар белән расланмый. 630-660 нчы еллар тирәсендә, ягъни Кубрат хан идарә иткән чорда Бөек Болгар дәүләтенең халкы ислам динен тотмаган. Алардан соң калган зиратларда бары тик мәҗүси йолалар буенча күмелгән кеше сөякләре генә табыла. VII гасырның 60 нчы елларында Кубрат хан дәүләте таркалганнан соң, Урта Иделгә күчеп килүчеләрнең беренче дулкыны булып саналган болгарлар да үлгән кешеләрне мәҗүсиләр йоласы буенча җирләгәннәр.

Тагын бер риваять. Аны 1135 һәм 1150 нче елларда Болгар иленә сәяхәт кылган Андалусия (Көньяк Испания) гарәбе Әбү Хәмид әл-Гарнати болгар казые Йакуб ибн Ногманның «Болгар тарихы» исемле кулъязма китабыннан күчереп алган. Анда болай диелә: *«Галим кеше аларда беләр дип атала, шуңа күрә илне дә «Беләр» (Биләр. – Ф.Х.) дип атаганнар, аның мәгънәсе – «галим кеше».* Бу сүзне гарәпләштергәннәр дә, «Болгар» дип әйтә башлаганнар. Эш шунда ки, берзаман аларга мөселман сәүдәгәрләре төркеменнән, Бохарадан бер кеше килә, ә ул тыйб гыйлемен (медицинаны) яхшы белүче дин әһеле, факих була. Болгар патшасының хатыны, патша үзе дә дәвалап булмаслык куркыныч авыру белән авырып китәләр. Аларны үзләрендә кабул ителгән төрле дарулар белән дәвалап карыйлар, ләкин авырулары һаман көчәя генә бара, инде үләрләр дип курка башлыйлар хәтта. Һәм шулвакыт теге Бохара мөселманы әйтә: «Әгәр дә мин сезне дәвалый башласам һәм сез терелсәгез, минем динемне кабул итәрсезме?» Икесе дә: «Әйе», – дип җавап бирәләр. Ул аларны дәвалый, алар, терелеп, ислам динен кабул итәләр һәм ислам динен илнең барча халкы кабул итә».

Бу риваять дөреслеккә якынрак тора: ни генә булмасын, болгарлар яңа динне Багдад шигыйларыннан түгел, Урта Азия хәнәфиләреннән кабул иткәннәр. Риваятьтә сөйләнелә торган вакыйгаларның Алмыш хан заманына кадәрге чорга караганлыгы да шик тудырмый.

Язма чыганаклар: «Болгарларның күпчелеге ислам динендә»

Ышанычлы *язма чыганаклар* аз, әмма ул чыганакларда безне кызыксындыра торган сорауларга якынча булса да җавап бирерлек кыйммәтле мәгълүмат тупланган. Тарих фәнендә расланган факт: Мөхәммәд (с.г.в.) исән вакытта уңышлы гына башланып киткән яңа дин тарату кампаниясе, аның вафатыннан соң, Гарәбстан ярымутравыннан читкә чыга. Йөз ел дәвамында, дөрес, бераз «тәнәфесләр» белән, көнбатышта Испания, Марокко һәм Мавританиядән башлап, көнчыгышта Пакыстан, Һиндстан һәм Бангладешка кадәр сузылган, төньякта исә Урта, Кара, Каспий һәм Арал диңгезләре, көньякта Африка Сахарасы һәм Һинд океаны диңгезләре белән чикләнгән зур биләмәләр һәм шул җирләрдә яши торган халыклар Багдад хәлифәте хакимияте астына эләгәләр.

VII гасыр урталарында ук исламның Көнчыгыш Европага, хәзерге Россия җирләренә үтеп керүе башлана. Дагыстан территориясендә Халифәтнең төп көндәше – Хәзәр каһанлыгы. Гарәп-Хәзәр сугышлары йөз елга якын дәвам итә (642-737). Бу сугышлар тарихы әл-Балазури, әл-Йакуби, әт-Табари, әл-Куфи, Ибн әл-Асир кебек гарәп һәм фарсы тарихчыларының хезмәтләрендә бәян ителә. Билгеле булганча, 737 елда Хәзәр дәүләте җиңелә, полководец һәм булачак хәлиф Мәрван ибн Мөхәммәд хәзәрләр белән солых килешүе төзи. Шартнамә буенча Хәзәр каһаны, аның яраннары һәм кул астындагы халыклар, шул исәптән болгарларның да бер өлеше җиңүчеләр динен кабул итәргә мәҗбүр ителәләр. Шулай да галимнәрнең күбесе, бу чорда исламның таралу даирәсе каһан һәм аның якыннары белән генә чикләнгән, болгарлар үзләренең традицион тәңречелек карашларыннан ваз кичмәгәннәр дигән фикерне алга сөрәләр. Әмма тарихта шунысы да билгеле: IX гасыр башларында Хәзәр каһаны Обадия яһүдиләр динен кабул иткәч, аның бу гамәле белән килешмәгән болгарлар баш күтәрәләр, илдә чуалышлар башлана. Баш күтәрүчеләрнең бер өлеше – ислам динен тотучылар Урта Иделгә күчеп китәргә мәҗбүр була.

Безнең кулда тагын бер кызыклы чыганак – 903-912 нче елларда танылган фарсы географы һәм тарихчысы Ибн Рөстә тарафыннан язылган «Әл-алак ән-Нәфисә» («Кадерле кыйммәтләр») дигән зур энциклопедик хезмәтнең җиденче томында теркәлгән хәбәр. Игътибарыбызны мондый юллар җәлеп итә: *«Болгарларның күпчелеге ислам динен тота, авылларында мәчетләре һәм имамнары-мөәзиннәре белән башлангыч мәктәпләр бар <...> Аларның киемнәре мөселманнарныкына охшаган, зиратлары да мөселманнарныкы кебек».* Академик И.Ю.Крачковский Ибн Рөстәнең бу хезмәте 903-912 нче елларда язылган дип исбат итте. Соңгы елларда, ул 922 ел вакыйгаларыннан соң язылмадымы икән, дип уйлаучылар бар. Шулай булган очракта да, Болгар мөселманнары турында мәгълүмат Ибн Рөстәнең китап язу чорында гына барлыкка килмәгәндер дип уйларга кирәк. Бу мәгълүматлар, И.Ю.Крачковский язганча, һичшиксез, IX гасыр азагы чынбарлыгын чагылдыра.

Исегезгә төшерәбез: әле XIX гасырның 80 нче елларында ук танылган дин галиме һәм тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани болгарларны Алмыш хан (Җәгъфәр ибн Абдаллаһ) заманында түгел, ә Габбаси хәлифәләре Әл-Мәʼмүн (813-833) һәм Әл-Васыйк (842-847) идарәсе чорында, ягъни IX гасырның беренче яртысында ук исламлаштыра башлыйлар, дип язып чыккан иде. Шушы ук фикерне соңыннан, әле Советлар хакимияте чорында ук, күренекле археолог һәм тарихчы профессор Альфред Халиков яклап чыкты. Ул үзенең хезмәтләрендә хәлиф Мәʼмүн заманында

Биләрдә Җәмигъ мәчет нигезе

Хәзәр каһанлыгы белән инде VIII гасырда ук мөселманлашкан Урта Азия арасында тыгыз хәрби-сәяси һәм сәүдә-икътисади элемтәләр урнашкан булуына басым ясады. Хәзәр дәүләтендә яшәгән болгарларга ислам дине нәкъ менә Урта Азиядән, төгәлрәге, Хәрәзем өлкәсеннән үтеп кергән булырга тиеш дип фаразлый әлеге галим.

Археологлар нәрсә ди?

Чыганакларыбызның өченче төркеме – *археология һәм нумизматика материаллары*. 1956 елда Бөек Новгородның Нерев дип аталган бер өлешендә археологик казу эшләре алып барганда Шәрык илләреннән китерелгән көмеш тәңкәләр хәзинәсе табыла. Хәзинәдәге тәңкәләр арасыннан бер ягына Җәгъфәр бине Абдаллаһ исеме язылган дирһәм галимнәрнең игътибарын җәлеп итә. Ул елларда шәрык нумизматикасы белән актив шөгыльләнүче Мәскәү дәүләт тарих музее гыйльми хезмәткәре Светлана Алексеевна Янина Җәгъфәр бине Абдаллаһ – Идел буе Болгары хакиме Алмыш ханның мөселманча исеме, ә тәңкәнең исә дирһәмнең кире ягында күрсәтелгән Аббас хәлифәсе әл-Муктафи (902-908) идарә иткән чорда сугылган булуын кире какмаслык дәлилләр белән исбатлады. Димәк, илтабар Алмыш тарихи 922 елга кадәр егерме ел элек үк инде ислам динендә булган икән. Светлана Янинаның бу ачышын бүгенге нумизматлар да инкяр итми, чөнки ул яңадан-яңа табышлар белән раслана тора.

Археологларның ачышлары исә болгарларның Хәзәр каһанлыгында яшәү чорына, ягъни тагын да борынгырак чорга карый. Каһанлык халкының шактый өлеше, чыннан да, ислам динен тоткан дигән фикерне Дон елгасы бассейнында ачылган IX гасыр мөселман зиратларын казып тикшергән археологлар 1980 нче елларда рас-

лады. Мөселман каберлекләренең датасын ачыклау җиңел түгел, чөнки мәетләрне бит киендереп күммәгәннәр, каберләрдә, мәҗүсилек чорындагы кебек, даталары төгәл билгеле бизәнү әйберләре дә, эш һәм сугыш кораллары да юк. Элегрәк археологлар мондый каберләрне Алтын Урда чорыныкы дип уйлыйлар иде. Стратиграфик күзәтүләр – кайбер каберләрнең X-XI гасыр корылмалары белән җимертелгән булуын – мондый зиратларның IX (VIII?) гасырда барлыкка килүен исбатладылар. Хәзерге вакытта Хәзәр каһанлыгы территориясендә, нигездә, Азов буйларында, ягъни соңрак Урта Иделгә күчеп утырган болгарлар тупланган урыннарда дистәгә якын мөселман каберлекләре турында мәгълүматлар бар.

Хәзәр илендә мөселман сәүдәгәрләре, һөнәрчеләр, Урта Азиянең төрле өлкәләреннән килгән башка төркем вәкилләре күп була. Аларның археологик эзләре Урта Азия шәһәрләрендә сугылган тәңкәләр, тандыр тибындагы мичләре булган торак урыннар, керамик эшләнмәләр, башка әйберләр рәвешендә сакланып калганнар. Хәзәрләрнең шул чордагы башкаласы Итилдә, гарәп тарихчысы Ибн Хәүкәл язмаларына караганда, утызга якын мәхәллә мәчете булган, шәһәрнең үзәк мәйданында биек манаралы Җәмигъ мәчете балкып торган.

Археологлар тарафыннан расланган тагын бер фактны исәпкә алырга кирәк: Идел буе Болгарына хәлифә Мөкътәдир илчелеге килгәнче үк Урта Азия сәүдәгәрләре Болгар базарларында сәүдә иткән, алар белән һөнәрчеләр дә, ислам дине вәгазьчеләре дә килгән. Нәтиҗәдә, Болгар дәүләте мәдәни яктан, академик Ю.В.Готье язганча (әлбәттә, бераз арттырып, әмма асылда дөрес), «Шәрыкның чын колониясе»нә әверелә башлый. Бу исә болгарларның ислам диненә күчү процессын җиңеләйтә генә.

Борынгы болгар бабаларыбызның 922 елга кадәр исламга омтылып үткән юллары шулардан тора.

Татар тарихында 922 ел вакыйгалары нидән гыйбарәт?

Идел Болгары дәүләт буларак IX гасыр ахырларында-X гасыр башларында формалаша. Биредә башлыча төрки телле болгар, сувар, барсил (берсула), бәрәнҗәр, искил һәм күрше фин-угыр кабиләләре – башлыча мәҗүсиләр һәм мөселманнар яши. Болгар патшасының хыялы шул кабиләләрне, алар белән идарә итүне җиңелләштерү өчен, бер халык итеп туплау һәм үз дәүләтен халыкара күләмдә таныту була. Моның иң кулай юлы илдә күп аллалы мәҗүсилекне бетереп, ислам динен рәсми рәвештә кабул итү икәнен Җәгъфәр бине Абдаллаһ (Алмыш) яхшы аңлый. Һәм ул, шул максаттан чыгып, 921 елда Багдад хәлифәсе Мөкътәдиргә хат белән мөрәҗәгать итә. Хатында ул хәлифәдән болгарларны дингә өйрәтүче, ислам диненең кануннарын аңлатып бирүче факихлар, алар өчен мәчет төзеп бирүче осталар җибәрүен сорый, дошман патшалардан саклану өчен кальга (крепость) салуда ярдәм итүен үтенә.

Багдад хәлифәсе ризалыгын бирә, һәм шул ук 921 елның 21 июнендә Багдадтан ерак Болгарга зур гына илчелек чыгып китә. Багдад илчелегенең җитәкчесе итеп Сәүсән ар-Расси, сәркатибе итеп, «хәлифәнең Болгар патшасына язган хатын уку, аңа бүләк итеп җибәрелгән әйберләрне тапшыру һәм мөселман хокукы белгечләре, укытучылар өстеннән күзәтчелек итеп тору өчен», Әхмәд ибн Фадлан билгеләнә. Ул юлда күргән нәрсәләрне, Болгардагы очрашуларны – барысын да түкми-чәчми үзенең көндәлегенә теркәп бара.

Болгар иленә алар 922 елның 17 май көнендә килеп җитәләр. Хәзер сүзне Ибн Фадланга бирик:

«Хәлифәнең хатын укыганны ишетсеннәр өчен, ул, Болгар патшасы, үз иленең

патшаларын (кабилә башлыкларын, бәкләрен. – Ф.Х.), гаскәр башлыкларын һәм хөрмәткә лаек башка кешеләрен җыйганчы, без үзебез өчен корылган чатырларда якшәмбе, дүшәмбе, сишәмбе һәм чәршәмбе көннәрдә (торып) калдык. Пәнҗешәмбе көне килеп җиткәч (922 елның 21 мае. – Ф.Х.) һәм алар җыелгач, без үзебез белән алган ике чигелгән байракны җәеп җибәрдек, аны, Болгар патшасын, кара киемнәргә киендердек һәм чалма кидердек. Мин хәлифәнең хатын чыгардым һәм аңа: «Хат укыганда утырып тору рөхсәт ителми», – дидем. Һәм ул аякларына торып басты, үз дәүләтенең шунда булган күренекле, хөрмәткә лаек кешеләре дә торып бастылар. Мин укый башладым һәм хатның башын укыдым. Һәм: «Сиңа тынычлык булсын! Һәм, чыннан да, мин сиңа (мөрәҗәгать итеп) Аллаһыны данлыйм, Аннан башка бөтән бөек көч юк», – дигән сүзләргә җиткәч, мин: «Мөселманнарның хөкемдарына тынычлык теләп җавап бир!» – дидем. Һәм ул җавап бирде, шунда булган кешеләр дә барысы бергәләп җавап бирделәр. Без хатны укып бетергәч, алар: «Аллаһу әкбәр!» – сүзен кычкырып әйттеләр. Җир яңгырап торды.

Аннан соң мин вәзир Хәмид ибн әл-Габбасның хатын укыдым, Болгар патшасы бу вакытта басып торды. Аннан соң мин аңа утырырга куштым һәм ул Нәзир әл-Харәминең хатын укыганда утырып торды. Хат укуны тәмамлагач, аның, Болгар патшасының, иярченнәре аңа күп итеп дирһәмнәр чәчтеләр. Аннан соң мин хуш исле нәрсәләрдән аның һәм аның хатыны өчен тәгаенләнгән киемнәрдән, энҗеләрдән торган бүләкләрне чыгардым. Аннан соң мин аның хатынын кешеләр барында бүләкләдем, ә ул аның (Болгар патшасы) белән янәшә утыра иде. Һәм бу – аларның йоласы һәм аларның гадәте. Һәм мин аны бүләкләгәндә хатын-кызлар аңа дирһәмнәр чәчтеләр, һәм без чыгып киттек».

Шуның белән Багдад илчелеге алдына куелган төп бурыч үтәлә: Болгар Ислам дөньясының иң төньягында урнашкан дәүләт буларак рәсми рәвештә танылa.

21 май тантаналарыннан соң илчелек вәкилләренә Болгар иле, аның табигате, халкы белән киңрәк танышу өчен мөмкинлекләр тудырыла. Ибн Фадлан язмаларында болгарларның гореф-гадәтләре, төрле йолалары турында кызыклы мәгълүматлар табарга була: *«Мин аларның этләр улавын яхшыга юраганнарын күрдем, алар моңа бик шатланалар һәм муллык, бәхет һәм иминлек елы киләчәге турында сөйлиләр... Әгәр дә алар берәр кешедә акыл, белем һәм эшлеклелек сыйфатлары күрсәләр, ул безнең Тәңребезгә хезмәт итәргә лаек дип, аны тоталар да муенына бау салалар һәм җил-кояш астында кисәкләргә таралып беткәнчегә кадәр агачка асып куялар... Ирләр һәм хатыннар елгага юынырга төшәләр һәм шәрә килеш бергә юыналар, бер-берсеннән яшеренмиләр һәм һичбер хәлдә дә зина кылмыйлар...»*

Әхмәд ибн Фадланның шәхсән үзе тарафыннан бәрәнҗәрләр кабиләсеннән Талут атлы бары тик бер кешене мөселман диненә күндерүе (сүз уңаеннан: бу кабилә кешеләренең инде агач бүрәнәләрдән салынган мәчете дә була); Җәгъфәр ханның: *«Минем сүздән чыккан кешене кылычтан үткәрәчәкмен»,* – дигән сүзләреннән соң мөселманлыкка күчкән Сувар бәге; Болгар патшасының Хәзәр каһаныннан бәйлелектә, улы һәм кызының тоткынлыкта торуы турындагы хәбәрләре тарихчы галимнәр өчен кыйммәтле документаль чыганак булып торалар. Коръәнне, ислам хокукы (шәригать) кануннарын тирәнтен белгән Ибн Фадлан, болгарларда әле мәҗүсилек заманыннан ук калган мирас бүлешү тәртибен өйрәнгәннән соң («болгарлардан берәр кеше вафат булса, аның варисы булып уллары түгел, ә ир туганы кала»), аларга мирасның нәрсә икәнлеген аңлата һәм аның, ислам кануннары буенча, улларына күчәргә тиешлеген дәлилли.

Биләрдә иң борынгы Җәмигъ мәчет. ***С.Айдаров реконструкциясе***

Илчелек әгъзалары имамнарга һәм мөәзиннәргә ислам диненең кайбер катлаулы нигезләрен аңлатырга, җәйге көн кыскалыгы аркасында килеп чыккан намаз вакыты белән бәйле бәхәсләрне чишәргә дә ярдәм итәләр.

Ибн Фадлан китабында Болгар дәүләте белән күрше халыклар арасында урнашкан сәүдә мөнәсәбәтләре турында да бай мәгълүмат табарга мөмкин.

Идел болгарлары мәдәниятле халык булган

Идел Болгарында ислам дине кабул ителү ил һәм халык тормышында җитди үзгәрешләргә китерә. Болгар иле, урта гасырлар цивилизациясенең иң атаклы һәм бай бер өлеше сыйфатында, гарәп-фарсы географларының, урыс елъязмачыларының, Европа сәяхәтчеләренең һәм сәүдәгәрләренең игътибар үзәгендә тора. Бу бик яхшы аңлашыла, чөнки иң төньякта урнашкан мөселман дәүләте тиз арада халыкара сәүдә үзәге буларак танылa башлый.

Эреле-ваклы шәһәрләре булу һәр цивилизациянең төп билгеләреннән санала. Урта Идел һәм Кама буйларында археологлар тарафыннан ачыкланган болгар калаларының саны 170кә җитә. Аларның өч дистәдән артыгы – чын шәһәр калдыклары. Болгар шәһәрләре ерактан ук балкып торучы мәчет манаралары, кызыл кирпечтән салынган җәмәгать биналары – мунчалары, төрбәләре белән Шәрык дөньясының мөселман шәһәрләренә охшап торган.

Урта гасырлар цивилизациясенең икътисади нигезен шәһәр һөнәрчелеге тәшкил итә. Тимерчеләр һәм бакырчылар, ювелирлар һәм күнчеләр, пыяла ясаучылар һәм кирпеч сугучылар, чүлмәкчеләр һәм башка һөнәр ияләре җитештергән югары сыйфатлы тауарлар дөнья базарында дан тоткан. Биләрдә тимер коючылар бистәсенең – бер гектар, чүлмәкчеләр бистәсенең өч гектар җир биләп торуы, XI гасырда ук инде тәрәзә пыялалары ясый башлау, төсле һәм кара металл эшкәртүдә, ювелирлык эшендә күптөрле катлаулы ысуллар куллану һәм башка шундый фактлар болгар һөнәрчелегенең үз вакыты өчен гаять югары дәрәҗәдә торуын раслыйлар.

Идел болгарлары мәдәниятле халык булган. Бу өлкәдәге казанышлар – урта гасырлар цивилизациясенең үзенчәлекле күренеше. Сөяктән нәфис итеп ясалган язу каләмнәре, кара савытлары, асылташлар белән бизәлгән китап тышлыгы, гарәпчә язулы йозаклар, шахмат фигуралары – шул цивилизациянең археологиядә чагылыш тапкан бик кечкенә бер өлеше.

Мәчет-мәдрәсәләрдә ислам нигезләрен генә өйрәнеп калмыйча, хисап, табигать белемнәре, шул исәптән география, астрономия һәм дә тарих, медицина буенча башлангыч мәгълүматлар алганнар. Сәләтле яшьләрне Бохара, Сәмәрканд, Нишапур, Балх, Багдад һәм Шәрыкның башка шәһәрләренә җибәреп укытканнар. Шул яшьләр арасыннан үсеп чыккан Әбү Хәмид ибн Идрис әл-Болгари, Борһанетдин ибн Йосыф әл-Болгари, Сөләйман ибн Дауд әс-Саксини әс-Суари, Таҗетдин ибн Хөсәен әл-Болгари кебек атаклы галимнәр дин һәм хокук белеме, медицина, фәлсәфә буенча күләмле хезмәтләр язып калдырганнар.

Монголларга кадәрге Болгар чоры әдәбиятының безнең көннәргәчә килеп җиткән җәүһәре – Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» китабы – элгәре цивилизациябезнең чын көзгесе. Мондый әсәрне иҗат итү өчен шартлар урта гасырлар чорының бөтен яктан да югары үскән җәмгыятендә генә булырга мөмкин.

Табигый ки, матди һәм рухи культураның барлык өлкәләрендә диярлек шундый югарылыкка ирешкән Болгар дәүләте үз кабыгына гына бикләнеп яши алмаган. Язма чыганакларга мөрәҗәгать итеп, Болгарстанның Азия-Европа мөнәсәбәтләре системасындагы урынын аныкларга мөмкин. Исеме билгесез венгр тарихчысы язмаларында Биләр кешеләренең Дунай якларына китеп, анда Пешт шәһәренә нигез салулары, дәүләт хакимиятендә финанс эшләре белән җитәкчелек итүләре турында кызыклы мәгълүматлар бар. Скандинавия сагаларында «Вулгария» Гардариканың – «Шәһәрләр иле»нең бер өлеше буларак телгә алына. XII гасырда яшәгән фарсы тарихчысы Бәйхаки китабында болгар әмире Ибраһимның Хөрәсән патшасына Сәбзевар һәм Хөсрәүҗәрд шәһәрләрендә мәчетләр төзү өчен акча һәм бай гына бүләкләр җибәрүе турында язылган.

Бу темага караган материаллар археологиядә дә күп. Алар арасында VIII-X гасырларда сугылган көмеш дирһәм хәзинәләре, Урта Азиядән (Үргәнеч, Сәмәрканд, Мерв), Иранннан (Кашан, Рей), Һиндстаннан, Сүриядән, Византиядән китерелгән кыйммәтле савыт-саба, муенса төймәләре, бизәнү әйберләре ясаганда кулланыла торган лазурит, сердолик, гранат, тау хрустале кебек асылташлар һәм башка табылдыклар бар. Биләрне һәм Мөрән шәһәрлеген казыганда килеп чыккан төсле витраж пыялалары, лампалар, савыт-сабалар Грузиядә, Әрмәнстанда, Азәрбайҗанда эшләнгәннәр. Херсон һәм Таврия остаханәләрендә ясалган амфоралар да еш очрый.

Болгар дәүләтенең Көнбатыш Европа, Балтыйк буе һәм Скандинавия илләре белән бәйләнышлары да археологиядә чагылыш тапкан. Табылдыклар исемлегендә Алманиядә, Даниядә, Чехиядә сугылган акчалар бар. X-XI гасырларда ясалган франк кылычлары болгарларга варяглар аша килеп кергән. Болгар шәһәрләрендә табылган әйберләр арасында Лотарингиядә, Аквитаниядә эшләнгән бакыр-көмеш савытлар бар. Швециядә, Норвегиядә, Финляндиядә, Даниядә, Польшада, Венгриядә һәм Балтыйк буе дәүләтләрендә X гасырда сугылган болгар акчалары табылган.

Күргәнебезчә, ислам динен кабул итү чорында формалаша башлаган халыкара бәйләнышлар болгарларда икътисадның һәм мәдәниятнең үсешенә уңай тәэсир ясаган. ■

Алтын Урда һәм суфыйлар

Илнур Миргалиев

در بیان آداب صحبت و شرایط او

در ستایش اعتقاد حاجی محمد قرتی در حق پیر خود

«Каләндәрнамә»нең бер бите

Олуг Олыс, ягъни Алтын Урда дәүләте Чыңгыз хан һәм аның уллары, торыннары алып барган сугышлар нәтиҗәсендә оеша. Шактый территорияне биләгән бу ил мөселман һәм мөселман булмаган халыкларны, аларның җирләрен бер канат астына җыя. Әмма ул тиз арада тулаем ислам мәмләкәтенә әверелә.

Археология тикшеренүләре күрсәткәнчә, исламлашу процессы биредә XIII гасырның беренче яртысында башлана һәм өзлексез дәвам итә. Илнең беренче

шәһәрләре үк Урта Азия, Анадолу һәм Якын Көнчыгыш мөселман традицияләрен исәпкә алып салына, шундый синкретизм нәтиҗәсендә архитектурада һәм сәнгатьтә үзенчәлекле урта гасыр татар-ислам стиле барлыкка килә.

Исламлашу гаммави күренеш ала, утрак халык та, күчмә ырулар да мөселман диненә тартыла. Бәркә ханнан соң мәҗүси хакимнәр идарә иткән елларда да әлеге процесс тукталмый, акрынаймый. Язма чыганаклардан күренгәнчә, бик күп мөселман галим-голамәсе Алтын Урдага күченеп, үзен иршадка – ислам динен таратуга багышлый. Аерым шәехләрнең исемнәре тарихи язмаларда теркәлеп тә калган: Шәех Сәйфеддин әл-Хәрәзми, Шәех Мәҗидеддин Ширвани, Шәех Нәҗибеддин (Баба Төкләс дип танылган), Шәех Әхмәд, Шәех Хәсән Гүргәни, Шәех Мөхәммәд Илле...

Кайбер татар шәҗәрәләре Эрзурумнан чыккан һәм «Бату хан чоры»нда ислам динен таратыр өчен яңа җирләргә – Идел буена күченеп килгән руханиларга тоташа. Аларның күбесе суфый була, билгеле. Бу табигый дә. Беренчедән, суфыйларның тулаем дингә бирелгән, аның өчен җанын фида кылырга әзер затлар булуын онытмыйк. Икенчедән, борын-борыннан суфыйлар имам-шәех җитәкчелегендә берләшә, үзләре аерым җәмәгатьләр булып яши, ягъни зур көч тәшкил итә. Тәхеткә Мөхәммәд Үзбәк утырып, исламны дәүләт дине дәрәҗәсенә күтәргәч, мөселманнар үзәк хакимиятнең таянычына әверелә. Алар структур яктан моңа күптән әзер була инде.

Бу елларда яңа шәһәрләр, мәчетләр, мәдрәсәләр төзелә. Иң мәгълүмнәре арасында Иске Кырымдагы Үзбәк хан мәчет-мәдрәсәсен, Болгардагы Җамигъ мәчетен санап узарга мөмкин. Түбән Иделдә уздырылган археологик тикшеренүләр Олуг Олыста Аллаһ йортларының бихисап корылуын күрсәтә. Шәехләрнең тәрикатьләре зурая, мөритләре арта. Алтын Урда чорында Пәйгамбәребезнең (с.г.в), Әбү Бәкер, Гали кебек сәхабәләрнең нәсел дәвамчылары татар шәҗәрәләренә килеп керә.

Шул чорда иҗат ителгән «Каләндәрнамә» хезмәте бу якларда ислам дине таралу буенча бихисап фактологик мәгълүмат бирә. Аның авторы Әбү Бәкер үзенең Алтын Урдага күченүен болай дип аңлата: *«Каләндәр Кырымга иршад кылыр өчен килде»*. Һичшиксез, каләндәрләр тәрикате дә, Әбү Бәкернең эшчәнлеге дә Идел буенда мөселманнар санын арттыруга зур йогынты ясый. Төрки-татар чыганаклары күрсәткәнчә, Үзбәк хан исламга Сәед Ата (Ясәвия тәрикате суфые) тәэсирендә керә. Әмма Бәркә хан чорында өстенлек, ихтимал, Анадолу шәехләре ягында булгандыр.

Чыңгызыйлар корган дәүләтләрдә мөселман галимнәре XIII гасырда ук миссионерлык белән шөгыльләнә башлый. Хәрәземшаһлар һәм Багдад хәлифәте арасындагы каршылык мөселманнарның монголларга карата мөнәсәбәтендә дә чагыла. Ибн әл-Әсир хәбәр иткәнчә, Багдад хәлифе белән Чыңгыз хан яшерен элемтәдә торалар. Бу элемтәләр Җүчи заманында да дәвам итә. Хулагу хан хәлифкә каршы яу чабарга ниятләгәч, Бәркә бертуганы Бату ханнан бу эшкә каршылык күрсәтүне ялварып сорый: хәлиф белән Җүчи нәселе арасында тыгыз бәйләнешләр бар, ди.

Монголлар һәм ислам дөньясының бәрелешүе тарихи хезмәтләргә үтеп керә. Мөселман галимнәре бу яуларны ахырзаман белән чагыштыра. Шул ук вакытта ике арадагы хезмәттәшлек тә өзелми. Нәтиҗәдә, чыңгызыйлар нигезләгән дүрт дәүләтнең өчесе тиз арада тулаем исламлаша. Руханилар ил җитәкчелеген үз ягына авыштыруга ирешә.

Дини вазгыятьне өйрәнүче галимнәр Алтын Урдада кайсы тәрикатьнең өстенлек итүен өздереп әйтә алмыйлар. «Каләндәрнамә»дә, ясәвия белән бергә, каләндәрләр тәрикатенең дә киң таралуына ишарә бар. Бу хезмәткә таянып фикер йөртсәң, Алтын Урда халкын исламга тарту Чыңгыз хан заманыннан ук башланган.

Безнеңчә, Җанибәк һәм Бирдебәкне тәрбияләүчеләр арасында очраган аталыклар, һичшиксез, шәехләр булырга тиеш. Аталык – дәүләт белән идарә итәргә өйрәтүче. Аталык сүзе яңгырашы буенча Анадолуга якын тора. Әмма тәрбиячеләр вазыйфасын каләндәрләр дә башкарган булырга тиеш.

«Каләндәрнамә» – «җанлы» әсәр, ул, мәгърифәтле, белемле укучыны күздә тотып, диалог-әңгәмә рәвешендә язылган. Әбү Бәкер үзе дә: *«Бу эшләрдән хәбәрдар кеше генә мине аңларга мөмкин»,* – дип искәртә. Беренче каләндәрләрнең тамырлары Анадолуга тоташкан, дидек. Алар ислам турында күп белгән, үзләре суфый тормышы алып барган. Отыры «каләндәр» һәм «суфый» сүзләре бөтенләй синонимлашкан. Башка тәрикатьләр белән чагыштырганда, каләндәрләрнең саны күп булмый. Әмма алар, нигездә, хакимнәр белән аралаша һәм, беренче чиратта, өске катламны исламга тартырга тырыша. Шуңа күрә каләндәрләр һичкайчан чәчрәп чыкмыйлар, яшерен эш йөртәләр, башкарган гамәлләре турында күкрәк төеп сөйләмиләр, оран салмыйлар. Каләндәрләр хакындагы мәгълүматның бүгенгәчә аз булуы шуның белән дә аңлатыладыр, мөгаен.

Эшләрен яшерен йөртсәләр дә, суфыйлар үз «тарихын» теркәп барырга онытмый. Әйтик, Габделгаффар Кырыми: *«Бәркә һәм Үзбәк ханнар мәҗүси татарларны исламга кертте»,* – дип яза. Ягъни зур вакыйганы аерым шәхесләр, аларның ихтыяры аша аңлата. Болай иткәндә, билгеле, динне дә, шәехләрне дә данлау шактый җиңеләя төшә: чөнки алар, конкрет кешене – ханны – исламга китерү белән бергә, тулы бер халыкны да мөселманлаштырган булып чыга.

Каләндәрләр һәрвакыт хакимияткә якын була, аларның терәгенә әверелә. Алтын Урда ханнары (хәтта мөселман булмаганнары да) каләндәрләргә ышана, аларга уңай мөнәсәбәттә тора, дини эшчәнлекләрен җәелдерүгә каршы төшми. Тәрикать әгъзалары исә үзләренә һичнинди байлыклар, хәерхаһлык сорамыйлар, дингә һәм ханга хезмәт итүне изге бурычлары дип саныйлар. Мондый мөнәсәбәт, билгеле, хакимнәргә дә бик кулай була.

Мөхәммәд Үзбәк хан идарәгә керешер алдыннан җүчиләр тәхете какшап ала. Уйгыр Баҗар Төкбуга Олуг Олыс хакимиятен кулга төшереп, җүчиләрнең нәселен кисәргә, тәхеткә үз нәселен утыртырга омтылыш ясый. Әмма Үзбәк аның гаскәрен тар-мар итә. Мөселманнарның Үзбәкне яклап чыгуы җиңүгә зур өлеш кертә. Илдә ислам дине дә позицияләрен ныгыта. Җиңүче тараф тантана итә: *«Моннан ары кара кешеләр тәхеткә кул сузмас!»*

Мөхәммәд Үзбәк хан бөтен дөньядан мөселман галим-голамәсен үз янына җыя. Дөрес, аңарчы бу эшне Бәркә хан башлаган була инде. Шуңа күрә хакимият белән ислам руханиларының үзара багланышын, ихтимал, Бәркә хан чорыннан исәпләсәң, хакыйкатькә якынрак булыр.

Аның тәхеткә менүе Габделгаффар Кырыминың *«Үмдәт әл-әхбәр»* исемле хезмәтендә болай бәян ителә: *«Бәркә ханзадә Аллаһ рәхмәте илә мөселман холыкфигыленә ия иде, Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) тарафдарларын очратса, шунда ук дуслаша, мәҗүси татарларга нәфрәт белән карый иде. Шунлыктан туган-тумачасы һәм дәүләт ирләре аны акылдан язганга чыгара, үзләреннән читкә тибәрә иде. Шул сәбәпле ул Сыгнак вилаятенә күченде һәм бөек галим, мәртәбәле хәзрәт Шәех Сәйфетдин әл-Хәрәзмигә якынайды. Догалар, фәннәр өйрәнүгә бирелде,*

Илаһка тартылды. Илаһ ярдәме илә үзе дә шәехкә, могҗизалар кылучыга (сәхиб кирәмәткә) әверелде. Монголлар чиргүе аны күз уңыннан югалтты һәм ни белән шөгыльләнүен белмәде. Шул вакытта Идел падишаһы вафат булды, карашлар Хулагу тарафына борылды. Шәехләр башлыгы Бәркәгә мөрәҗәгать итте: «И бөек бабаларыңның, бушап калган тәхеткә ия хуҗаларыбызның хөрмәтле угылы, шул тәхеткә ия булыр өчен синең алда барлык мөмкинлекләр ачылды...»

Бәркә моңа каршы килә, данлыклы Ибраһим Әдһәмнең, Илаһка хезмәт итәр өчен, тәхеттән баш тартуын үрнәк итеп китерә. Әмма шәех барыбер аның фикерен үзгәртүгә ирешә. Нәтиҗәдә, Бәркә, Хулагуга каршы чыгып, атасының урынын ала, ханлыкка баш була. Шәех аңа һәрьяклап ярдәм күрсәтә. Мөселманнарның Җүчи нәселен тәхеттә калдыру өчен ничек тырышуы, аларның нинди куәткә ия булуы шушы кечкенә өзектә дә яхшы чамалана.

Үзбәк хан мәчетенең бер өлеше. Солхат, Иске Кырым. 14 нче йөз. *И.Измайлов фотосы*

Габделгаффар Кырыми бәян иткәнчә, Бәркә хан чорында Алтын Урда халкы тулаем ислам динен кабул итә. Әмма аның вафатыннан соң, бик күпләр яңадан мәҗүсилеккә кайтып, утка табына башлый. Шуннан соң дүрт атаклы *«әүлияуллаһ» «Дәшти Кыпчак халкы арасында Җүчи Олысында Мөхәммәд динен»* таратырга керешә, болар: Шәех Мәҗидеддин Ширвани (хәзрәти Гали нәселе), Баба Төкләс Шәех Нәҗибеддин (Әбү Бәкер Ситдыйк нәселе) һәм ике сәед (Пәйгамбәр (с.г.в.) нәселе) – Шәех Әхмәд белән Шәех Хәсән Гургани. Мәҗүсиләрнең сихер белән мавыгуы, башка ямьсез гамәлләре турында сөйләнгәннән соң, язмада Мөхәммәд Үзбәк ханның иле белән исламга күчүе һәм *«шәрыкътан алып гаребкә кадәр бөтен Татарстанның иманга килүе»* хакында хәбәр ителә.

Ары таба мөселманнар, ханга терәк булудан бигрәк, аның якыннарына, үз кешеләренә әверелә. Мөхәммәд Үзбәк ханның улы Җанибәк ислам гореф-гадәтләре нигезендә тәрбияләнә. Аңа туганда ук мөселман исеме кушыла: Солтан Мәхмүд Җанибәк. Бирдебәк тә шундый ук тәрбия ала.

Габделгаффар Кырыми: *«Җанибәкне Гомәр әл-Фарук (сәхабә, Пәйгамбәрнең (с.г.в.) фикердәше, көрәштәше, икенче хәлиф, мөселманнар арасында гаять мәртәбәле зат) белән чагыштыралар иде»,* – дип яза. Моның төбендә Гомәр әл-Фәрукның да, Җанибәкнең дә Фарсы илен яулап алулары ятмыймы икән? Һәрхәлдә, андый уртаклык та күзгә ташланып тора. Бу очракта Бәркә ханны Пәйгамбәрнең (с.г.в.) фикердәше, көрәштәше Әбү Бәкер белән чагыштырырга мөмкин булыр иде. Алтын Урда суфыйлары, беренче хәлифәләр һәм татарның беренче ханнары арасында паралельлар тудырып, татар тарихын ислами күзлектән теркәп калдыралар. ■

Безнең мирас №5 май 2022

Батырша мулла – татарның каһарман улы

Рәфис Шәйхәйдаров

Татарстанның һәм Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, «Батырша» музее җитәкчесе, имам-хатыйб Рәфис Шәйхәйдаров

Тирә-якта зур белем иясе булуы белән танылу тапкан, динебезне, халкыбызны саклап калу өчен барган көрәшкә зур көчен салган, патша хөкүмәтен зур хафага төшергән Габдулла Галиев – Батырша Карышбаш авылындагы Туктаргали Дусалиев гаиләсендә туа.

Батырша исеме

Батыршаның исемен галимнәр төрлечә атыйлар. Мәсәлән, Ризаэддин Фәхреддин Габдулла Батырша (Баһадиршаһ) ди. Танылган галим Гайсә Хөсәенов Батыршаның чын исеме – Баһадиршаһ Миңлегали улы (Галиев), ә халыкта аның исемен, кыскартып, Батырша дип йөрткәннәр, дип әйтә.

Кайчан туган?

Батыршаның туган елын билгеләүдә дә галимнәрнең фикере төрлечә. М.И.Әхмәтҗанов Батыршаның туган елы итеп 1711 елны атый, С.М.Васильев, А.П.Чулошников, 1710-1715 нче еллар, ди, «Татар энциклопедиясе»ндә Батыршаның

туган елы итеп 1710-1715 нче еллар, ә «Башкорт энциклопедиясе»ндә 1709-1717 нче еллар күрсәтелә. Батырша 1756 елның октябрендә Мәскәүдә сорау алганда үзенең яшен төгәл күрсәтми. Ул бары тик: «Тумышымнан утыз яшьтән күбрәк», – дигән. Архивта сакланган материалларда да, кызганыч, бу сорауга җавап таба алмадык.

Кемдә укыган?

Батырша иң элек әтисеннән – абыз Туктаргалидән дин сабакларын ала, аннары Тайсуган авылындагы Габдерахман мулла мәдрәсәсендә укый. Габдерахман хәзрәт киңәше белән ул Казан өязенең Ташкичү авылына барып мәшһүр мулла, булачак ахун Габдессәлам Уразмөхәммәд җитәкчелегендә дини һәм дөньяви белемен камилләштерә. Батырша хәзрәт 25-26 еллар чамасы шушы мәдрәсәләрдә белем ала.

Кайда укыткан һәм имам булган?

Ташкичү мәдрәсәсендә дини белемнәрен камилләштергәннән соң, Батырша Уфа өязенең Уса юлындагы Гайнә волосте Күземъяр – Байавыл авылында (хәзерге Пермь өлкәсенең Барда авылы) һәм Исәт провинциясендәге Мөслим Аширов старшинаның йомышлы татарлар яши торган Мөслим авылында (хәзерге Чиләбе өлкәсе) балаларга сабак укыта, мулла вазыйфасын башкара.

Биш еллап шушы җирләрдә укытканнан соң, Батырша хәзрәтнең авылдашлары, аның янына килеп, авылга имам булып кайтуын үтенәләр. Әлбәттә, Батырша хәзрәт теләп ризалаша һәм, 1749 елда туган авылы Карышбашка кайтып, мулла булып эшли башлый. Карышбашта әтисенең бушап калган өен мәдрәсә итеп үзгәртеп кора һәм балалар укыта. 1750 елда мәчет һәм аерым мәдрәсә бинасы төзелеп бетә. Тиздән Батырша мәдрәсәсе тирә-якта шактый абруй казана һәм бирегә дини белем алу өчен якын-тирә авыллардан гына түгел, ерак Казаннан һәм Көңгер өязеннән татар һәм башкорт егетләре агыла башлый.

Батырша ни турында уйлана?

Ә бу вакытта мөселман халкын көчләп чукындырулар, мәчетләрне юкка чыгару, исламнан аерылырга теләмәгән мөэминнәр өстенә ясаклар салу, моңа кадәр күл төпләреннән алган тозны сатып алырга боерулар, әлеге сәясәт белән риза булмаганнарны җәберләү, тукмау, хәтта үтерү хәлләре башлана. Патша хөкүмәтенең әлеге мәкерле сәясәте күпләрне зур хафага сала. Батырша хәзрәт тә мөселманнарга килгән фаҗигаләрне күрә һәм боларны туктату турында нык уйлана башлый.

Татарның коллыкка протесты – «Өндәмә»

1755 елның март аенда Батырша хәзрәт мөселманнарның май ахырында восстание күтәрергә карар кылулары турындагы хәбәрне ишетә. Ул берничә ай буе Оренбургны, аның янындагы Каргалы бистәсен, Нугай юлындагы Бөрҗән һәм башка волостьларны, Себер һәм Уса юлларын йөреп чыга, Казан губернасының Казан өязендәге татарлар һәм Җаек аръягындагы казакълар белән дә элемтәгә керә. Халыкны оештыру өчен, дәррәү патша дәүләтенә каршы восстаниегә күтәрелү мак-

сатыннан ул үзенең тугыз биттән торган «Өндәмә»сен яза һәм аны шәкертләре аркылы Идел-Урал төбәгендә яшәгән мөселман халыкларына тарата.

Батырша хәзрәт бу өндәмәсендә дин һәм ирек өчен көрәшкә чакыруның сәбәпләрен аңлатып бирә: «Ислам әһелен хур вә зәгыйфь тотуга сәбәпче булды», – ди. Бердәм булуның үрнәге итеп Болгар дәүләте чәчәк аткан чорны күрсәтә. Батырша патша сәясәтенең максаты – мөселманнарны ассимиляцияләү һәм урыслаштыру, ә шуңа ирешүнең бердәнбер юлы – чукындыру икәнен ассызыклый. Моны булдырмас өчен барча мөселманнар берләшеп, патшага каршы көрәшкә чыгарга, колонизаторлардан котылып, бердәм мөселман дәүләте төзергә кирәк, ди ул.

Батырша бу сугышның русларга каршы тугел, ә чиновникларга, офицерларга, хыянәтче старшиналарга, азгынлыкка, ачкүзлелеккә, шулай ук үз халкының мәнфәгатен саткан канэчкеч кешеләргә каршы икәнен аңлатып яза. Ул алышның авыр булачагын, көчләрнең тигез түгел икәнен, корбаннар булачагын да бик яхшы аңлый. Әгәр дә батыр һәм тәвәккәл булсак, җиңү безнең якта булыр, шәһид киткән һәр кеше халык хәтерендә калыр һәм җәннәткә ирешер, ди ул. Батырша восстаниегә Россия территориясендә һәм Урта Азиядә яшәгән мөселманнарның барысын берьюлы күтәрергә ниятли.

Губернатор аңын җуя

«Өндәмә»дә восстание оештыру турындагы сорауларга да зур урын бирелә. Анда кат-кат бик җентекле әзерләнү, баш күтәрүчеләрне корал һәм атлар белән тәэмин ителү кирәклеге турында әйтелә. Автор фикеренчә, һәрбер хөкүмәтнең, илнең төп вазыйфасы – халкын кайгырту, аларнын хокукларын яклау, барча халыкка бертигез мөнәсәбәт күрсәтү. Ә Россия патшалары исә мөселманнарга карата булган вазыйфаларын үтәмиләр, шуның аркасында, кимсетелгән халыклар үзләренең язмышларын үзләре хәл итәргә хокуклы, ди.

Батырша татар, башкорт, казакъ халыкларын царизмга каршы әзерли башлый һәм үзен яшерен эш итү остасы итеп таныта. Бу эшчәнлекне ул шундый пөхтә, төгәл башкара ки, һәр шәхесне күзәтү астында тоткан дәүләт шымчылары да аның ничә еллар буена алып барган актив эшчәнлеген сизми кала. Халык күтәрелеше турындагы хәбәрен ишеткәч, губернатор И.Неплюев шул дәрәҗәдә каушап кала ки, үлем якасына җитәр хәлдә «горячка»га егылып, аңын җуя һәм яшәү белән үлем арасында һушына килә алмыйча интегә.

Сугыш ничек башланган?

Батыршаның уйлавы буенча, восстание Уса һәм Себер юлы мишәр һәм башкортлары белән бер үк вакытта башланырга тиеш була. Әзерлек эшләре шактый киң күләмдә алып барылса да, план үтәлми, аерым урыннарда башбаштаклыклар күзәтелә.

Бөрҗән башкортлары бай татарларны талап, үтерә башлыйлар. Елан Иткол һәм Ходайбирде җитәкчелегендәге башкортлар тарафыннан 15 майда экспедиция начальнигы Брагин һәм аның командасындагы 6 кеше үтерелә. Брагин Нугай юлының көньяк волостьларына, Урал тауларында төсле ташлар эзләү өчен җибәрелгән була. Тик нәфесе туймаган түрә биредә алтын гына эзләми, ә җирле халыкны көчләү һәм талау белән дә шөгыльләнә. 18 майда баш күтәрүчеләр Исәт юлындагы Сапса ямыстанын һәм Брагинның яшәгән йортын туздыралар.

Балтач районының Югары Карыш авылындагы Батырша музее

Неплюев аңына килә

Ырынбур губернаторы И.И.Неплюев тиз арада Бөрҗән волостендагы чуалышларны тар-мар итү өчен мөһим чаралар күрә. Чуалышлар 15 майда башланган булса, 18 майда ул бирегә подполковник Исаков җитәкчелегендәге гаскәриләр командасын озата. 22 майда әсир ителгән баш күтәрүчеләрне җәзалау башлана. Боларга өстәп, тагын 1000нән артык солдат һәм казаклар җибәрелә. Фетнәне бастыруда патша хакимиятенә тугры калган башкорт һәм мишәр старшиналары да катнаша. Баш күтәрүдә гаепләнгән башкортлар, аларның гаиләләре һәм туган-тумачалары кулга алына, мөлкәтләре хөкүмәт файдасына конфискацияләнә. Исән калган башкортлар, артык каршы тора алмаячакларын аңлап, казакъ далаларына юнәләләр. Әмма Неплюев, фетнәчеләрнең казакъ далаларына чигенү ихтималлыгын күз алдында тотып, аларның Җаекны кичүләренә аркылы төшү чараларын да уйлап куя. Шул сәбәптән бик күп баш күтәрүче Җаек кичүләрендә казаклар һәм калмыклар тарафыннан юк ителә.

Өметләр акланмый, хәйлә һәм ялган

Болардан тыш, биш меңләп татар-башкорт казакъларга килеп кушыла алса да, кардәш халык аларны колач җәеп каршы алмый. Батырша алдан күргәнчә, җирле халык белән башкортлар арасында тарткалаш, хәтта сугыш башлана, мөселман-төрки халыклар бер-берсенә каршы корал күтәрәләр.

Батырша хәзрәт Казан губернасындагы мөселманнарның да баш күтәрәчәгенә ышанган була, әмма бу өметләре дә акланмый. Казан тирәсе дәүләт гаскәре белән тулганга күрә, алар баш күтәрергә җөрьәт итми.

Татарларны сугышып кына җиңеп булмаганны яхшы аңлаган патша хакимияте, халыкның рухын какшату өчен, мәкерле алымнарга, ялган вәгъдәләргә бара. Неплюев хәтта Ибраһим ахун исеменнән татар-башкорт һәм казакъ далаларына Батырша хәзрәткә каршы язылган ялган хат язып тарата. Шулай ук казакъ хан-

нарын баш күтәргән татарларга каршы котырту, аларны сатып алу ысулын да киң файдалана.

Фетнәчеләр килешүне боза

Шуңа да карамастан, Батырша хәзрәт халык арасында оештыру эшләрен дәвам итә. Ул нугай юлында яшәгән волость җитәкчеләре һәм дин әһелләре белән очраша. Батырша Ырынбурда Ибраһим ахун белән күрешә, аның белән дә сөйләшүләр алып бара. Каргалыга килә, анда Габдессәлам ахунның өендә берничә көн кунак була. Ул анда күтәрелешнең вакытын билгели. Батырша Каргалыдан Казан өязендәге Алат юлы йөзбашы Ярмәкәй Мамашевка хат җибәрә. Анда ул: «Уфа өязенең барлык дүрт юл халыклары әзер, Казан татарлары да әзерлектә торсыннар», – дип яза. Восстание башлауның вакыты килешенә, уртак фикергә килеп, планнар төзелә. Бөтен Гайнә татарларының кузгалышы 1755 елның 1 сентябренә билгеләнә.

Әмма 9 августта көтелмәгән яңа чуалышлар башланып китә: Урал тауларының көнчыгыш битендә урнашкан Бөрҗән волосте башкортлары тагын баш күтәрә. Фетнәчеләр старшина Абдул Ваһапны, анын писарен һәм 2 йомышлы татарны үтерәләр. Барон Сиверсның Ык буенда төзелеп килүче Вознесенск бакыр заводына һөҗүм оештыралар. Тиз арада фетнә тирә-як волостьларга да тарала. Гвердышев заводы тирәсенә килеп, заводны яндыру белән яныйлар. 15 августта Покровский заводы яндырыла. 20 августта фетнәгә Үсергән, Бөрҗән, Тамьян, Тәнгәүр һәм Бушман-Кыпчак волостьлары да кушыла.

Ырынбур губернаторы И.Неплюев, фетнәне тиз арада бастыру өчен, патша гаскәрләрен, үзенә тугры калган башкорт һәм мишәр командаларын озата. Шулай ук 1000 калмык, 1000 дон казагы, 1000 ырынбур казагы, 500 чукынган калмыкны ил чиген казакълардан саклау өчен җибәрә. Патшабикә Елизавета Петровна исеменнән 1 сентябрьдә үзләре теләп бирелгәннәрне гафу итү, казакъларга качып китүчеләргә 6 айда туган якларына әйләнеп кайту мөмкинлеге турында манифест кабул ителә. Манифестның урыс телендә – 580, татарча 200 данә күчермәсе халык арасына таратыла.

Нугай юлында фетнәчеләргә каршы көрәш 9 августтан алып октябрь уртасына кадәр дәвам итә. Неплюев уңышка ирешә: волостьларда башланган фетнәне төбәкләргә таратуга чик куя, баш күтәрүчеләрнең отрядларын тар-мар итә.

Батырша урманга качканмы?

Шушы вакытларда Батырша мулла Гайнә иленнән хат ала. Анда: «...Гайнә халкының яртысы әзер тора иде, ләкин монафикълар кешеләрне куркытып, кайберләрен үтергәннәр. Ошбу төндә үзеңезне һәлак итмәк касдында торалар. Бик тизлек вә саклык илә башыңызны коткарырга җәһәдләңегез», – диелә.

Батырша үзе белән хатыны Зөлбохарны, 7 яшьлек улы Таҗетдинны, 3 яшьлек кызы Зөләйханы, 1 яшьлек кызы Салиханы, иң якын шәкертләре – Яхъя, Мөхәммәдрәшип, Моталлип, Касыйм, Габделкәрим, Мирәхмәт, Мөслим һәм Габделгаффарны, шулай ук Дәүләтбай Хуҗагулов белән Сәфәр Агаферовны алып, урманга китә.

Восстание тарихын чагылдырган хезмәтләрдә Батырша хәзрәт «урманга кача» дигән сүзләрне очратырга туры килә, ләкин моның дөреслеккә туры килмәвен ачыклап китү кирәк. Алда бәян ителгәннәрдән чыгып, без Батыршаның кыю-батыр, курку белмәс ир-егет, көчле иманлы, тәкъва мөселман икәнен раслыйбыз. Ул һәрвакыт

Аллаһның тәкъдиренә ризалыгын белдерә. Ничек инде шушы кеше көрәшнең иң җаваплы вакытында үзен генә кайгыртып, куркып урманга качарга мөмкин?! Яу башлыгының туган авылыннан урманга китүе Яныш Габдуллин рапортыннан чыгып бәян ителә. Ул: «Батырша вур унбер юлдашы, хатыны һәм угланнары белән урманга качты. Мин, артындин куа барып, урманда сугыш итеп, ике кешеләрен үтердек», – дип яза.

Батырша, Гайнә иленнән шөбһәле хат алгач та, тиз генә башын коткарырга уйламый, төнне өендә куна. Мондый шөбһәле хат алганнан соң, Батырша, уйланып, йокысыз төн үткәрә. «Бер Ходаема тәвәккәл итеп, өй җәмәгатем вә шәкертләрем, алты садак, бер сөңге коралымызны алып, халыкның уртасына чыгып киттек. Алты чакрым урманга йиткәнчә, сәламәтлек берлә озаттылар. Без урманга кердек. Анлар кайтдылар. Белдем: ул халык арасында безгә дошманнар юк икәндер», – дип яза ул. Аңлашылганча, Батыршаны 6 чакрым чамасы ераклыктагы урманга гаиләсе һәм унбер шәкерте белән озатып баралар. Батырша сүзләренә караганда, 150 кеше арасында Яныш старшина кешеләре дә була. Ләкин ни өчен алар Батыршаның урманга китүенә каршы төшмәгән? Мәсгуд Гайнетдин, шушы сорауга җавап итеп, болай дип яза: *«Таң атканда күрә, дошманнар инде авылга тулганнар, Батыршаның өен урап алганнар. Әмма Яныш старшина үзе әле килеп җитмәгән. Батырша бу хәлдән файдаланып кала. Аның халык арасында авторитеты шулкадәр көчле була, күрәсең, ул, җыенып юлга чыгарга уйлагач, чигенеп, аңа юл бирәләр. Бу аз санлы, ярдәмчесез төркемне 140-150 кешелек отряд урманга кадәр урап барса да, берәү дә аларга кул күтәрергә җөрьәт итми».*

Карышбаш һәм Чуртанлыкүл авылларында сакланган риваятьләрдә Батырша белән Яныш старшинаның туган булуы турында да әйтелә. Шул сәбәпле дә булса кирәк, Яныш старшина кешеләре Батырша хәзрәтне урманга чаклы озатып бара. Ул гаскәри мишәрләргә, үзенең әмереннән башка, Батыршаны тоткарламаска әмер бирә.

Күтәрелеш бастырылгач, бөтен җиргә гаскәр килеп тулгач кына, Яныш старшина Батырша һәм аның аркадашларын эзәрлекләүне оештырырга мәҗбүр була. Батырша урманда ерак качмый. Бәрелештә ике кеше үтерелгәч тә, әле ул ун көн буе: «Халаеклар ни хәлгә әйләнерләр икән?» вә «Ни хәлләр аңларырмыз икән?» – дип, урман читендә генә йөри. Яныш старшинаның шушы ун көн эчендә йөзләрчә кешелек отряд оештырып, Батыршаны кулга төшерү мөмкинлеге булган, ләкин ул моны эшләми.

Урмандагы җитәкчелек итү пункты Батырша тарафыннан алдан ук әзерләнгән була. Моны сорау алу материаллары да раслый. Аларда: «Карыш авылындин чыкмастин борын ул Куҗаш урманына азык чыгарып куйган икән, аны ашап тордык ике җомга», – диелә.

Батырша: «Кышны базда үткәрдек»

Батырша хәзрәтнең үзенә һәм тарафдарларына карата ау башлана, аның күп көрәштәшләре кулга алына һәм хөкем ителә. Хакимият органнары Батыршаны тотмыйча фетнәне тулысынча тар-мар ителде дигән нәтиҗә чыгарып булмаганын яхшы аңлый. Шуңа күрә алар аны үтергән яисә тоткан кешегә 1000 тәңкә, әяраннары өчен 500 тәңкә акча вәгъдә итә. Батыршаның халык белән бәйләнеше тулысынча киселә, ачлык башлана. Авылларга азык алып килергә дип җибәрелгән шәкертләрнең берсе дә кире кайтмый, урманнан чыгу белән үк аларны, кулга алып,









Батырша китаплары

Уфага озаталар. Батырша, салкыннар башлангач, каенесе Мостафа Хөсәен улын, балалары белән хатынын Урал аръягына, әтиләренә җибәрергә тели. Әмма урманнан чыгу белән алар да, дошман кулына төшеп, Уфага озатылалар. Зөлбохарны балалары белән тайный советник Б.Ф.Щербаковка тапшыралар, соңрак аларны, чукындырып, монастырьга ябалар.

Батырша Яхъя исемле шәкерте белән тагын кача. Күпме эзләсәләр дә, аны таба алмыйлар. Соңыннан төрмәдә язган «Гарызнамә»сендә ул: «Нәдер старшина (Уразмәтов) авылында мәчет астында баз казып, шул базда кышны үткәрдек, Габдерахман хәзрәт шәкертләре, дип, тирә-як авылларда хәер сорашып тукландык», – дип әйтә.

Батыршаның кулга алынуы

Икенче елны ул туган якларына кайта, әмма 1756 елның 8 августында Әзекәй дигән йомышлы татарлар авылында старшина Сөләйман Диваев һәм аның ярдәмчеләре тарафыннан кулга алына. Батыршаны Уфага, аннан сак астында Мәскәүгә Сенат судына озаталар. Юлда барганда ул тимер богавын кисеп, сак астыннан качып китәргә ниятли, ләкин аны солдатлар куып тотып, бик каты кыйныйлар. Батырша Мәскәү төрмәсендә шактый озак авырып ята.

Батыршаны тикшерү эше ике елга сузылып, 1758 елның декабрендә хөкем чыгарыла: камчы белән суктырырга һәм борын яфракларын кисеп алырга. Ул гомерлеккә Шлиссельбург крепостеның бер кешелек камерасына ябыла, янында һәрвакыт сакчылар була.

Батырша тикшерү барышында императрица Елизавета Петровнага восстание сәбәпләрен күрсәтеп хат юллый. Хатында ул Казан, Ырынбур һәм Тубыл губерналарында яшәүче мөселманнарны көчләп чукындыру, түрәләрнең гади халыкны изүе, төрле сәбәпләр табып, кечкенә мәсьәләләрне дә айлар, хәтта еллар буе хәл итмәүләре; вулыс старшиналарының эчеп исерүләре, кылыч белән кешеләрне кисүләре, кулларын чабулары, караклыклары турында яза.

Качарга омтылу һәм үлем

Батырша, 5 ел утырганнан соң, 1762 елның 24 июлендә үзен-үзе коткармак булып, төрмәдә берүзе баш күтәрә һәм төрмә сакчылары белән тиңсез алышта вафат була. Таш зинданның бер кешелек караңгы, салкын, тар камерасында ятып, тәмам иза чиккән бу батыр, ниһаять, акыл җитмәслек тәвәккәллеккә бара: дәрья уртасында моңарчы беркем котыла алмаган таш капчыктан кул-аягы богаулы көе качарга була. Крепость коменданты полковник Бердников сүзләрен китерәбез: *«Оный колодник взял принесенный солдатом Хомутовым топор по одиночке у капрала Никитина тем топором голову разрубил надвое, у солдата Хомутова головы левую сторону разрубил и правый висок проломил; у Лазарева в двух местах брюхо пропорото; у Епифанова, который был на часах, в двух местах голову разрубил же. Оный же колодник и сам умер без всяких язв и побой»*. Аның гәүдәсен кальга диварлары тышындагы бер чокырга күмәләр.

***

Ислам дине, рухи азатлык, халык бәхете өчен кулларына корал тотып көрәшүчеләр, гомерләрен корбан итеп, патша хакимиятенең мөселманнарга карашын берникадәр йомшарталар, шулай да көчләп чукындыруны туктата алмыйлар. ■

Безнең мирас №5 май 2022

«Күз күрде, гакыл белде...»[1]

Миркасыйм Госманов

Әтрәч зиратының хәзерге күренеше

22.07.1968.

Иртәнгелекне ашап-эчеп алгач, Тәтеш ягына, Әтрәч, Торма, Аллабирде авылларына киттек. Көн бик әшәке иде. Тәтешкә килдек. Мин, почтага кереп, Казан белән сөйләштем.

Бу Тәтеш шәһәре шактый иске, йолкыш шәһәр. Үзендә борынгы кирпеч йортлар күп: сәүдәгәр, мещаннарның оясы булганга охшый. Урамнар пычрак, күп йортлар җимерек. Яңа төзелешләр бик кәрлә...

Киттек Әтрәч ягына... Олы Торма дигән авылга килдек. Монда 125 йорт. Янында гына Кече Тормада 46 йорт икән. Авыл Советы рәисе – Тәгъзим Мусин. Бер карт белән сөйләштем, әллә нәрсә белми.

Авыл Советына мәктәп мөдире Хатип ага Сафиуллин килде. Аның әйтүенчә, элек бу Торма авылында шәҗәрә булган, ләкин соңрак вакытта аның үзе югалган... Сәлимулла Сафиуллин дигән бер бабай килде. Аның әйтүе буенча, бу авылда элек чуашлар булган. Аннары төрле яклардан татарлар килеп утырган. «Торма» дигән сүз чуашча «Алла» дигән сүз, имеш... Бу бабай шактый гына белдекле бугай, «Йосыф» китабын яттан ук белә, тәре!

Хәбибрахман Хәмзин дигән бабайдан (мулла булган) калган күп китапларны Касыйм абзый Хәмзин (сүзлекче)[2] Казанга алып киткән булган... Икенче бер риваятькә

---

[1] 1968 елда Татарстанның Тау ягына – Чүпрәле, Буа һәм Тәтеш районнарына оештырылган археографик экспедиция (VIII сәфәр) көндәлегеннән кыскартып бирелә. Экспедициядә М.Госманов белән Мөхәммәди Мөхәммәтшин һәм Җәүдәт Дәрзаманов та катнашкан. – *Ред.*

[2] Хәмзин Касыйм Зыятдин улы (1895-1976) – педагог, тел белгече, Олы Торма авылында туган.

караганда, бу авыл кешеләре элек кайдандыр (бәлки, Чуаш ягыннандыр) килгән, имеш...

Кече Тормадан Гыйльман Камай[3] чыккан, шулай ук Альфред Халиковның[4] атасы шушы авылдан икән.

Хатип ага [Сафиуллин] белән бергә зиратка барып ташлар карадык. Мәрҗанинең оныгы Габделгазиз бине Борһанеддин шушы кабердә күмелгән икән.

23.07.1968.

Кичә Авыл Советына кереп, бернәрсәне дә җүнләп әйтмәгән Хәсән Гыйфәтуллин дигән картка кереп, аның бер кульязмасын карадык. Шунда мондый шәкерт шигырьләре бар:

«Иланhи бәет

Озын-озын юллар улыр,
Ул юлларның башларында чүлләр улыр.
Мәктәптә торган шәкертләргә
Гыйлемлек хасил кайчан улыр?
Мәктәп юлы тузан улыр,
Туфраклары гөлзар улыр,
Мәктәптә торган шәкертләр
Гыйлемлек өчен хур-зар улыр.
Мәктәп йире катыг улыр,
Сүзләре аның татлыг улыр,
Мәктәп юлы гәүһәр улыр,
Сүзләре һәрбер җәүһәр улыр,
Мәктәптә торып тәгълим алган
Барча талиплар асыл улыр.
Аталарның билен бөккән,
Аналарның яшен түккән
Нәчарә зипа (пөхтә вә зифа?) шәкертләр вар
Мәктәптә дигән йирләрдә.
Мәктәптә торган шәкертләрнең
Алтын булыр китаплары,
Китаплардин тәфсир иткән
Асыл булыр остазлары.
Бу йирләрдин ул йирләргә
Очсам ирдем, очсам ирдем,
Очып, мәктәп йирләрегә
Йитсәм ирдем, йитсәм ирдем.
Остазларның хезмәтендә
Торсам ирдем, торсам ирдем.
Тәгълим алып, үз йиремгә
Кайтсам ирдем, кайтсам ирдем,

[3] Камай Гыйлем (Гыйльман) Хәйри улы (1901-1970) – танылган татар галиме, күренекле химик, профессор (1931), 1935-1937 нче елларда Казан университеты ректоры.
[4] Халиков Альфред Хәсән улы (1929-1994) – күренекле татар археологы, тарихчы, тарих фәннәре докторы.

Ата-ана догасыны
Алсам ирдем, алсам ирдем,
Ата-ана хезмәтендә
Торсам ирдем, торсам ирдем».

Китапның үзен алып булмады, карт теш-тырнагы белән ябышкан. Көн бик салкын. Ачы җил. Нәкъ көз көне кебек. Егетләр, мескеннәр, күшегеп беттеләр. Шулай да йорттан-йортка йөриләр, иренмичә йөриләр.

Зираттагы Ш.Мәрҗани оныгы өстендәге таш:

«Бәлдәи Казанда җәмигы әүвәлдә имам вә мөдәррис мулла Борһанеддин Мөхәммәд бине дамелла Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең әүладыннан талибел-гыйлем Габделгазиз (...) вафат улып ошбу кабердә мәдфүн улды. Сәнә 1893 миладия».

Бу авылда кульязмалар, нигездә, берничә бәете белән генә әһәмиятле. Төш вакытында башка авылга киттек. Төштән соң Аллабирде авылына килдек. 170 йортлык авыл. Колхоз рәисе – Рәхмәтуллин Хәсән Нигъмәтуллович.

Олы Әтрәчтә Гатауллин Хөснулла дигән кешеләрнең аталарында Аллабирде авылының тарихы булган, имеш.

Фатирга яхшы гына урнаштык. Көн бик җилле булганга, кичен беркая да чыкмадык.

24.07.1968.

Бүген, әгәр саташмаган булса, көн ачык, җылы һәм якты.

Колхоз бухгалтеры Садриның әнисе Мәхубҗамал әби Мөхәммәтшинага кереп, берничә кульязма алдым. Үлгән баласына багышланган шигырь (бер генә бит кульязма) бик тәэсирле генә икән. Бер төп китап – бәетләр җыентыгы.

Авылның мулласы булып йөргән Мирхатип Галиев дигән кешегә кердек. 5-6 гарәпчә китап алдык, иң карты – «Мишкат әл-әнвар». Зур форматлы 235 кәгазьле, 470 битле китап, яхшы гына кәгазьдә матур гына почерк.

Колофон: *«Тәммәт әл-Китабел-Мишкател-әнвар фи би-йәд ил-габдиз-зәгыйфил-хәкыйрь Сәгыйд бине Габдерраззак әл-Болгари мин һәҗрин-нәбәви сәнәтә 1190 вә фиш-шәһриш-шәүвәл вә йәүмәл-хәмис фи вактиз-зәваль вә фи карйәти Бәрәскә фи мәдрәсәти мулла Бикчәнтәй».*[5]

Шул ук битнең кырыенда бу сүзләр:

«1854 ел декабрьнең 10ында Борнаш мулла Сәгыйдеддиннән бу «Мишкател-әнвар»ны алдым. Бешлә (Пешлә) илендә Әхмәд Гобәйдулла угылы. Хакы 15 сум. Алла хәерле кылыр».

Китап башындагы бер биттә бу табышмак:

«Ул нә коштыр: дошманы булса, тышка чыгар,
Очар ирсә, агызындин утлар сачар,
Дөньяда ком йийебән, гомере кәчәр,
Тәне юктыр, җаны юктыр,
Тән тишебән, кан эчәр.
Җавабы: Йәдрәтел-мылтык яки бомба».

Төшкә кадәр шактый йөрелде. Малайлар да берничә әйбер тапканнар. Аллабирде

[5] Татарчага тәрҗемәсе: *«Мишкател-әнвар» китабы зәгыйфь, мескен бәндә Сәгыйд бине Габдерраззак әл-Болгари тарафыннан һиҗри 1190 елның шәүвәл аенда пәнҗешәмбе көнне кич белән Бәрәскә авылында Бикчәнтәй мулла мәдрәсәсендә [күчерелеп] тәмам булды».* – И.М.

авылы, бу яктагы күп кенә авылларга караганда, төзегрәк: йортлар да яңа, яшеллек дә шактый. Ләкин сугыш елларында бу авыл бик нык янган икән... (И мескен татар авыллары! Сезнең янмыйча калганнарыгыз булды микән?!) Зиратына менеп төштем. Борынгы ташлар юк. Әйтүләренә караганда, андый ташлар Әтрәч авылында күп булырга тиеш.

Кичкә колхоз рәисе Хәсән Рәхмәтуллинга кереп, аның әтисеннән калган китапларны карап, берничә кулъязма алдык. Арада «Шәрх әл-Мохтасар Викая»ның татарча тәрҗемәсе бар. Дөрес, ул шушы гасыр башында гына күчерелгән язма.

25.07.1968.

Бүген ачык булмаса да, җылы гына. Хуҗалар белән исәп-хисапны бетергәч, Әтрәч авылына килдек. Олы һәм Кече Әтрәчләр янәшә. Авыл Советы рәисе – Сибгатуллин Хөснулла. Колхоз «Вахитов» исемендә. Авылында (олысында) – 140 йорт һәм кечесендә – 120 йорт. Халык телендә таралган «риваять» буенча, бу авылның килеп утыруына 500-600 ел булган. Элек бу Әтрәчләрнең һәр икесендә икешәр мәчет, берәр мәдрәсә эшләгән.

Колхоз идарәсенә килдек: исерек башлы бер колхоз бухгалтеры. Бер сүз дә җүнләп сөйли белми. Гаҗәп, ничек итеп исәп-хисап эшендә шундый исерек утыра икән!

Шактый йөрдек, егетләр дә, мин дә, ләкин әллә ни юк. Монда да шул бер иске фаҗига – авыл урамнары тулысы белән янган еллар булган...

Күп кенә әйберләр саф дини язмалардан гыйбарәт. Бер кечкенә кәгазь кисәгендә мондый юллар бар, исеменә караганда «Хан кызы» кебек:

«Илаһи матур хан кызы бәете
Һавадин очып йөргән кош дәгелме?
Егетнең җаны сөйгән кыз дәгелме?
Бер кич бардым кыз катына – күзәттеләр,
Унике чукмар берлән озаттылар.
Бар, әйтеңез ярыма, кайгырмасын,
Сул кабыргам кыңгыр иде – төзәттеләр.
Хан кызы, ач ишегең, бән керәем,
Сәнең буең зифа, диләр, бән күрәем...»

Нәрсә бу? Шул бәет башымы? Әллә мөстәкыйль әсәрме?

Авыл Советы рәисе белән шактый коңгыргач, Олы Әтрәч өстендәге борынгы зиратка бардык. Кечерәк кенә бер мәйданда бик борынгы ташлар барсы да XIV-XV гасырдагы. Бик калыннар, бик зурлар, күбесендә зур-зур орнаментлар бар. Ләкин бу ташлар элек тагы да күп булганнар икән. Узган гасырларда, Ямбухчы чиркәве нигезенә алу өстенә, шушы елларда да бик күп ташлар югалганнар – кемнәрдер аларны урлыйлар икән. Саклау турында кайгыртасы иде!

Арып кайттык. Мөгаен, иртәгә кайтырга кирәк булыр. Җитәр инде...

Каюм абзый Кәримов дигән 80 яшьлек бер карт белән кичен бик озак чәйләшеп утырдым, болай карап торуга 60тан артык бирмәссең. Аның әйтүе буенча, мин бая барып карап кайткан зират тирәсендә элек көмеш акчалар, хәтта алтын тәңкәләр дә табыла торган булган. Малай чакта яңгырдан соң ул үзе дә барып табып кайта торган булган... Әйтүе хак булса, көмеш хәзинәлекләр табып баючылар да булган, имеш. Шул җирдә, риваять буенча, Мең Өй Чоңгалы (Шонгаты) дигән шәһәр булган...

Күрәсең, бу урында археологлар өчен эш табыла кебек. Кайткач, Альфред Халиков белән сөйләшеп карарга кирәк, бәлки, ул яхшырак беләдер.

Бер иске китап эчендә мондый колофон: *«Бу китапны язгучы Җиһанша бине Корбан мәрхүм угылы. Бу китапны яздым /870/ (?) нче елда тәмам укыгучылардин дога-и хәерләр өмет итеп. Яздым шәһри Казанда Яңа Бистәнең Шаһиахмәт хәзрәт мәдрәсәсендә. Кул тотты, каләм язды, кара төште, күз күрде, гакыл белде».*

«Кул тотты, каләм язды, кара төште, күз күрде, гакыл белде».

Моннан соң мондый «хат» китерелә: *Сез ки гыйззәтлү вә хөрмәтлү улып торгучы Мөхәммәд-Шакир мулла Садыйк угылына бик сагынып бик күп сәлам, вә әткәеңезгә бик сагынып бик күп сәлам, вә абыстумач[и]га бик сагынып бик күп сәлам, вә көлле (барлык) өй җәмәгатьләренә бик сагынып бик күп сәлам, вә әңкәемез хәзрәтләренә бик сагынып бик күп сәлам. Вә кирәк нәрсә әүвәл бер мичкә бал, вә ун кадак май, биш кадак сары май, сигез кадак атланмай, вә бер пот ак он, бер гөбе каймак, утыз бәлеш, кырык йөз (!) пилмән, мең сумса, өч йөз таба бәлеш, сигез йөз төче коймак, биш кадак шикәр, өч кадак яшел чәй, дүрт кадак простуй чәй, янә самавар, өч пар чынаяк, пар патнус, пар чәйнек, актыгында бикәч бик кирәк.*

Җүри әйтәм, кирәкми. Юк чакта тәмам булды...»

Моннан соң тагын бер хатның «болванкасы» китә дә, тәмамланмыйча өзелә... Йә Аллаһ, ач шәкерт нәрсә турында хыялланмаган!.. Язма якынча XIX гасыр азагына карый.

Корбангали дигән бер Әтрәчле мулланың язмаларында мондый сүзләр бар: *«1891 нче елда газизләр ташын урыс кулында[н] кайтардык, телеграм сугып».*

Бу Корбангали югарыдагы «хат»ның авторы Җиһаншаның атасы булып (димәк, кабер ташларын талау XIX гасыр азагында да дәвам иткән), моны әлеге «шәҗәрә» кисәге раслый: *«Олуг бабамыз мулла Мөслим, аның угылы Йосыф, аның угылы Корбангали, аның угылы Җиһаншаһ».*

Егетләр бүген дә киного киттеләр, ә мин, принцип буенча, йокларга яттым.

26.07.1968.

Бу авылда Зәйнәп апа Миңнуллина дигән әбидә торган идек. Ярлы булса да, нурлы иде... Исәп-хисапларны бетергәч, егетләр белән кечәге зираттагы ташларны карадык: егылганнары белән бергә 18 данә.

Ә сәфәр турында мондый нәтиҗәләрне әйтергә мөмкин[6]:

1. Сәфәр күңелле узды. Табышлар да яхшы, мул һәм төрле. Иң күп табышлар дип, шәкерт дәфтәрләрендәге бәетләрне күрсәтергә була: дистәләгән дәфтәрдә, төрле нөсхәләрне исәпләгәндә, биш-алты дистә тулы бәет нөсхәсе бар... Ә монументаль әсәрләрнең кулъязмасыннан исә «Нәһҗел-фәрадис», «Йосыф Зөләйха», «Рәүнакъ әл-ислам», «Нәваи диваны», «Чупан-намә» һ.б.ны күрсәтергә мөмкин. Шулай ук гарәпчә бик борынгы кулъязмалар да бар. Якынча XV-XVI гасыр нөсхәләре...

2. Табышларның иң күбесе Буа районының Кильдураз, Кул-Черкене, Яңа Чәчкап, Әхмәт, Яңа Тинчәле авылларында булды. Чүпрәле районы авыллары исә ул хәтле

[6] Миркасыйм Госманов еллык сәфәргә гомуми нәтиҗә ясый. Тау ягы сәфәренең беренче өлеше «Бозау тиресенә язылган кәгазьләр булган» исеме астында журналыбызның март санында (2022 ел) басылып чыккан иде. – *Ред.*

түгел, дөрес, терлек авыруы булу сәбәпле, карантин хөкем сөргәнлектән, шактый гына авылларга барып булмады. Зур өметләр көткән Тәтеш районы авылларында исә ул хәтле табышлар очрамады. Ә Апас районына быел өлгермәдек.

3. Саф тарихи кульязмалардан, әлеге Мөслими сафсатасын игътибарга алмаганда, Яңа Тинчәледә табылган Касыйм мулла тарафыннан язылган «Яңа Тинчәле һәм аның тарихы» дигән 23 шәҗәрәле авыл тарихын күрсәтеп була. Бу – безнең табышлар арасында иң әһәмиятлеләреннән берсе.

4. Быел барылмый калган берничә зур авыл бар – Иске Тинчәле, Суыксу, Шәйморза һәм Кече Чынлы. Бу авылларны мин юри калдырдым – берәр студентны махсус җибәрер өчен.

5. Егетләр дә яхшы йөрделәр. Миңа бигрәк тә Җәүдәт Дәрзаманов күбрәк ошады: наив кына булуына карамыйча, шактый тырыш егет, язмаларны укып маташуы да өметле генә. Ә Мөхәммәди Мөхәммәтшин исә гаҗәп җиңел – бик ваемсыз, җилкуар сыман.

6. Халык тормышына килсәк, тормыш шактый төзәлгән, бик мул, бик бай торган авыллар да бар. Иген дә быел бик яхшы, тик яңгырлар гына комачауламаса (ә хәзергә яңгырлар бик күп булды) ярар иде.

Вәссәлам...

***

Бер китапның иң ахыргы ягында, шәһре Болгарга баргач, нинди догаларны ничек укырга дигән «күрсәтмә» бар, башлана: *«Вә нәкыльдер ки, мәшаех Хәсән Болгаридин һәркачан[7] Болгары Шәрифкә зиярәт кылырга килгүчеләргә[8] мәгълүм булсын ки, ни кәйфи[я]тлә зиярәт кыласы вә ничәнче (?) мәэмүрдер ки». Игенчеләр пире Адәм, галимнәр пире мулла Җәлалетдин – рәхмәтуллаһи галәйһи...»*

Янәсе, манарага менеп, азан әйтеп, манара ягында намаз укырга, аннары изгеләр зиратына барып, тагын бер кат намаз, күпсанлы догалар, күпсанлы салаватлар (кайчан кайсы кул кайда буласы – барсы бар!)

Хәсән шәйх, Айдар хан, аның кызы Туйбикә әрвахларына дога багышларга киңәш итә... Тагын бихисап догалар...

***

Рабига Мингазовадан алынган зур гына күләмле «Шәрхе Викая» исемле китапта мөһер бар: *Гыйрфанетдин бине мулла Җәлалетдин әл-Болгарый әл-Казанлы 1310.*[9]

Гомумән, бу мөһер белән китаплар шактый очрый. Китап үзе әйбәт кенә оформит ителгән, бизәлгән. Барлыгы 308 кәгазь.

***

Гаҗәп хәл – һәрбер китапны язган кеше үзен шулай «Болгари» дип атый.

Барлыгы 130лап китап. Бик борынгылары булган кебек, бик яңалары да бар. 20ләп китап һәм кечкенә дәфтәрне аерып куйдым. Алар хәзергә үземдә торырлар. Көзен, яхшылап карап тикшергәч һәм күчергәч, тапшырырмын. Күчерү аерым дәфтәргә булыр, бигрәк тә бәетләр һәм шигырьләр... «Яңа Тинчәле» тарихын исә бөтенләй аерып күчерергә кирәк булыр.

Менә тикшереп чыгу бүген, ягъни август 1ендә генә тәмам булды.

*Текстны басмага **Диләрә Госманова** һәм **Ильяс Мөстәкыймов** әзерләде.* ■

---

[7] Һәркачан – һәркайчан.
[8] Килгүчеләргә – килүчеләргә.
[9] Гарәп хәрефләре белән язылган.

Без кем яки Бер китап тирәсендә уйланулар

Индус Таһиров, академик

Тарихчы-галим Газиз Гобәйдуллин (1887-1938): «Дөньяда бер тамырдан барлыкка килгән бер генә чиста халык та юк...»

I. Татарлыкның башы кайда?

Халыкларның чыгышын тикшерү – катлаулыдан-катлаулы проблемаларның берсе. Борынгы яки урта гасыр кабиләләрнең күбесе һәрвакыт хәрәкәттә булып, күршеләре белән төрле рәвештәге мөнәсәбәтләрдә торганнар. Монда үзара аңлашып тынычлыкта яшәү дә, канлы сугышлар да булган. Боларның һәммәсе дә – кан алышуларга китерә торган гаммәлләр.Кыпчак һәм славян, хәзәр һәм урыс, татар һәм фин-угыр мөнәсәбәтләре әнә шуны раслыйлар.

Дөньяда бер тамырдан барлыкка килгән бер генә чиста халык та юк, дип язган күренекле тарихчыбыз Газиз Гобәйдуллин. Шунлыктан ул, халыкларның чыгышын билгеләгәндә, аларның һәр тамырын җентекләп тикшерү зарур дип санаган. Һәм, бу, чыннан да, шулай.

Ул гасырлар буе дөньяны иңләп яшәгән татарларга бигрәк тә туры килә. Кайда гына калмаган татарның эзләре: Испания, Италия дисеңме, бүгенге Русиянең көньягымы яки төньягымы, көнбатышымы, әллә көнчыгышымы – кая карасаң да –

татар эзләре. «Поскреби любого русского и в нем найдешь татарина», – дип, Наполеон юкка гына әйтмәгәндер. «Мин тарихны тарихи әдәби әсәрләрдән өйрәндем», – дип тә өстәгән әле ул. Болары кайберәүләребезнең йөзенә чыккан кушымталар гына.

Ә бүгенге татарны үзара төрле мөнәсәбәтләрдә торган уртак тамырлар барлыкка китергән.

«Татар кем ул?» – дигән сорауга төрлечә җавап бирәләр. Берәүләр аны – болгар, икенчеләре Алтын Урда татарлары дип фаразлыйлар. Без әле алга таба Болгар һәм Алтын Урда чорларыбыз хакында сүз алып барырбыз. Ә хәзер исә, хөрмәтле укучылар, сүз борынгы татарлар турында булыр.

Минем кулымда ике китап. Аларның берсе – «Тысяча лет из истории татар», икенчесе «Татары: История возникновения великого народа» дип атала. Болар – Эдвард Паркер китабының инглизчәдән русчага тәрҗемәләре. Беренчесе 1895 елда ук язылган, икенчесе – шул ук китапның азрак үзгәртүләр кертелгәне 1911 елда дөнья күргән. Аларның беренчесен – АКШта яшәүче күренекле галим Вил Мирзаянов, икенчесен Т.Ю.Любавская тәрҗемә иткән.

Китапларның беренчесен – 2003, икенчесен 2010 нчы елларда «Идел-Пресс» нәшрияты бастырып чыгарган. Алар эчтәлекләре белән тәңгәл. Ләкин Мирзаяновның тәрҗемәсе тулырак, ул авторның үз шәрехләүләре, аңлатмалары белән баетылган. Тәрҗемәләрнең икесе дә беравыздан диярлек татарның бөеклеге, аның данлыклы башлангычы турында сөйли. Алар белән танышканда татарларның төркилек башында торганлыгына, аларның иң затлы нәселләреннән икәнлегенә инанасың.

Кем ул Эдвард Паркер? Һәм ул нилектән кытай яки монгол турында түгел, ә алар белән янәшәдә гомер кичергән татарлар турында язган?

Э.Х.Паркер – мәшһүр дипломат һәм тарихчы. Ул – 1849 елда туып, 1926 елга кадәр яшәгән бер инглиз галиме. Э.Паркер күп еллар буена Кытайда дипломатик



Инглиз галиме Эдвард (Эдуард) Харпер Паркерның (1849-1926) русча нәшер ителгән «Татары: История возникновения великого народа» китапларының тышлыклары

хезмәттә булып, кытай телен камил рәвештә үзләштергән, татарларга караган кытай чыганакларын ныклап өйрәнгән киң карашлы шәхес булган.

Әйдәгез әле, хөрмәтле укучылар, Эдуард Паркерның китабына күз салыйк.

Анда сүз күп гасырлар дәвамында Кытай империясенең бердәнбер күршесе булган татар кабиләләренең Азия далаларындагы дәһшәтле дәүләтләре турында бара.

Китапта тупланган фактлар халкыбызның моннан 25 гасыр ук элек татар атамасындагы бер кабилә булып, соңрак аның тарихка төркиләр исеме белән кергән кабиләләр берлеген оештыруы турында. Шулай ук әлеге җыелмада татар берлегендә һуннарның аерым зур урын алып торганлыгы да яктыртыла.

Ә менә татарлар үзләре, 1247-1318 нче елларда яшәгән Рашидеддин язуынча, 70 000 йорт тәшкил итеп, тутукулиут, алчи, чаган, терат, куин, баркуй, дербен, дутау, алухай кебек кабиләләрдән торганнар[1].

Кытай чыганаклары бу җыелма тугандаш кабиләләрне, алар төзегән дәүләтләрне «хиен-ну» дип тә атаганнар. Шул ук вакытта аларга карата «Татар ыстан», «татар» дигән төшенчәләр дә еш кулланылган.[2] Ә «төрки» сүзе тик безнең дәвернең V гасырында гына әйләнешкә кергән[3].

Безнең дәвернең ахырында хәзерге Кытай тирәсендәге төрки сөйләмле кабиләләр диңгезендә Гансу (Синцзян), Ляо (Төньяк Кытай) атамалы ике татар дәүләте булган. Алар арасындагы 2,5 мең чакрым ара татар далалары дип йөртелгән.

Шушы урында азрак тукталып, Паркерга кадәрге тарихчыларның төрки тарихка керткән өлешләрен әйтеп китмәсәм, гаделлеккә хыянәт булыр иде. Әйе, Паркерга кадәр дә, аннан соң да борынгы тарихыбызга караган мәгълүматлар күренгәләп торган. Тик аларга тиешле игътибар гына бирелмәгән.

Төркиләрнең башлангыч тарихларын өйрәнүне беренчеләрдән булып чуаш-монах Н.Я.Бичурин (Иакинф) башлап җибәргән. Шушы максатчан һәм намуслы шәхес хакындагы мәгълүматларны күренекле дипломат-тарихчы Йолдыз Хәлиуллин язмаларында укырга мөмкин.

Н.Я.Бичурин, күптөрле чыганакларны өйрәнеп, Ухуань йортының тарихын ачыклаган һәм шушы йортның нәсел башы Татар хан икәнлеген дәлилләгән. Шундагы кабиләләрнең яшәү рәвешләрен дә тасвирлый алган.

Н.Я.Бичурин сурәтләгән кабиләләр ишекләре көнчыгышка таба ачыла торган түгәрәк йорт-тирмәләрдә яшәгәннәр. Аларда, аталары үлгәннән соң, үги аналарына, абыйларыннан соң, аларның хатыннарына өйләнү гадәте булган. Бу нәселне саклап калу максаты белән эшләнгәндер, күрәсең.

Шушы татарларның яки ухуан-һуннарның ашый торган ризыклары – ит, эчемлекләре кымыз булган. Алар, тарихта беренчеләрдән булып, тимер эретә башлаганнар, алтын эшкәрткәннәр, иген иккәннәр, шул исәптән, тары һәм шуңа охшаш культуралар да үстерә белгәннәр. Нәкъ башка тугандаш кабиләләр кебек үк, ат өстендә килеш тә оста итеп ук атканнар, башкалардан бик гайрәтле булулары һәм сугышчанлыклары белән аерылып торганнар.

Тик менә гайрәтле һәм кызу канлы булып, бер-берсенә каршы сугышсалар да, имчәктәш туганнар беркайчан да бер-берсенә кул тидермәгәннәр. Аларда анага карата аерым ихтирам хөкем сөргән. Гомумән, хатын-кызның гаиләдәге роле зур

[1] Рашид-ад-дин. Сборник летописи, т.1, кн.1. – С.305.
[2] Э.Х.Паркер. Тысяча лет из истории татар. – Казань: «Идел-Пресс», «Слово», 2003. – С.48.
[3] Шунда ук, 5 б.

булган. Алар матур итеп чигә һәм тегә белгәннәр. Ирләр, сугыш проблемаларыннан гайре, барлык мәсьәләләрне хатын-кыз киңәше белән хәл итә торган булганнар.

Эдвард Паркер да әлеге кабиләләрне нәкъ шул рәвештә тасвирлаган. Ләкин Бичурин ахыр чиктә бу кабиләләр монголлар дигән ялгыш фикергә килгән. Паркер исә, аннан аермалы буларак, аларның төркилекләрен исбатлаган, шуларның башлангычындагы татарларның нинди кабиләләрдән торганлыкларын ныклап тикшергән һәм шуны исбатларга тырышкан.

Кытай теле белгече, сәяхәтче, милләте буенча чуаш Иакинф (Никита Яковлевич Бичурин, 1777-1853)

Мин, тырышкан, дип әйтәм, чөнки Паркер үзе атамаларны бик сак куллана. Мәсәлән, ул Европага килгән һуннарны хиен-нуларның дәвамчысы дип өздереп әйтми, ләкин икесенең дә, Кытайдагылары кебек үк, «ат өстендә йөреп, ит ашап һәм кымыз эчеп» яшәүче икәнлекләрен генә күрсәтә. Шуннан соң, һәр укучы үзе нәтиҗә ясарга тиеш, дип билгеләп үтә. Ә китапка кереш сүзендә хиен-ну, скиф, һун һәм төркиләрнең берүк кабиләләрнең төрле тарихи чорлары икәнлеген ассызыклый.

Э.Паркер шул ук вакытта Копенгаген профессоры В.Томсенның болар сөйләшкән телнең төрки икәнлеген исбатлавы, аннан соң Петербург профессоры В.Радловның төрки телне моннан 1200 ел элеккеге рәвешендә торгызуы турында да яза.

Шунысы игътибарга лаек: Европаны дер селкеткән һуннарны да Аммиан Марцелин, Приск кебек көнбатыш авторлары да нәкъ шушы рәвештә тасвирлаганнар. Хәтта, кызып китеп, кайвакыт бер-беренә кылыч күтәрү гадәтләре дә нәкъ Бичуриндагыча, Паркердагыча.

Ләкин Бичурин һәм башка тарихчылар шактый күп чыганакларны белмәгәннәр. Аларның анда үтеп керү мөмкинлекләре азрак булгандыр, күрәсең. Ә менә бөек империя дипломаты булган Паркерның андый мөмкинлекләре җитәрлек булганлыгы әсәренең һәр битендә диярлек чагылып тора. Шушы мөмкинлекләр аңа «татар» атамасының нидән гыйбарәт икәнлеген төгәлрәк ачыкларга юл ачкан.

«Мин абруйлы кытай авторларының оригиналларын сүзгә-сүз тәрҗемә иттем, кульъязмалар белән чагыштырып тикшердем һәм алар 7 мең данәдән дә артып китте», – дип язган Паркер китапка кереш сүзендә. Әсәрнең һәр битендәге фактлар тыгызлыгы бу сүзләрнең дөреслегенә дәлил булып тора.

Мин Бичурин һәм башка тарихчыларның борынгы тарихыбызга багышланган әсәрләренә игътибар җитенкерәмәвен күрсәтеп киткән идем инде. Ә бит Паркерның үзенә дә тиешле игътибар булмый. Китабы 1895 елны языла, берничә басмасы дөнья күргәч, хәтта кытай теленә дә тәрҗемә ителгәч тә, ул игътибар үзәгеннән читтә кала биргән. Революциягә кадәр генә түгел, бигрәк тә совет

Безнең мирас №5 май 2022

чорында. Йолдыз Хәлиулин язганча, аңа тиешле бәяне тик В.В.Бартольд һәм В.П.Алексеев кына бирә алган. Соңгы елларда ул С.Кляшторный хезмәтләрендә дә еш искә алына.

Әгәр дә мин Хәлиуллинның Паркер хезмәтләренә игътибар һәм тиешле бәя бирмәүләре өчен татар тарихчыларына үпкә белдерүе турында әйтми үтсәм, бу һич кенә дә дөрес булмас иде. Туры әйткән туганына да ярамый, диләр. Ләкин без бу очракта дөрес сүзгә җавап юк икәнлеген аңлап, милләттәшебезнең шушы үпкәсен аңа рәхмәт белдереп кабул итәргә тиешбез.

Көнбатыш галимнәренең күзләрен евроцентризм томалаган булса, Русия тарихчыларының күпчелеге бөекдержавачылык томанында йөзгән һәм, кызганыч, әле дә йөзә бирә.

Ничек инде ул ниндидер коллыкта, ә соңрак булыр-булмас автоном хокукта яшәгән татарлар бөек булсыннар?! Ничек инде аларның Ганнибалга тиң гаскәр җитәкчеләре булсын?! Европалыларның да, шулай ук русларның да күңелләре һич кенә дә моның белән килешә алмаган, күрәсең...

Тартария Ганнибалы, һуннар империясенә нигез салучы Модэ-Баһадур (Мете хан, б.э.к. 234-б.э.к. 174 нче елларда яшәгән) бюсты

Ә бит чынында Модэ-Баһадурны Тартария Ганнибалы дип юкка гына атамаганнар. Аның ил һәм гаскәр белән камил рәвештә идарә итү системасын кытайлар да, соңрак монголлар да тикмәгә генә үзләренә өлге итеп алмаганнар. Паркер шушы системаны җентекләп тикшергән һәм аңа югары бәя биргән. Ул үзенең актык көннәренә кадәр евроцентризмга каршы көрәш алып барып, хиен-ну, скиф һәм һуннарның төрки телле кабиләләр икәнлеген исбатлый алган.

«

Европаны кәбестә тозларга һуннар өйрәткән!

Паркер Җания-Баһадурның үткән дәвернең 211 елында 320 меңлек кытай армиясен тар-мар итүен Аттиланың Рим гаскәрен тар-мар итүе белән чагыштыра. Бу уңышларны ул борынгы татарларның күпләргә караганда гайрәтлерәк булулары, ат өстендә килеш оста сугыша белүләре, үзләренә генә хас сугыш стратегияләре һәм тактикалары булу белән аңлата.

Аныңча, Кир, Александр (Македонский), Дарий, Керкс, Цезарь һәм Помпей кебек полководецлар Баһадур белән чагыштырырлык та түгелләр. Ул, аларга караганда, күпкә өстенрәк.

Баһадур Кытай императорына язган бер хатында үз кул астына барлык татарларны яки «ат өстендә җәядән ук атучыларны» җыйдым дип яза. Сүз 1911 елга кадәр Кытай империясенә кергән (Тибеттан башка), соңрак төркиләр дип аталган кабиләләр яшәгән җирләр турында бара.

Паркер татарлар төзегән дәүләтләрдә җинаятьчелекнең юк дәрәҗәсендә икәнлеген ассызыклап күрсәтә. Аның язуынча, монда кешегә карата җинаять кылучылар үлем җәзасына тартыла торган булганнар. Хөрмәтле укучылар, күрәсез ки, борынгы бабаларыбыз кеше кадерен бик яхшы белгәннәр[4].

Мондагы җайга салынган халык санын алу системасы да шул турыда сөйли. Бу дәүләти чара Алтын Урдада дәвам иткән һәм татарлар тарафыннан соңрак рус җирләренә дә кертелгән. Җанисәп тарихының башы әнә шунда, хөрмәтле укучыларым!

Паркер әсәрендәге татарларның кытайларга ясаган йогынтылары, аларның Пекинны яулап, император тәхетенә утыру фактлары, императорларның татар традиция һәм гореф-гадәтләрен үзләштерүләре, үзара никахлары турындагы мәгълүматлар күпләр өчен яңалык булыр дип уйлыйм.

Алай гына да түгел, кытайлар төркиләрнең көй-моңнарын да ныклап үзләштергәнәр. 1989-1990 нчы елларда Казан университетында стажировка үткән кытай профессоры Чянь бин: *«Без сезнең музыкагызны алдык һәм аны тирә-якка тараттык, хәтта Япониягә кадәр җиткердек»,* – дип әйтә иде. Бу, чыннан да, шулай. Галим Марсель Әхмәтҗановның хезмәтләрендә кытай императорларының татарлар янына аларның музыкасын язарга махсус белгечләр җибәрүләре турындагы мәгълүматлар бар.

Ә менә мәшһүр Зәки Вәлиди төрки музыканы казан татарлары саклап калганлыгын дәлилли. Моның сәбәбен ул заманында Казан тирәсенә Алтай якларыннан күчеп килгән татар кабиләләренең урнашуы белән аңлата[5].

Ләкин, ничек кенә булмасын, кытайларның үзенчәлекле цивилизация тудырып, дөньяга бик күп яңалыклар керткән халык икәнлеген онытырга ярамый. Татарлар үзләре дә алардан бик күп нәрсәләргә өйрәнгәннәр. Мәсәлән, җир эшкәртү, иген игү, бакчачылык һөнәрләренә. Хәтта кәбестә саклау рәвешенә дә. Тик, кытайлардан аермалы буларак, һуннар кәбестәне дөге аракысына салып түгел, ә тозлап саклый торган булалар. Татарларның бу ысулга күчүләре яхшы аңлашыла булса кирәк. Алар хәрәкәтчән, һәрвакыт диярлек походта. Ә анда аракылы арбалар белән йөреп булмый. Шушы кәбестә тозлау ысулын европалылар һуннардан өйрәнә. Хәтерегездә калдырыгыз, хөрмәтле укучылар, Европаны кәбестә тозларга һуннар өйрәткән!

Билгеләп үткәнемчә, Паркер борынгы татарларны батыр, күпләргә караганда гайрәтлерәк, ат өстендә килеш оста сугыш алып бара белүчеләр рәвешендә тасвирлый. Аларның үзләренә генә хас сугыш стратегиясен һәм тактикасын булдырганлыкларына басым ясый.

Әйе, бу – татарның борынгы бөеклек чоры. Ә әлеге чор кайчан беткән? Минемчә, Паркер үз әсәрен юкка гына Чыңгыз дәверенә җитү белән туктатмагандыр. Бәлки, татарларның җиңү тантаналарын тасвирлаган авторның бөек халыкның Чыңгыз тарафыннан җиңелүе турында язарга кулы күтәрелмәгәндер…

Ахыры киләсе санда ■

---

[4] Н.Я.Бичурин (Иакинф). Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. – Издательство Академии наук СССР. – Москва-Ленинград, 1950. – С.142-143.

[5] Заки Валиди Тоган. Воспоминания. Борьба мусульман Туркестана и других восточных тюрок за национальное существование и культуру. – М., 1997. – С.261.

ФӘРИТ МӨХӘММӘТШИНГА 75 ЯШЬ

Фәрит Мөхәммәтшин: «Иң мөһиме – кеше булып калу!»

(ТР Дәүләт Советы рәисе Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшинның төрле елларда (2007-2017) биргән интервьюларыннан)

«Хакимият – үз уйларыңны тормышка ашыру мөмкинлеге. Тик мин беркайчан да бернинди очракта да аны уңайлылыкка, җайлылыкка ирешү дип карамадым. Ул килә дә китә. Хакимлекнең сиңа вакытлыча гына бирелүен беркайчан да онытмаска кирәк. Хакимият гомерлеккә бирелми. Иң мөһиме – кеше булып калу».

«Иң яхшы депутат – комитет, сессия утырышларын бер дә калдырмый, актив катнаша, үз фикерен белдерә, тәкъдимнәр кертә торган депутат. Иң яхшы депутат – әйткән белән генә ризалашып утырмыйча, сиңа каршы төшеп һәм, шуның белән беррәттән, үз фикерен дәлилләп, яңа тәкъдим дә кертүче депутат. Теләсә нинди закон берәр максатны күзаллый. Максат – бер, аңа ирешү юллары гына төрле. Коллегаларың арасында, мин бу юлда шикләнәм, менә болай карап карыйк әле, дип әйтүче кеше бар икән, ул – уйлаучы, кайгыртучан депутат. Андыйларны бик хөрмәт итәм».

«Милли телләрне саклау һәм үстерү проблемалары күп илләрдә бар. Үзебездә, Татарстанда, татар телен саклап калачагыбызга минем бер шигем дә юк. Элек куркыбрак йөри идек. Бүген республикада андый куркыныч юк дип әйтәсе килә. Ник дигәндә, татар гаиләсендә туган балалар бернинди мәҗбүр итүләрсез татар теленә тартыла башладылар. Ә менә инде милли татар университетын да ачып җибәрсәк, иншәАллаһ, минемчә, бу проблема тагын да киңрәк чишелеш табар. Мәктәпләрдә татар телендә укып чыккан яшь кешегә университет системасында укырга мөмкинлек туса, татар теленең дәрәҗәсе, кадере бермә-бер артыр дип ышанам».

«Тормыш дәресләре гаиләдә бирелә. Тәрбия иң элек ана белән атадан килә: өйдә үзеңне ничек тотасың, тормышка карашың нинди, балаларыңны эшкә ничек өйрәтәсең... Минемчә, хатын-кыз, әни булган кешенең бурычы – кыз баланы идән юарга, кер юарга, кер үтүкләргә, тегәргә, кухня тирәсендә аш-су пешерергә өйрәтү, аны тормышка тиешенчә әзерләү. Ир баланы тормышка әзерләү исә – әти кешенең бурычы: авырлыкларны ничек җиңеп чыгарга, көрәкне ничек тотарга, чүкеч белән ничек кадак кагарга өйрәтү. Бала мондый беренче дәресләрне бернинди мәктәптә дә ала алмый. Аны әти белән әни бирергә тиеш. Хәзер бит барысын да мәктәпкә сылтап калдырабыз. Имеш, мәктәп карамый. Мәктәп ул син өйдә биргән дәресләрне ныгытып, белем генә бирергә тиеш, минемчә. Төрле яктан белем бирергә. Ә тормышка әзерләү ул –гаилә бурычы».

«Гаилә – җәмгыятьнең нигезе ул. Гаилә кыйммәтләрен еш үзгәртеп торсаң, миңа калса, фундамент какшаячак. Ул – законнар беркайчан да үзгәрмәскә тиешле үзенчәлекле дәүләт. Традицияләр белән яшәргә тиешле дәүләт. Әйтик, синең үзеңә инде – 70, улыңа 50 яшь тулган, ә син әле һаман үзеңне аның өчен җаваплы дип саныйсың. «Әти нәрсә әйтер?» – дигән уй, юк-юк та, әле дә башыма килеп ала. Үземнең улымда да шулай дип уйлыйм. Бу һәр нормаль гаиләдә тәрбияләнгән кешедә булырга тиешле нәрсә дип саныйм. Бер-берең өчен һәм бер-берең кар-

шында җаваплылык. Кайберәүләр моны артык кайгырту дип атар, дөрес түгел, дияр. Минемчә, җаваплылык хисе булу һәм аның киләсе буынга да күчүе – зур нәрсә. Һәр шимбә балаларың һәм оныкларың белән күрешү традициясе булу – тагын бер искиткеч әйбер. Син ул очрашуларда гаилә кыйммәтләрен киләсе буынга тапшырып калдырасың. Оныкларың бу мөнәсәбәтләрне күрә, гаиләдә ата-анага игътибар нинди булырга тиешлегенә өйрәнә. Оясында ни күрсә, очканында шул булыр, дип юкка гына әйтмәгәннәр бит. Без шуңа ияләштек, шунсыз яши алмыйбыз. Әгәр иртәнге сигезенче яртыда һәм кич эштән соң кызыбыз әнисенә шылтыратмаса, без борчыла башлыйбыз. Улым көн дәвамында миңа бер шылтыратып алмаса – шул ук хәл. «Балалар шылтыраттымы?» – Луиза белән бер-беребезгә көн дә бирелә торган гадәти сорау бу. Без оныкларның өй эшләрен ничек әзерләвен, контроль эшләрне ничек эшләвен белеп-белешеп торабыз».

«Бәхетнең нәрсә икәнен бер сүз белән генә әйтеп булмыйдыр, һәрбер көннең үз бәхетле минуты, бәхетле сәгате бардыр, һәр гомернең үзенә генә хас бәхетле көннәре, атналары, айлары бардыр. Матур гаилә корып җибәрсәң дә, бәхетле саныйсың үзеңне. Укуларыңны яхшы гына тәмамлап, диплом алган көннәр дә – бик бәхетле көннәр. Минемчә, инде дөньяга тугансың икән, синең төп вазыйфаң – гаилә корып, халкыңа хезмәт итеп, балалар үстереп, киләчәк буыннарга белемеңне, тәҗрибәңне калдыру. Ә инде бүгенге эшләп йөргән көннәреңдә үзең телəгән, яраткан эшең булса, аңа ашкынып барсаң, арып-талып эшләгәннән соң, ашыгып сине көткән гаиләң янына кайтсаң, шуннан да зуррак бәхет юктыр инде, минемчә».

«Үз эшенең маһиры...»

(Күренекле шәхесләребез – Фәрит Мөхәммәтшин турында)

Гариф Ахунов (1925-2000),
Татарстанның халык язучысы:

«Мин Фәрит Мөхәммәтшинны Әлмәттән үк беләм. Нефтьчеләребез башкаласында язучылар оешмасын җитәкләгәндә, ул инде җаваплы урыннарның берсендә эшли иде. Мин үзем кешене бер күрүдә таный алам. Ә Фәрит Хәйруллович әүвәл ачык күңелле, ягымлы-мөлаем булуы белән үзенә җәлеп итте. Гомумән, табигать аңа кешелеклелек сыйфатларын да, буй-сын күркәмлеген дә кызганмаган. Тора-бара мин аның үз эшен бик төгәл белүен, хезмәттәшләренә карата таләпчән һәм кайвакыт яхшы мәгънәсендә кырыс булуын, башкаларны ихлас ихтирам итүен, үзара сөйләшкәндә төчеләнергә яратмавын якыннанрак аңладым. Республикабызның Югары Советын җитәкләгәндә дә, Премьер-министр вазыйфаларын башкарганда да Фәрит Мөхәммәтшин, иң беренче чиратта, үз эшенең маһиры, югарыда әйтеп үтелгән сыйфатларын тоныкландырмаучы булып кала белде».

Туфан Миңнуллин (1935-2012),
Татарстанның халык язучысы:

«Миңа аның иң ошаган сыйфаты – аның белән рәхәтләнеп авылча сөйләшеп була. Шаяртып әйтелгән сүзләрне аңлый, урынсызрак сүз ычкындырсаң, гафу итә белә.

Гаҗәеп тырыш, максатчан кеше. Ул баштарак татар телен әйбәт үк белми иде. Хәзер туган телебездә иркен сөйләшә, референт язып биргән чыгышларны кәгазьдән укымыйча сөйләү дәрәҗәсенә иреште. Кайсы халык баласы икәнен аңлый. Әгәр дә теге яки бу сүзнең тирән мәгънәсен аңлап бетерми икән, сорарга да оялып тормый. Югыйсә кайбер түрәләр дөньядагы бөтен нәрсәне дә беләбез дип уйлыйлар: язучыны – китап язарга, көтүчене – көтү көтәргә, футболчыны – туп тибәргә, академикны фәнни ачыш ясарга «өйрәтәләр». Андый чакта без дәшми генә елмаеп утырабыз. Фәрит Хәйрулловичтан минем андый акыл сатулар ишеткәнем булмады. Үз эшенең авырлыгын, җаваплылыгын белгәннәр бүтәннәрне өйрәтергә алынмый».

Роберт Миңнуллин (1948-2020),
Татарстанның халык шагыйре:

«Кайнар заманның да, казанның да
Син эченә кереп кайнадың,
Мәскәүнең дә көен көйләдең син,
Казанның да җаен җайладың.

Болай гына тормас дөньялары,
Килми калмас башка патшалар.
Кайтмый калмас безгә мөстәкыйльлек,
Ансын инде эшләр башкалар.

Тормыш дәвам итәр моннан соң да,
Безнең картаюга карамас...
Ул дәверләр генә кире кайтмас,
Синең чәчләр генә каралмас.
25 октябрь, 2003 ел»



Индус Таһиров (1936),
академик:

«Миңа аны төрле вазгыятьләрдә күрергә туры килде. Сессия вакытларында да, рәсми очрашулар вакытында да үзенә тугрылыклы булып калды. Аның нотыгы һәрвакытта да мантыйклы, шуңа күрә җиңел кабул ителә. Кешеләр белән мөгамәләсе һәрвакыт яхшы һәм аларны ихтирам итә, әңгәмәдәшен тыңлый белә.

Фәрит Мөхәммәтшинның киләчәккә планнары күп. Аларның тормышка ашырылачагына без ышанабыз. Аның искиткеч эшлекле сыйфатлары, көчле рухы һәм уңышка ышанычы – моңа гарантия».

(Фотосурәтләр Ф.Мөхәммәтшинның гаилә архивыннан алынды.)
*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

«Безнең мирас» котлый!

Танылган шәхесләребез – дәүләт эшлеклеләре, язучылар, галимнәр, журналистлар һәм сәнгать әһелләре май аенда үзләренең гомер бәйрәмнәрен билгеләп үтә. Менә алар:

1 май – язучы, рәссам, Г.Державин исемендәге премия лауреаты (2014), Казан шәһәре тумасы, 2000 елдан Америкада яшәп иҗат итүче **Майя Диас кызы Вәлиева**га 60 яшь (1962);

9 май – шагыйрь һәм язучы, 2008 елдан ТР язучылар берлеге әгъзасы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Р.Төхвәтуллин һәм С.Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр иясе, Түбән Кама районының Түбән Чаллы авылы тумасы **Әхәт Хәбибуллин**га (Габделәхәт Габделхәй улы Хәбибуллинга) 70 яшь (1952);

21 май – актер, режиссер, педагог, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТРның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, Казан шәһәре тумасы **Фәрит Рәфкать улы Бикчәнтәев**кә 60 яшь (1962);

22 май – дәүләт эшлеклесе, сәясәт фәннәре докторы, РФ Технологик фәннәр академиясе академигы, ТР Дәүләт Советы рәисе, Әлмәт шәһәре тумасы **Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшин**га 75 яшь (1947);

22 май – язучы, драматург, тәрҗемәче, журналист, 1995 елдан ТР Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстан Язучылар берлегенең Ш.Маннур исемендәге әдәби премия иясе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (2000), Татарстанның Мамадыш районындагы Арташ авылы тумасы **Нәзифә Харис кызы Кәримова**га 75 яшь (1947).

Олуг затларыбызның барысын да юбилейлары белән ихластан котлыйбыз һәм аларга саулык-сәламәтлек, иминлек, иҗат уңышлары теләп калабыз! ■

Бүгенге имам – татарның рухи яңарыш әйдаманы

Данис Шакиров, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе

Бөтенроссия дин әһелләре җыены быел 12 нче мәртәбә оештырыла. Җыенның темасы – «Милли тормыш һәм дин». Аңлашыла ки, әлеге ике төшенчә татар халкы өчен аерылгысыз. Бөтендөнья татар конгрессы – Россия күләмендәге татар дин әһелләрен бер канат астына туплый алган бердәнбер оешма. Җыенда Россиянең 80гә якын төбәгеннән килгән татар дин әһелләре катнашачак. Чараның быелгысы Идел Болгарстанында ислам динен рәсми кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан узачак.

Җыен Казан Эксподагы күргәзмә белән танышудан башланып китәчәк һәм тарихи яссылыктагы чыгышлар белән үрелеп барачак. Дин әһелләре 20 май

көнне тарихи вакыйгада – Казанда төзеләчәк Җәмигъ мәчетенә нигез салу тантанасында катнашачак. Әйтергә кирәк, татар башкаласында Җәмигъ мәчет төзү символик мәгънәгә ия. Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет академия театрында 1100 вәкил һәм Республикабыз Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов катнашында пленар утырыш үтәчәк. 21 май көнне барлык дин әһелләрен Болгар җыенына алып барабыз.

«

Дин әһелләре җыенының төп максаты – татар халкының тотрыклы үсешендә, милләтнең бердәмлеген ныгытуда мөһим фактор булган традицион рухи-әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләрне саклау юнәлешендә татар дини оешмаларын берләштерү, Россия территориясендә татар халкының бай мирасы, традицион ислам кыйммәтләре нигезендә бердәм рухи һәм мәдәни даирә булдыру нисбәтеннән дини оешмаларның үзара бәйләнешләрен ныгыту.

Татар дин әһелләрен бер мәйданга туплаганбыз икән, димәк, аларның карашлары Татарстанга төбәлгән. Бу исә татар һәм, гомумән, мөселман дөньясында Президентыбыз Рөстәм Нургали улы Миңнехановның мөһим роле турында сөйли. Дин әһелләрен Татарстанга җыеп, киләчәктә аларның эш юнәлешләрен билгелибез. Шул исәптән Россиядә татар факторының да ни дәрәҗәдә бәһасез роль уйнаганына басым ясыйсыбыз килә. Әлбәттә, бу җыен – Россия, татар дөньясы, гомумән, мөселман өммәте өчен мөһим вакыйга һәм ул тарихта тирән эз калдырачак.

Дин әһелләре җыенының төп максаты – татар халкының тотрыклы үсешендә, милләтнең бердәмлеген ныгытуда мөһим фактор булган традицион рухи-әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләрне саклау юнәлешендә татар дини оешмаларын берләштерү, Россия территориясендә татар халкының бай мирасы, традицион ислам кыйммәтләре нигезендә бердәм рухи һәм мәдәни даирә булдыру нисбәтеннән дини оешмаларның үзара багланышларын ныгыту.

Бөтендөнья татар конгрессы каршында Татар дин әһелләрен координацияләү советы эшләп килә. Безнең Россия киңлекләрендә төрле диния нәзарәтләре, дини оешмалар эшли, аларның барысын да Татарстан, Казан һәм Бөтендөнья татар конгрессы берләштерә. Дини фактор көчле булган җирлекләргә – Пенза өлкәсенең Урта Әләзән авылына, Мордовиянең Әзүркә һәм Аксюннарына, Самара өлкәсенең Гали һәм Камышлыларына, Чуашстанның Шыгырдан, Тукай һәм Урмаена, Түбән Новгород якларына игътибар итсәк, дини фактор көчле булган төбәкләрдә милли, демография, гаилә, әхлак һәм бизнес мәсьәләләре үз җае белән уңай якка хәл ителгәнен күрәбез. Андый авылларны дәүләт эчендәге дәүләт дияргә була. Әлбәттә, моның нигезендә ислам белән милли тормышның бергә үрелүе һәм рухи кыйммәтләрнең нык булуы тора. Хәзерге көндә имам дини тәгълиматны таратучы гына түгел, ә татарның рухи яңарыш әйдаманы, бу өлкәдә армый-талмый эшләүче шәхес тә әле. Болардан тыш, туган телебезне саклау юнәлешендә дә татар дин әһелләренең роле бәяләп бетергесез зур. Әлеге җыенда игътибар менә шуларга юнәлтеләчәк. ■

Фәрит Бикчәнтәев: «Театр бүген бар, иртәгә ул – тарих»

*(Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты **Фәрит Рәфкать улы Бикчәнтәев** белән «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире **Ләбиб Лерон** әңгәмәсе)*

– Әтиегез Рәфкать Бикчәнтәев, әниегез Наилә Гәрәева, хатыныгыз Люция Хәмитова, улыгыз Йосыф һәм Сез – тулы бер театраль династия. Театрга мәхәббәт әтиегездән күчкәнме, әллә тагын да ераккарак барып тоташамы?

– Әтнә районындагы Бәрәскә авылына кайтып, андагы кешеләр белән аралашкан саен шул турыда уйланам. Марсель Хәким улы Сәлимҗанов, Илдар Хәйруллин, Марсель Җаббаров һәм Зөлфия Зарипованың нәсел-нәсәбе шушы төбәк белән бәйле. Бәрәскә авылындагы колхоз рәисе Илгиз кардәшебезнең хатыны Сәрия ханым шәҗәрәләр төзү белән шөгыльләнә. Ул Марсель Сәлимҗановның нәселе Борнаевлардан килүен ачыклаган. Бәрәскә суы, Бәрәскә һавасы дөньяга нинди олы шәхесләрне биргән! Менә шуларны уйлагач, әллә, чыннан да, театрга мәхәббәт Әтнә ягыннан, Бәрәскәдән килгәнме икән дип уйланасың. Чыннан да, Әтнә мәшһүр Мәрҗани, бөек Тукай, могтабәр шагыйребез Сибгат Хәкимнең туган ягы бит! Бу төбәк татар мәдәниятендә аерым урын алып тора.

Балачакта Марсель Хәкимович мине сәхнәгә чыгарып уйнатып карады. Ә 7-8 класcларда укыганда театрга бөтенләй килми башладым, мәктәп сәхнәләрендә дә уйнамадым, театраль түгәрәкләргә дә йөрмәдем, урам малаена әйләндем дә куйдым. Унынчы сыйныфны тәмамлаганда «Кая барырга?» дигән сорау туды. Дус малайлар ПТУга кыстый башлады, әмма беркөнне бер гәҗиттә театр училищесына абитури-

Фәрит Бикчәнтәевнең бала вакыты

Әнисе Наилә Гәрәева белән

ентлар кабул итү турындагы игълан игътибарымны җәлеп итте. Рус бүлегенә керергә уйладым, чөнки рус мәктәбендә укып, урамда уйнап үскәнгәдерме, татар телем югалып бара иде инде. Шунда әни: «Теләсә нишлә, мин сине рус бүлегенә җибәрмим! Әтиең белән мин татар театрына хезмәт итәбез, синең дә урының шунда булырга тиеш. Татар бүлегенә барасың!» – диде. Дөресен әйткәндә, биш яшемә кадәр русча бер сүз дә белмәдем, чөнки җәй айларын әбиемнең туган авылы Казакларда уздыра идем. Ярты ел эчендә татарча сәхнә теленә җайлаштым. Шулай итеп, татар театрына кереп китүемә төп сәбәпче әни булды. Марсель Сәлимҗанов беренче курста ук мине икенче составта уйнарга чакырды, училищены тәмамлаганда 6-7 ролем бар иде инде.

Әтисе Рәфкать Бикчәнтәев белән

– Соңрак Сезгә Мәскәүгә китеп уку насыйп булды...

– Марсель абый: «Мәскәүдә афишаларны гына күзәтеп йөрсәң дә, нәрсәгәдер өйрәнеп була», – дип әйтә торган иде. 1979 елда Дамир Сираҗиев, ГИТИСны тәмамлап, Казанга кайтты. Яңача фикерле торган, гаҗәеп шәхес иде мәрхүм. Ул, студент чагымда куйган бер өзегемне карады да: «Фәрит, син, һичшиксез, ГИТИСка керергә тиеш!» – диде. Ул миңа җан кертте, күңелемә яңа уй салды. Марсель абый да мине хуплап, фатихасын бирде.



«Чит кеше» спектаклендә Ринат Таҗетдинов белән. 1973 ел

– Бала вакытта бүтән һөнәр сайлар, башка өлкәдә эшләргә теләр идем дигән хыялларыгыз булмадымы? Үзегез беләсез, үскәч очучы яки космонавт булам, дип шашты бит безнең буын...

– Хыяллар күп булгандыр инде... Космонавт, дигәннән... Биш яшькә кадәр әти белән бергә Космонавтлар урамында яшәдек. Шунда бишкатлы бер йортның диварында космонавт сурәте бар иде. Ул әле дә бар... Нигәдер, мин аны гел әнигә охшата, аның сурәте дип кабул итә идем. Ул миңа хатын-кыз кыяфәтле булып күренде...

Ул вакытта танк, автомат безнең буын кулындагы төп уенчыклар иде.

– Башкала театрларының тәҗрибәсен өйрәнеп, ГИТИС белеме белән Сез Казанга кайтып төшәсез. Бу вакытта нинди хисләр кичердегез? Җиңел булмагандыр, чөнки иҗат кешеләре бик катлаулы шәхесләр бит...

– Дүртенче курста укыганда әнием: «Мин сиңа бер әсәр җибәрәм әле, укып кара, аны худсовет кабул итмәде. Ә миңа ул әсәр бик ошады», – ди. Бу – Мансур Гыйләҗевнең «Бичура»сы. Миңа да әсәр ошады, анда гадәти булмаган кешеләр, бичуралар бар… Марсель абыйга бу әсәрне куярга теләвемне белдердем. Артистлар белән дә авырлык булыр дип уйламадым, мин – аларның күз алдында үскән малай. Фәкать Әзһәр абый Шакиров кына кыенлыклар тудырды: ул бик кире һәм аның һәрчак үз фикере бар…

– Сыртын кабартып ала торган гадәте бар, дип әйтүегездер…

– Без бик еш бәхәсләштек. Үземчә эшләттердем моны дип кенә уйлап куям, ә ул барыбер икенче төрле уйный. Димәк, мин Әзһәр абыйны тулысынча ышандырып бетерә алмаганмын. Ә гомумән алганда, безнең театрга режиссер кайдан гына килмәсен, аңа хөрмәт зур. Бу – Марсель абый Сәлимҗановтан килгән традиция. Кайбер театрлардагы кебек артистларның башбаштаклыгы бездә юк, бу яктан тәртип. Читтән килгән режиссерлар да безнең театрның әлеге сыйфатын югары бәяли.

– Марсель Сәлимҗанов белән озак еллар иңгә-иң куеп эшләдегез. Каршылыклар булдымы?

– Гадәттә, баш режиссерлар яшьрәкләрне кыса, ә Марсель Сәлимҗанов бер спектаклемне дә үзгәртмәде. Аның традициясенә тугры булып, үзем дә башка режиссерлар эшенә тыгылмыйм, юкса бу шәхеснең үз-үзенә ышанычын бетерә. Иҗатта ирек булырга тиеш…

Дөрес, Марсель абый миңа түзде, төрле чакларым, кыланышларым булды инде…

– Мөдәррис Әгъләм бервакыт миңа интервью биргәндә: «Шәләй-вәләй күп йөрелде инде», – дигән иде. Безнең дә шундый вакытлар булмады түгел…

– Марсель абый моны яхшы аңлый иде…

– Режиссерлыгыгызга бер вакыйга аша зур бәя бирәм. Сезгә үземнең «Экстрасенс» дигән пьесамны биргәч, аны укып чыктыгыз да: «Ләбиб, телегез бик әйбәт, пьесагыз яхшы, әмма минеке түгел!» – дигән идегез. Бу – күңелемә ошамаган әсәрне куярга алына алмыйм, дип әйтүегез иде. Гадел һәм дөрес әйттегез. Минемчә, болар Сезнең ихласлыгыгыз турында сөйли…

– Ркаил Зәйдулла белән дә шундый ук хәл булган иде. Аның «Саташкан сандугач»ын укып чыккач, Марсель абый: «Фәрит, син нәрсә уйлыйсың?» –ди. Мин: «Ркаил – гаҗәеп шагыйрь, әмма драматург түгел», – дидем. Ркаил үпкәләмәде. Ә Марсель абый: «Шагыйрьне театрга тартырга кирәк», – дип, пьесаны куйдыртты.

– Пьесаны Сез чимал дип саныйсыз, ә Туфан Миңнуллин әдәбият дип әйтә иде. Чынлап та, заманында пьесалар күпмедер дәрәҗәдә әдәби китап ролен үтәде.

– Чимал дигән сүз мыскыллабрак әйтелгән кебек яңгырый шул…

– Туфан абый Миңнуллинның «Миләүшәнең туган көне» пьесасының дәвамы булган «Хушыгыз» пьесасын «Казан утлары»нда укыгач, аны гап-гади бер әсәр буларак кабул иткән идем, ә Сезнең куелышта лиризмга, психологиягә корылган искиткеч затлы әсәр килеп чыкты.

– Мин аңа гел: «Туфан абый, килешегез инде, пьеса сәхнәгә менмәсә, ул тулы булмаячак!» – дип әйтә килдем. Ул исә: «Нәрсә, мин язганнар чималмыни?!» – дия иде.

– Чынлап та, пьеса «чәйнәп каптырылган» булса, режиссер өчен кызык түгелдер дип уйлыйм.

– Шекспирның китабын кулга алып, аны мөкиббән булып укып утырган

кешеләрне белмим, Чеховны да егылып укымыйлардыр хәзер.

– Мин укып чыктым Чеховны...

– Танышып чыккансыздыр инде... Сәхнәгә менмичә, бер генә пьеса да тулы түгел, минемчә. Драматурглар аны укыр өчен иҗат итмәгән, барысы да уйнар өчен, сәхнә, тамашачы өчен языла. Сәхнәдә аны артист уйнарга, тамашачы исә карарга тиеш!

– Хыялланып та куймый калган әсәрегез бармы?

– Әлбәттә, андый әсәрләр бар. Заманында мин аларны куярга һөнәри яктан җитлекмәгән идем. 1990 нчы елларда Марсель Сәлимҗанов мине Мәхмүт Галәүнең «Мөһаҗирләр»е белән таныштырды. Укып чыктым да бу әсәргә гашыйк булдым. Шул заманнан хәзерге көнгә кадәр аны сәхнәгә кую турында хыялланып йөрдем. Илтөзәр Мөхәммәтгалиев белән инсценировкасын язып карадык, конкурс игълан иттек, сизәм, мин әзер түгел. Кинорежиссерларга тәкъдим иттем, алар да берни майтара алмады. Ниһаять, быел үзем сәхнәләштерә башладым.

– Төп эшегездән аерылмыйча, Качалов, Буа һәм Уфа театрларында да эшләп карадыгыз. Бу да зур тәҗрибәдер.

– Әлбәттә. Анда да артистлар сине күз карашыңнан ук аңлый. Артистларның 75 проценты – үземнең укучылар. Ә читтә үз-үзеңне башка яктан сынап карыйсың.

– Без – Сәлимҗановлар стилендәге театрны карап, Камал, Тинчурин, Туфаннар рухында тәрбияләнгән буын. Хәзерге театрга яңа юнәлешләр килә, мин аларның кайберләрен хәтта аңлап та бетерә алмыйм. Яшьләр аны ярата, шуңа күрә мондый әсәрләр дә кирәктер дип уйлыйм. Камал театрының бүгенге максаты нинди? Репертуарның киләчәге ничек булыр: традиционмы яки заманчамы?

Фәрит Бикчәнтәев һәм Илгиз Хәйруллин Әтнә районының Бәрәскә авылында

«Хушыгыз» спектакленең репетициясе. Равил Шәрәфиев белән. 1993 ел

– Алга барыр өчен, артта калмаска кирәк. Буын алышына, яшь тамашачылар килә. Аларның дөньяга карашы бөтенләй башка. Традициягә дә яңалык кертергә кирәк. Шулай эшләмәсәк, без театраль музейга әйләнәчәкбез. Хәтта музейлар

М.Сәлимҗанов һәм Ф.Бикчәнтәев шәкертләре белән. 1995 ел

да хәзерге көндә заманча ысуллар эзли. Заман барыбер алдан чаба, яңалык кертмәсәк, театр кызык булмас иде. Әдәбият, шигърият тә үзгәрә...

Киноны 20 елдан артык карарга була, ә театр бүген яши. Спектакль бүген туа, 5-6 ел сәхнәдә яши дә, картая һәм үлә. Вакыты җитү белән спектакль үзеннән-үзе көчсезләнә башлый, аның бүгенге көнгә тәэсире югала.

Элеккеләрнең нинди спектакльләр куйганын без тарихтан гына укып беләбез. Театр менә шулай тарихка гына кереп кала, аны тотып карап булмый. Кайчакта элекке видеоязмаларны кабызып карыйм. Аларны карап булмый. Театр – тере организм. Кемдер аны күбәләк белән чагыштыра. Театр бүген бар, бүген яши. Бу – аның фаҗигасе. Ә иртәгә ул – тарих. «Их, шундый спектакль бар иде!» – дигән хатирәләрдә генә яши ул. Фәлән әсәрне кире кайтарырга иде, диләр. Ә элеккеләрне кире кайтарып, бүген тәкъдим итсәң, аңа тамашачы кире кайтыр идеме икән? Белмим...

Дөрес, кайберләре бик озак куела, зал тулы тамашачы белән бергә яши. Үлемсез әсәрләр дә юк түгел. Мәсәлән, Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл»е. Аны ничә куйма, зал һәрвакыт шыгрым тулы. Һичшиксез, традицияләрне дә сакларга тиешбез. Ул «музей» булсын – килеп кенә карасыннар.

– Музей кебек әсәрләрнең дә уйналуы кирәк. Туфан абый әйтмешли, «Зәңгәр шәл»дә татарның кеме генә юк, барысы да – үзебезнекеләр...

– Без традицияләрне дә югалтмаска, икенче яктан, заманнан да артта калмаска тиеш. Миңа калса, академия театрының миссиясе менә шул.

– Эльдар Рязанов һәр кинофильмының бер эпизодында үзе уйный иде. Элекке артист буларак, үзегез яки яшьләр куйган спектакльдә күренеп алырга теләмисезме?

– Юк, теләмим. Ә менә Сез әйткәч, уйлап карарга кирәктер, дим...

– Бу тамашачылар өчен дә кызык булыр иде.

– Фикерегезне теркәп куям. «Мөһаҗирләр»дә татарларның патшага мөрәҗәгать язу вакыйгасы бар. Менә шул хатны, бәлки, үзем сәхнәгә чыгып укырмын. Режис-

сер буларак бик гади генә итеп, әмма шул ук вакытта ниндидер мәгънә салып укысам, бик яхшы булыр кебек. Бу – тетрәндергеч хат.

Наил Дунаев, Фәрит Бикчәнтәев һәм Әзһәр Шакиров

Минтимер Шәймиев белән татар театрының 100 еллыгына багышланган кичәдә. 2007 ел

Театраль гаилә: Фәрит, Йосыф һәм Люция. 2012 ел

– Сүз дә юк, артист укуына караганда, Сезнең сәхнәгә чыгуыгыз бөтенләй башкача булачак. Спектакльгә бүгенге тормыш килеп керәчәк.

– Мәскәүнең хәзерге кайбер режиссерлары да сәхнәдә үзләре күренгәли. Нәтиҗәдә, спектакль икенче мәгънәгә ия була. Ярый, хәл иттем – хатны, режиссер буларак, үзем укыячакмын. Рәхмәт, Ләбиб!

–Үзегезгә зур рәхмәт! Уңышлар юлдаш булсын! ■

Безнең мирас №5 май 2022

Рухи хәяттә дини әдәбият

Рәмил Исламов



«Кисекбаш» китабы. 1909 ел

Билгеле ки, халкыбызның мең елдан артык тарихы булган рухи мирасының аерылгысыз өлешен дини тематика белән бәйле язма ядкярләр тәшкил итә. Күбесенең кем тарафыннан иҗат ителүе билгеле түгел, әмма авторлары мәгълүм булганнары да бар. Бер мәкалә кысаларында аларның барысына да тукталу мөмкин түгеллеген истә тотып, кайберләре һәм, нигездә, татар телендәгеләре белән генә таныштырып үтү мәгъкуль күрелде.

Дини әдәбият дигәндә, беренче чиратта, сүз Коръән Кәрим турында бара, әлбәттә. Типографияләр барлыкка килгәнче, аны кулдан язып таратканнар. Археографик экспедицияләр вакытында табылган һәм хәзерге вакытта фәнни оешмалар фондларында саклана торган күп сандагы күчермәләр – моңа ачык дәлил. Аларның күпчелегендә күчереп язу урыны һәм елы күрсәтелмәгән. Шулай ук күчереп язучының исеме дә бик сирәк очрый: мөселман традициясе буенча, Коръән, ягъни Аллаһ сүзе астына үз исемеңне кую дөрес саналмаган. Әйтергә кирәк, изге китапның мулла Госман хәзрәт Ибраһим тарафыннан әзерләнгән тексты беренче мәртәбә Петербургта Фәннәр академиясе типографиясендә 1787 елда нәшер ителә һәм 1798 елга кадәр биш басмасы дөнья күрә. 1802 елда Коръән Кәрим Казанда басыла башлый һәм аның нөсхәләре барлык мөселман илләрендә дә таратыла.

Коръән Кәримне аңлау-төшенү өчен тәфсирләр языла. Аларның, гарәп-фарсы телендәгеләре белән бергә, татар телендәгеләре дә барлыкка килә. Татар тәфсиренең башлангычы танылган дин галиме Габденнасыйр Курсави исеме белән бәйле. Аның шәкерте Ногман бине Сабит әс-Сәмани остазының китабын 1861 елда нәшер итә һәм ул «Һәфтияк шәриф» дип атала. Шулай ук халкыбыз арасында популярлык казанган ике томлы «Тәфсир Ногмани» («Ногмани тәфсире») да аның тарафыннан язылган.

Әйтергә кирәк, Коръән Кәрим каләм ияләренең иҗаты өчен илһам чыганагы да була. Мәсәлән, Кол Галинең эчтәлегендә дөньяви проблемалар да чагылыш тапкан «Кыйссаи Йосыф» поэмасы (13 нче йөз) – шундыйлардан. Ул Йосыф пәйгамбәр (г.с.) турындагы 12 нче сүрәгә нигезләнеп язылган һәм «Йосыф кыйссасы», «Йосыф китабы», «Йосыф-Зөләйха» дип тә аталып йөртелгән. Исәпләүләребез буенча хәзерге вакытка «Кыйссаи Йосыф» әсәренең якынча 300дән артык күчермәсе билгеле. Габдерәхим Утыз Имәни тарафыннан төзелгән тәнкыйди текст нигезендә әсәр беренче тапкыр 1839 елда Казан университеты типографиясендә нәшер ителә һәм 1917 елга кадәр аның 70ләп басмасы дөнья күрә. Халык арасында иң күп таралыш алган бу әсәрнең традицияләре аннан соңгы чорлардагы татар әдәбиятында XX гасыр башларына кадәр чагылыш таба.

Коръән Кәримнән аерым аятьләр еш кына үткәндәге авторлар тарафыннан үз фикерләрен дәлилләү, нинди дә булса фактны раслау өчен кулланыла. Алай гына да түгел, тулы әсәрләр иҗат ителә. Моңа мисал итеп, мәсәлән, Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьяр әсәрләрен китерергә мөмкин. Дөрес, совет хакимияте вакытында дөнья күргән китапларында бу мәсьәлә читләтеп үтелде.

Дини әдәбиятның икенче төре пәйгамбәрләр тарихы белән бәйле. Аларның гарәп һәм фарсы телләрендә язылганнары Шәрыкта киң таралган. XIV гасырның беренче яртысында Алтын Урда дәүләтенең Харәзем төбәгендә төрки телдә шундый әсәр барлыкка килә һәм ул «Кыйссасел-әнбия» дип атала. Аның авторы Рабат Угызы дигән шәһәрнең казые Борһанеддин ибне Насыйреддин исемле укымышлы була. Ул типография ысулы белән нәшер ителә башлагач (1859 елда) татарлар арасында басма китап булып та киң таралыш ала. «Кыйссасел-әнбия» мәдрәсәләрдә уку әсбабы сыйфатында да кулланыла.

Турыдан-туры Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) хакында да әсәрләр иҗат ителә. Мәсәлән, аның туган көненә багышланган «Мәүлиден-нәби», күккә ашу вакыйгасын тасвирлаган «Мигъраҗнамә» китаплары – шулар җөмләсеннән.

Мөхәммәд пәйгамбәргә (с.г.в.) бәйле һәм татарлар арасында популяр булып, көйләп укыла торган әсәрләрнең берсе – төрек шагыйре Мөхәммәд Чәләбинең «Мөхәммәдия» китабы. Ул беренче мәртәбә Казанда 1845 елда нәшер ителә һәм 1917 елга кадәр аның егерме дүрт басмасы дөнья күрә. Әлеге китап кадими мәдрәсәләр программасында булып, кызлар өчен уку әсбабы сыйфатында кулланыла. «Мөхәммәдия» – халкыбызның рухи мәдәниятенә көчле тәэсир ясаган әсәрләрнең берсе. Аның йогынтысын күп кенә шагыйрьләр, мәсәлән, Габделҗаббар Кандалый, Габдулла Тукай иҗатларында күрергә мөмкин.

Мөхәммәд Чыкрыкчызадә исемле икенче бер төрек әдибенең шундый ук характердагы прозаик әсәре «Алты Бармак китабы» дип атала. Аның эчтәлеге Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.) тормышын һәм эшчәнлеген тасвирлаудан гыйбарәт.

Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.), аның кияве Гали (р.г.) исемнәре белән бәйле тагын бер шигъри ядкяр «Кисекбаш» дип атала. Ислам динен тарату һәм ныгыту максатыннан иҗат ителгән бу әсәр шулай ук популяр була. Аның кульязма күчермәләре


رساله‌ء عزيزه
شرح ثبات العاجزين

Дозволено цензурою С.-Петербургъ 16 января 1897 г.
КАЗАНЬ.
Типо-литографія Императорскаго Университета.
1897 г.

«Рисаләи Газизә шәрхе Сөбател гаҗизин» китабы. 1897 ел

әле дә табылып тора. «Кисекбаш» матбага ысулы белән дә күп тапкырлар нәшер ителә. Ул иҗат әһелләре өчен илһам чыганагы да була. Биредә Г.Тукайның шуңа нигезләнеп язган «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасын гына искә төшерү дә җитә.

«Бәдәвам» – татарлар арасында иң киң таралган шигъри әсәрләрнең берсе. Аның атамасы дүртьюллык бәет тәмамланган «Аллаһ дигел бәдәвам» дигән сүзтезмәдән алынган. Авторы да, кайчан һәм кайда иҗат ителгәнлеге дә билгеле түгел. Галимнәр фикеренчә, 18 нче йөзгә кадәр иҗат ителгән булырга тиеш. Әлеге әсәр беренче мәртәбә 1846 елда басыла һәм чыганаклардан күренгәнчә, 1915 елга кадәр 65 басмасы нәшер ителә. «Бәдәвам» – күләме зур булмаган һәм әдәп-әхлак кагыйдәләрен бозмаска, иманны сакларга өндәгән дидактик характердагы әсәр. Бу уңайдан Кушлавыч авылы кешесе Хисаметдин Камалетдиновның хатирәсеннән бер кызыклы хәлне искә төшереп үтү мәгъкуль күрелде: *«Менә беркөнне Тукай икәвемез безнең түбән өйдә нәрсә беләндер уйнап утырганда, түбән очта фатир төшерүче Әхмәди дигән кеше бар иде, шул Әхмәди безнең түбән өйгә керде дә: «Әссәламү галәйкүм!» – диде. Үзе яхшы гына «кызган» иде. Мин аны-моны күп уйлап тормадым: «Вә галәйкүм әссәлам!» – дидем. Ә инде Тукай сәламен алмады. Әхмәди абзый, үзе бик җиңел кеше булу өстенә, азрак төшереп тә алганга күрә, бик тиз генә Тукай җанына: «Ә син ник сәлам алмыйсың?!» – дип орышырга барган иде, [Тукай]: «Исереккә сәлам бирмә, ул бирсә һәм син алма, дип, «Бәдәвам»да язган», – дигәч, башка бер сүз әйтмәстән чыгып китте».*

Мәдрәсәләрдә уку «Иман шарты» дигән китап белән башлана. Әлифба буларак кулланылган һәм дин нигезләрен өйрәтүгә корылган бу әсбап беренче мәртәбә 1802 елда нәшер ителә һәм иң күп басылган китапларның берсе була.

Вафаи исемле төрекмән авторының 1464-1465 нче елларда язылган «Рәүнакел-ислам» («Ислам чырагы») шигъри әсәре утыз биш бүлектән гыйбарәт һәм ул мөселман йолалары турында. Аны Н.П.Остроумов типография ысулы белән беренче мәртәбә 1907 елда Ташкентта бастыра. Ядкярнең кульязмалары да шактый табыла. Бу әсәр дә мәдрәсә шәкертләренең уку китабы булган.

Мөселманнар өчен яшәү кодексы рәвешендә язылган әсәрләрнең берсе – «Нәсыйхәтес-салихин», ягъни «Изгеләрнең нәсыйхәтләре». Ул кульязмада күп таралган. Нәсыйхәтес-салихин» беренче мәртәбә Казанда 1853 елда нәшер ителә һәм аннан соң егермеләп басмасы дөнья күрә.

Мәдрәсәләрдә «Иман шарты»ннан соң укытыла торган китапларның берсе «Фазаилеш-шөһүр» («Айларның фазыйләтләре») дип атала. Аның төзүчесе – Җамалетдин бине Бикташи исемле мулла. 1854 елда нәшер ителгән бу китап әхлак, дин гамәлләрен үтәү тәртибе мәсьәләләренә багышланган.

Халкыбызның рухи хәяте репертуарының билгеле бер өлешен суфый әдәбият

алып тора. Болар – барыннан да элек, чыгышлары белән Урта Азиядән булган мәшһүр шагыйрьләрдән Әхмәд Ясәви хикмәтләре, Сөләйман Бакырганиның «Бакырган китабы», «Мәрьям ана китабы», «Хәким ата китабы», «Ахырзаман китабы» дигән әсәрләр. Мәсәлән, «Ахырзаман китабы» халыкта «Тәкый гаҗәп» буларак та билгеле. Ул заман ахырының билгеләрен, Кыямәт көне вакыйгаларын һәм Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.) Аллаһы каршында мөселманнарны яклавын тасвирлауга корылган. Әсәр эчтәлегенең актуальлеге, текстының гадилеге белән үзенчәлекле. Бу ике әдип әсәрләренең күп кенә Истамбул, Казан һәм Ташкент басмалары барлыгы мәгълүм.

Әйтергә кирәк, аларның татар шигърияте үсешенә ясаган йогынтысы сизелерлек була. Мәсәлән, 17 нче йөз шагыйре Мәүла Колый үзенең хикмәтләрен Әхмәт Ясәви тәэсирендә иҗат итә. «Бакырган китабы»ның тәэсире соңрак дәвер шагыйрьләре Һибәтулла Салиховның «Тәндә җаным» исемле касыйдәсендә, Вәсим Солтановның «Канау буе» дигән поэмасында ачык күренә.

Бу хосуста без шулай ук әйтелгән төбәкнең танылган каләм иясе Аллаһияр суфыйның шигырь белән язылган «Сөбател гаҗизин» («Гаҗизләрнең ныклыгы») әсәрен дә игътибардан читтә калдыра алмыйбыз. Аның 1802-1865 нче елларда Казанда тугыз мәртәбә нәшер ителүе мәгълүм. «Сөбател гаҗизин»га шәрехләр язу нигезендә Таҗетдин Ялчыгол 1837 елда «Рисаләи Газизә» дигән китап төзи. Ул беренче мәртәбә 1847 елда Санкт-Петербургта нәшер ителә. 1850 елда Казанда да дөнья күргән әсәрнең кырыклап басмасы билгеле. «Сөбател гаҗизин» мәдрәсәләрнең башлангыч сыйныфларында тел дәреслеге сыйфатында кулланыла.

Шәрыкътан кергән кыска сюжетлы мавыктыргыч эчтәлекле кыйссалар шулай ук халыкның яратып укыла торган әсәрләреннән санала. Алар арасында, мәсәлән, «Тутыйнамә», «Хатәм Тай», «Әбугалисина», «Кырык вәзир», «Каһарман Катыйль», «Кыйссаи Нәүруз» һ.б. бар. Болар да кульъязмаларда күпләп тарала, матбагачылык хәрәкәте башлангач, басма китаплар буларак та нәшер ителә.

«Бакырган китабы». 1895 ел

Зур булмаган әлеге күзәтүләребездән аңлашылганча, татарларның рухи хәятендә файдаланылган дини әдәбият киңкырлы һәм үзенчәлекле. Шунысын да әйтергә кирәк, теге яки бу әсәрнең кем тарафыннан һәм кайда язылган булуы шул заман укучысы өчен мөһим булмаган. Барыннан да элек, рухи ихтыяҗны канәгатьләндерү алгы планда торган. Күп кенә әсәрләр шагыйрьләргә, язучыларга иҗат эшчәнлеге өчен үрнәк һәм рухлану чыганагы була. Бу уңай белән шунысы да ачыклана: әлеге бибәһа мирас турында хәзерге вакытка кадәр тулы бер мәгълүмат тупланмаган. Шуңа күрә аның аннотацияле каталогын төзеп бастыру галимнәр һәм дин эшлеклеләре белән берлектә якын киләчәктә башкарасы кичектергесез бурычларның берсе саналырга тиеш. Алга таба бу фундаменталь хезмәтләр язарга ныклы җирлек булырга мөмкин. ■

Мизгел

Марсель Галиев

Санама үзеңне зур итеп, ә зурны хур,
Ахырда хурлык күрерсең, булма мәгърур.
Г.Утыз Имәни

Сулдан уңга: Ренат Харис, Д.Х.Зарипова (КПСС өлкә комитетының мәдәният бүлеге мөдире), С.П.Кошечкин («Правда» газетасының мәдәният бүлеге мөдире), Раиса Горбачева, Әмирхан Еники, Тәлгат Галиуллин, Илдар Юзеев, Миркасыйм Госманов. 1986 ел

Еллар саргайткан фоторәсемнәрне карарга яратам. Билгеле бер чорның сурәт-рәвеше киемнәрдә, чәч тарауларда, күз карашларында чагыла. Нәкъ шушы төркемне кабат беркайчан да җыя алмыйсың инде. Сурәттән бигрәк, мине шул кешеләрнең ничегрәк туплануы, нинди сүзләр сөйләшеп ыгы-зыгы килүләре кызыксындыра. Сурәттәге шәхесләрне терелтәсе, хәрәкәткә китерәсе иде дә... Ни кызганыч, еллар һәм юллар аларны инде әллә кайларга сибеп ташлаган, кайсыларыннан инде хәтер маягы булып кабер ташлары гына калган...

Шулай итеп мин, нәүмиз сагышланып, иңемә баскан Вакыт кодрәтен тоеп, иске фоторәсемнәр карарга яратам.

Менә тагын бер сурәт... Саргаерга әле өлгермәгән. Таныш йөзләр... Кичә генә тезелешеп төшкәннәрдер кебек. Саный китсәң, егерме ел гомер үтеп тә киткән икән шул. Раиса Горбачеваны уртага алып фоторәсемгә төшкән татар язучылары... Баксаң, ул еллар эчендә ил күләмендә нинди генә үзгәрешләр булмады да, нинди генә язмышлар дер селкетелмәде.

Ә ул чакта. Дөньядагы иң зур илнең Олимп тавындагылары мәңге шулай иярдә калыр кебек иде. Әмма, нигәдер, генераль секретарь хатыны Раиса Горбачева белән фотога төшүләрен язучылар үз вакытында бик мактанып сөйләп йөрмәделәр. Ул фотоны кайда да булса бастырып чыгарырга да ашыкмадылар. Сәбәп нәрсәдә иде? Тыйнаклыкмы? Куркуданмы? Бу илнең тәхет тирәсе тотрыксыз икәненә күнегеп беткәнгә күрә дәшмәскә уйладылармы?

Әлеге фото тарихын бер кулга җыярга теләп мөрәҗәгать иткәч тә, әле кайбер язучылар икеләнеп-шикләнеп калдылар. «Ярармы икән?..» – дигән сагаюны таратыр өчен тел ачкычлары кирәк иде. Мәйданнан киткән шәхескә түбәнсетеп карау Россиядә гадәткә кергән, бу очракны көлеп язмасмы икән дип, кайберәүләр миңа ышанмыйчарак та карадылар бугай. Ләкин бу гадәт мөселман тәрбиясе алганнарга хас түгел, шуңа күрә мин баштан ук мондый караштан ерак тордым. Минем өчен әлеге фоторәсем бәхетле очрак кына түгел, ә ил тарихының кешеләр йөзендә чагылган бер мизгеле иде.

Сүз – югары даирәдәге хатын-кыз шәхесе хакында...

***

Испания башкаласы Мадридта Корольләр сарае бар. Аның бер-берсен кабатламаган, искиткеч зиннәтле, дөньяның әкияти байлыгын туплаган меңгә якын залын карап та, акылга сыйдырып та бетерерлек түгел. Идәне, түшәме, диварлары «Алла кулы» белән чигеп эшләнгән сәнгатьле залларның берсе – «Тәхет залы» минем аеруча хәтердә калган. Калкурак урында алтын белән нәкышләп, бормалы бизәкләр уеп эшләнгән ике кәнәфи янәшә тора. Алдарак, як-якта, табигый зурлыгында алтыннан коелган ике арыслан дәһшәт салып төбәлгән. Кәнәфиләрнең арка терәгеченә король Хуан Карлос һәм королева Софиянең барельефы ясалган. Мине гаҗәпләндергәне шул булды: ни өчен соң әле король хакими биеклектә үзе генә утырмый, ә хатыны белән янәшә?!.

Шуннан соң инде мин тарихи әсәрләр укыганда игътибарлырак була башладым һәм бернәрсәгә төшендем: хан, патша, король, солтан һәм шаһларның хәләл җефетләре ил белән идарә итүдә хәлиткеч урын тотканнар икән. Аларның күбесе тәхеттәге иренә иң якын киңәшче, иң ышанычлы терәк булганнар. Әлбәттә, арада мәкерлеләре дә табылган, астыртын эш йөртеп, иренең башын кистереп, тәхеткә сөяркәсен утырту яисә үзе хакимлекне алу кебек күренешләр дә тарихка ят түгел.

Русның монгол-татарлар хакындагы ялган әдәбияты кыргый санаган хан даирәсе ничегрәк булган икән соң?

Монголларның Югары киңәшмәсендә (әгәр ул хәрби максатларны күздә тотмаса) бөек хан һәм төмән башлыкларының хатыннары катнашканнар, корылтайларда киңәш-табыш бирү хокукына ия булганнар.

Менә бер мисал. Сарай-Бату шәһәрендә булган Аурупа кешесе Плано Карпини хан сараенда үз күзе белән күргәннәрен болай дип язып калдыра: *«Бату тәхеттә хатыннарының берсе белән янәшә утыра. Аның энеләре, уллары һәм сарай әһелләре аста, арырак утыралар. Калганнар – келәмдә. Ирләр – уң якта, хатын-кызлар – сулда».*

Менә шуларны белгәннән соң инде, әле бу гасыр башында гына Англиядә хатын-кызларның сайлауга катнашу хокукы яулап митингларга чыгуын хәтерләп: «Их, Аурупа...» – дип мыскыллы көлеп куясың. Үз кыргыйлыгын күрмичә, гаепне гел Шәрыктан эзләгән Аурупаның, тарихи фактлар белән бәреп, күзен ачтырыр чор җиткәндер, ниһаять.

Тагын тарихка күз салыйк...

Каракорумда, Чыңгыз ханның оныгы Көек хан үлгәннән соң, аның урынына бөтен монгол мәмләкәтенә ханбикә булып хатыны Аккүл-Камыш кала.

Яшүсмер хан Улакчы урынына Алтын Урда белән Батуның тол хатыны Баракчина идарә итә.

Тарихта шактый мәртәбәле эз калдырган Бөек Үзбәк ханның хатыннарына игътибар итик: беренчесе – Кытай императоры Буянтуның сеңлесе, икенче хатыны – Византия императоры Андроник кызы Байалун була.

Урданың атаклы төмән башлыгы (кенәз дип тә йөртәләр) Нугайның хатыны – Византия императоры Михаил Палеолог кызы Ефросинья.

Җанибәк ханның хатыны Тайдулага Мәскәү янында бүләк итеп бирелгән җирдә калыккан Тула шәһәренә исем дә шул ханым хөрмәтенә кушылмадымы икән әле?!. Күрәсез, аксөяк нәселеннән булган бу ханымнарның аң-белем, культура дәрәҗәсенең ничек югары булуын күзаллау кыен түгел. Гаскәр белән килеп, иреннән калган тәхетне яулаган Түләбәк ханым хөрмәтенә XIV гасырда Сарайда акчалар сугыла.

Шулай ук тарихта исемен калдырган Хөршидбәк, Нурсолтан, Гәүһәршад һәм Сөембикәләр турында да романнар язарлык.

Алтын Урда һәм Казан ханлыгының дәүләт системасын үзләштергән Россиянең

тәхетендә әби патшалар пәйда булу – Шәрыкның турыдан-туры йогынтысы ул. Ә Испания – Аурупа бит, дияр кемдер. Әмма бу илнең берничә гасыр гарәпләр кул астында яшәвен онытмыйк. Аурупаның учында Шәрык биргән акыл ташы ята…

Бөек Октябрь мәхшәреннән соң, тәхет даирәсендәге гореф-гадәтләр буталды. Большевикларның хатын-кызга карашы, аларны дәүләт идарәсе эшләреннән читләштерә башлавы бернинди этик нормаларга да сыймый иде.

Тора-бара партия җитәкчеләренең хатыннары гадәти кухаркаларга әйләнеп калдылар.

Халыкара килешү буенча, ил башлыклары югары даирәдә очрашу үткәргәндә, хатыны беләнме, ялгыз киләме – бу алдан уртак фикергә килеп эшләнә. Михаил Горбачевның төрле илләргә эш визиты белән барганда хатыны Раиса Максимовнаны үзе белән алуы халык өчен башта яңалык иде шикелле. Белгәнебезчә, мондый визитлар бик кыска арада, гаять киеренке шартларда үтә, ә без экраннан аның тантаналы өлешен генә күрәбез, һәрнәрсәгә чырай сытып, шикләнеп карарга өйрәнгән совет кешесе ил башлыгы парлашып, кәеф-сафа корып йөри дип уйларга да мөмкин иде…

Хакимият тирәсендә борын-борынгыдан бүре законы хөкем сөрә. Сәясәттә дус-иптәш дигән төшенчә юк. Тарихи борылышларда көрәштәшләрең дә тапталып калырга мөмкин. Кешелек, яңадан-яңа акыл туплап, күпме генә алга барса да, хакими даирә шулай булып калачак.

Сәясәтнең менә шундый мәкерле әйләнешендә генераль секретарь (соңыннан Президент) Горбачевның үз хатынына иң якын сердәше, киңәшчесе, ышанычлы кешесе итеп каравы табигый түгелмени! Әгәр телеоператорлар, әрсез журналистлар Раиса Горбачевага объективны артык еш юнәлтмәгән булсалар, әгәр Президент Горбачевның, үз элгәрләренә караганда, хатын-кызга мөнәсәбәте күпкә әдәплерәк икәнен совет халкы аңлый алырлык культурага ирешкән булса… Кыскасы, без әле моңа тора-бара ныклап төшенербез. Раиса Горбачева бу илнең изелгән, болгавыр көнкүрештән йончыган хатын-кызлар кавеменә ниндидер үзгә бер рух бирде, хакими даирәгә Шәрыктан килгән олы гадәтне кайтарды, хатын-кызны үз биеклегенә куя алды.

Әдәбият-сәнгатьтән ерак торган Горбачевка бу өлкәгә аерым игътибар итәргә кирәклеген, хатын-кыз йомшаклыгы белән, бәлки, нәкъ менә Раиса ханым сеңдерә белгәндер. Югыйсә Максим Горький заманнарыннан бирле талантлы язучылар белән дәүләт җитәкчеләре һәрчак каршылыкта яшәделәр. Акыллы хан-патша белә: чорны хикмәтле итеп бары тик язучы-әдип кенә теркәп калдыра ала, сурәтең таш булып калмасын дисәң, әдип күңеленә каты кагылма… Күп хаталары бардыр, әмма Галиҗәнап Сүзгә, Акылга азатлык капкаларын ачкан Михаил Горбачевның, бөтен Политбюро әгъзаларын ияртеп, язучыларның зур форумына килүе күрелмәгән хәл, әмма табигый адым иде. Бу – СССР Язучыларының соңгы – VIII съезды (1986) иде. Бүгенге дәүләт эшлекләләренә хас «малайлык»тан аермалы буларак, һәрберсе үз исемен истә калдыртып, һәрберсе үз шәхесе хакында тотрыклы культ булдырган Политбюро әгъзалары президиумнан урын алуга, зал чүгеп, тантаналы тын кала. СССР Язучылар Союзы рәисе Георгий Марков, ике тапкыр Социалистик Хезмәт Герое булуга карамастан, каушап кала, докладыннан ике җөмлә укуга, йөрәген тотып, сыгылып төшә. Аны Советлар Союзы Герое Владимир Карпов алыштыра…

Тәнәфес вакытында Татарстан язучылары – делегатлар, Раиса Максимовна Горбачеваны (Титаренко) уртага алып, фоторәсемгә төшәләр. Әгәр башка җирдән килгән язучылар да аның белән фотога төшә алган булсалар, бу рәсемнең кыйммәте алай ук игътибарны җәлеп итмәс иде һәм мин дә бу истәлекне язып тормас идем. Хәер, сүзне шунда катнашкан язучыларның, галимнәрнең үзләренә бирик әле.

Ренат Харис: «Ике мишәр, сез генә булдырасыз, иң шәп урыннарны алып куегыз, дигән максат куелганлыктан, без, Тәлгат Галиуллин белән бергә, съезд ачыласы көнне иртәниртүк торып киттек. Кремльнең Зур Сараенда олы зал ачылмаган, ишек төбендә сакчылар гына тора иде әле. Күпмедер вакыттан соң, «Сим-Сим ишекләре» ачылып китте. Керәбез – зал буш, уртада, алгы рәттә, бер кеше генә утыра. Шул турыда, нәкъ трибуна каршыннан без бөтен делегациягә җитәрлек урыннарны биләп алдык. Бераздан халык тула башлады. Барысы да безнең урынга кызыгалар, әмма без нык торабыз. Мәскәү шагыйре Сергей Островой үзенең үҗәтлеген монда да күрсәтеп алды. Теге кеше рәтенә килә дә урын даулый, килә дә урын даулый. Ахырда теге кеше, гафу үтенеп, бу рәт Үзәк Комитетның культура бүлеге өчен, дип әйтеп салды. Булмагае, язучылар съезды ич бу, дип, Островой барыбер шул рәткә килеп утырды.

Минем бер ягыма – Дания Хөсәеновна Зарипова (КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире), икенче ягыма Сергей Петрович Кошечкин («Правда» газетасының культура бүлеге мөдире) туры килде. Съезд башланырга биш минут кала озын буйлы ике ярдәмчесе белән Раиса Максимовна килеп керде һәм нәкъ минем каршыдагы урындыкка утырды. Киенүе бик пөхтә, килешеп тора, бик затлы да, бик гади дә сыман иде. Артка борылып, ул миннән съезд документларын сорап алды. Исемлекне карады-карады да: *«Вот, посмотрите, опять несправедливость, ни одной женщины за столом президиума. Везде и всюду у нас зажимают женщин. А ведь есть прекрасные писатели-женщины!»* – диде.

Чынлап та, сәхнәдәге президиумга сайланганнар чыгып утыргач карыйбыз – гел ир затлары гына. Раиса Максимовна тагын безнең якка борылды да: *«Әнә карагыз, нәкъ исемлектәгечә, бизәк өчен генә булса да ник бер хатын-кыз булсын!»* – диде.

Съезд барышында минем башка бер уй килде. Дания Хөсәеновнага әйтәм, безнең бик матур сувенир китабыбыз бар – Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре», барыбыз да кул куеп, бүләк итик Раиса Максимовнага, дим. Тәнәфестә шулай эшләдек тә…

Чыгышлар вакытында Раиса ханым, артка борылып, теге яки бу язучы хакында сорый, Мәскәүнекеләрне яхшы белгән Кошечкин аның шәхси консультантына әверелде. Милли әдәбият вәкилләре трибунада күренә башлагач, мин дә әңгәмәгә кушылып алгаладым.

Озын тәнәфес алдыннан Дания Хөсәеновнага әйтәм, әйдәгез, бөтен делегация белән истәлеккә фотога төшик, Сез аңа тәкъдим итеп карагыз, дим. «Бездән күрмәкче башкалар да чакыра башласа… Уңайсыз булмасмы, син үзең тәкъдим итеп кара», – ди Дания ханым. Тәнәфескә чыкканда мин: «Раиса Максимовна, делегация татарских писателей обращается к Вам с убедительной просьбой… Не сможете ли Вы с нами сфотографироваться на память?» – дип мөрәҗәгать иттем. Ә ул гади генә итеп: «А почему бы и нет!» – дип җавап бирде. Шуннан соң инде без Гәрәй Рәхимне фотограф артыннан йөгерттек. Георгиевский залда көтеп тор, дидек. Раиса Максимовнаны уртага алып, вестибюльгә чыктык. Георгиевский залга керергә тәкъдим ясагач, ул: «Ә нигә анда керергә, шушында гына басып төшик», – диде. Шул мизгелдә әллә каян гына фотографлар пәйда булды. Раиса Максимовна янәшәсеннән урын алу мәсьәләсенә килгәндә…

Хәер, анысы башка хикәя…

«Анда безне фотограф көтеп тора, әйдәгез, тизрәк!» – дип, Гәрәй Рәхим килеп җиткәндә соң иде инде. Башка өлкәләрдән килгән делегатлар да фоторәсемгә төшәргә талпынып караган иделәр дә… Раиса Максимовна, саубуллашып, президиум бүлмәсенә кереп китте.

Башкорт туганнарга җитә калды. «Да, егетләр, сезнең хәзер һәр адымыгыз күзәтү астында булачак…» – дип шаяртып алгаладылар.

Икенче көнне төшке аш вакытында берәү килеп җилкәмнән кага. «Сез Казаннанмы? Тәрәзә янына барыйк әле», – ди. Йөрәгем жу итеп китте. Башкорт дусларның кинаяле шаяртуы искә төште… Тәрәзә янында ул кесәсеннән бер конверт чыгарды. Анда безнең фото

иде. Артына барыбызның да исем-фамилияләрен яздыртып чыкты. Тагын бер көн үткәч, янә берәү килеп: «Сез Татарстаннан бит әле, менә Раиса Максимовна Сезгә тапшырырга кушты», – дип, зур конверт сузды. Анда безнең күмәк төшкән шушы фотолар иде.

Ә Сергей Островой, безнең Раиса Максимовнага китап бүләк итүебезне күргәч, кызыгып, үзенекен алып килмәгәнгә бик офтанып торган иде. Икенче көнне ул тагын да шәбрәк киенеп килгән, кулына калын-калын ике томлыгын тоткан иде. Съезд беткәнче күтәреп йөрде ул китапларын, ләкин Раиса Горбачева бүтән күренмәде…»

Тәлгат Галиуллин: «Съезд ачылды. Бездән алдагы рәттә ниндидер ханым япон ручкасы чыгарып яза башлады. Мин аның үзеннән битәр шул затлы ручкасына игътибар иттем. Безнең арадан беренче булып аны Ренат Харис танып алды. «Егетләр, бу Михаил Сергеевичның хатыны түгелме соң?..» – ди. Шуннан соң инде минем өчен доклад, съезд кайгысы бетте. Күзләр Раиса Максимовнада. Ул, артка борылып, безнең кайдан килүебез хакында сорады. Докладчы Виктор Астафьевның «Ловля карасей в Грузии» дигән әсәрен телгә алгач, грузиннар, ярсып, урыннан кычкыра башладылар. Шулчак Раиса ханым, борылып: «Сез ул әсәрне укыган идегезме?» – дип сорады. Язучы халкы, укымаган булса да, һәрчак, укыдым, дип әйтә. Без дә шулай, әсәрне мактаган булып, сүзне икенчегә борырга тырыштык. Докладта телгә алынган башка әсәрләр турында да ул сүз кузгаткалап торды.

Тәнәфестә безнең язучылар аңа бүләк итәргә дип үз китапларын алып килделәр. Илдар Юзеев кулында да китап бар иде бугай… Шунда мин, кинаяләп: «Егетләр, Михаил Сергеевичның китапханәсен юк-бар белән тутырмагыз инде», – дигән булдым.

Озын тәнәфестә без Раиса Максимовнага фотога төшәргә тәкъдим иттек. Ул, әлбәттә, риза булды.

Башкорт язучылары: «Сез анда апай белән бик елмаешып, сөйләшеп утырмагыз. Президиумнан Михаил Сергеевич гел сезнең якка карап утырды, көнләшмәгәе!» – дип шаярып, үзләренең арткырак рәтләргә эләгү «бәхетен» капларга тырыштылар».

Миркасыйм Госманов сүзләренә игътибар итик: «Раиса Горбачева ул кадәр игътибарны җәлеп итәрлек чибәрләрдән түгел. Әмма кеше белән мөгамәләсе йомшак, сөйләшә башлагач, бик ягымлы күренә иде.

Фотога төшәргә дип җыелышкач, мин аның янәшәсенә туры килдем. Карыйм, аксакалыбыз Әмирхан ага читтәрәк калган, уртага керергә теләге дә бар шикелле… Муеныма кайнар тыны да бәрелгәч, урынымны морзага бирергә туры килде. Раиса ханымның беләген ычкындырып иң кырыйга чыгып бастым.

Язучыларның киләчәктә таркалачагы ачык күренеп торган бу шау-шулы, болгавыр съездның бер истәлеге булып шушы тарихи сурәт калды.

Актыктан Әмирхан аганың үзалдына сөйләнеп торуы әле дә күз алдымда: «Патша хатыны белән фотога төштек дисез инде… Понимаете… Моның соңы ни белән бетәр икән, соңы…»

Әмирхан Еники: «Раиса ханымның әле зенитта, шөһрәтле чагы иде бит. Аның хакында Башкортстанда яшәгән икән, милләте татар икән дигән сүзләр йөри иде. Съезд вакытында: «Сез милләтегез белән татар түгелме?» – дип кемдер сораган, имеш. ***«Юк, мин татар түгел, ләкин татар-башкорт арасында яшәдем, ул ике халыкны да бик хөрмәт итәм»,*** – дип әйткән, имеш.

Бүләккә дип әзерләнгән Муса Җәлил китабына мин дә үз имзамны куйдым. Фотога төшкәндә, бер читкә баскан идем, син олы кеше, карт кеше, дип, Раиса Максимовна янына ук китереп бастырдылар. Ул арада сурәткә дә төшереп алдылар. Теге *(Әмирхан ага*

кеткелдәп куя) фотограф эзләп киткән Гәрәй Рәхим генә килеп җитешә алмый калды... Шуның белән эш бетте. Бүтән берни дә кирәкми, шул җиткән, дигән идем, ләкин күрәм... Әле берсе китабын китереп төртә, автограф куеп, әле икенчесе... Шагыйрьләр инде... Раиса ханым ала инде, рәхмәт әйтеп, нәрсә дисен...»

Сүзне башка әдипләргә бирик.

Илдар Юзеев: «Кайчан да булса, Кремль сарайларына барып, патша хатыны белән фотога төшәрмен дип төшләремә дә кермәгән иде. Бу – тарих бит...»

Гәрәй Рәхим: «Мин, бәхетсез, шулай итеп бер фотога да эләкмәдем. Фотограф табып килеп җиткәндә, таралыша башлаганнар иде инде. Ятып калганчы атып кал, дигәндәй, Раиса Максимовнага Мәскәүдә чыккан шигырь җыентыгын бирергә булдым. Ашыгам, нәрсә дип язарга да белмим. «Товарищу Михаилу Сергеевичу... – дип булмый бит инде, ул бит зур кеше... Шәхсән үз исемемнән генә язсам да, яхшы түгел кебек... Шуннан: «Раисе Максимовне и Михаилу Сергеевичу, выражая уважение татарского народа. Г.Рахим», – дип куйдым. Раиса ханым, рәхмәт әйтеп, кулын бирде. Китабымны нәни сумкасына салып тормады, янәшәсендә үткер күзле чибәр-чибәр егетләр бар иде, шуларга бирде. Соңыннан дуслар: «Кулыңны ап-ак чүпрәк белән урап йөр, Раиса ханымның кул җылысын сакла», – дип көлеп тә йөрделәр».

***

Бу язмага нокта куяр алдыннан, уйларым ике ярымшарга бүленде. Әмма, ниндидер бер хакыйкатьнең асылын ачасы килеп тә, гамьле сүз кодрәте җитмәүдән гаҗиз калдым. Уйлар агышын эзлекле сүз тезмәсенә әйләндерергә җитешә алмаган каләмгә үч итеп, шул фикеремнең кайтавазларын гына бирәм.

Бәлки, бу гомерлек сораудыр?

Дөньяда хатын-кызның тоткан урыны нинди?

Күпме акыл көчен мең еллар буена җимерүгә сарыф иткән ирләр кавеменә Тәңренең күңеле суынып бара түгелме?! Җир-ана тәнендәге тирән яраларга хатын-кызның шифалы кулы кирәгрәк түгелме?! Шулай булмаса... Технократия гасырының икенче яртысында күпме Ил ияренә Алла учыннан гына төшеп, Галиҗәнап хатын-кызлар утырмас иде... Бөек могҗизалар, ак чалмалы таулар арасында туган философлар иле, һәммә төрле диннәр бишеге – Һиндстанның мәгърур анасы Индира Гандины гына искә төшерик. Ул җирдән киткәч... дөньяның изге бер нуры сыктап сүнде шикелле...

Ярымшарның бер ягында – ир-егетләр... Ирләр генә булган җирдә йодрык кысыла, усаллык чикләре киңәя. Ир-ат кына торган йорт, алтынга төрсәң дә, ягымсыз, нурсыз, җансыз була. Идарәче даирәдә ир-атлар гына эшләгән ил-йорт-дәүләт тә шулай... Хатын-кыз исә, дәрәҗәле урында эшләсә дә, үзенең ана икәнен, тормышта илаһи хис – наз барын беркайчан да онытмый.

Саный китсәң, олы эшкә алынган хатын-кызлар аз дисәң дә бар бит әле дөньяда. Алар, авыр постаментларга менеп, һәйкәл булырга кызыкмыйча гына, якты хатирә булып, тарих хәтеренә керә баралар. Бүгенге, без шаһит дәвердә дә шулай...

XXI гасыр башыннан күп кенә дәүләтләр тәхетен хатын-кызлар биләячәк. Күренекле эш урыннарында хатын-кызлар утырачак. Бу – табигый зарурилык. Чөнки Җир-ананы саклап калырга, каты бәгырьлеләнә барган кешелекне юатып дәваларга кирәк...

1990 ■

Әкрам Галләмов һәм аның шигырь дәфтәре

Равилә Мөбарәкшина

Әкрам Галләмов

Әкрам Галләмовның шигырь дәфтәре

Кулъязмалар янмый, диләр. Хезмәт ветераны Рузалия Хаҗип кызы Гатиятова үзенең якын туганы – фронтовик Әкрам Галләм улы Галләмовның шигырьләр дәфтәрен көтмәгәндә-уйламаганда табып, аны күз карасыдай кадерләп саклый. Гарәпчә язылган әлеге шигырьләрне галим Зөфәр Мөхәммәтшин татарчага күчергән.

Кем соң ул Әкрам Галләмов?

Әкрам Галләм улы 1913 елда Чуашстанның хәзерге Козловка районындагы Әлмән авылында дөньяга килгән. Әтисе Галләм Сәгъдиевнең шул авылда яшәгәнлеге мәгълүм. РФ Оборона министрлыгының Үзәк архивыннан алынган белешмәдә күрсәтелгәнчә, 1 нче гвардия кавалерия дивизиясенең 3 нче гвардия кавалерия полкы сугышчысы, Козловка районы хәрби комиссариаты тарафыннан чакыртып алынган Әкрам Галләмов (документта фамилиясе язылмаган) 1943 елның 28 мартында Украина ССРның Днепропетровск өлкәсендәге Синельников районының Зеленый Гай дигән торак пункты тирәсендә хәбәрсез югалган. 1 нче гвардия кавалерия дивизиясенең 3 нче гвардия кавалерия полкы 1943 елның апрелендә таратылган.

Фронтовик Ә.Галләмовның шигырь дәфтәренә күз салыйк:

«Иптәшләр һәм туташлар, һәм сеңелләрем, һәм энекәйләрем, һәм туганнарым, һәм абыйларым, һәм апаларым, һәм әни-әтиләрем!

Менә мин сезгә үземнең шушы җырларымны истәлек итеп калдырам. Шушы җырларымны мине сагынып исләрегезгә алып укырсыз һәм җырларсыз.

Шушы җырларымны язып калдырам 1940 елның гыйнварында. Ә.Галләмов».

Әкрам Галләмов

Син сайрагач, мин дә җылыйм...

(Өзек)

Яңа пароход сайлыйлар Ак Иделдә буйларга,
Күңелләрем сезне уйлый, керми башка уйларга.
Сандугачым, ник сайрыйсың, юк бит синең тәхетең,
Син сайрагач, мин дә җылыйм, минем дә юк бәхетем.
Аклы ситса күлмәгемнең итәкләре маркалы,
Син дустыма хатлар язам очкан кошлар аркылы.
Аклы ситса күлмәгемне якалы итеп тектерәм,
Рәхәт яшәвеңне теләп, шуның белән бетерәм.
Бу хатларны язган чакта караңгы иде утыбыз,
Килешмәгән җире булса, килештереп укыгыз.
Канәфер чәчәк ата дип сөйләшәләр бервакыт,
Син дустыма теләп калам ямьле тормыш, ак бәхет.
Аккош оча күл күреп, былбыл оча гөл күреп,
Кайчан күрешербез икән икәү бергә бер булып?
И дускаем, сагынам сине, бер күрергә җан атам,
Син дустымнан хатлар килсә, хәсрәтемне таратам.
Аклы күлмәк мин тектерәм иртә белән кияргә,
Бергә булган көннәребез калды сагынып сөйләргә.
Иртән торып сулар сибәм – сачәк атсын гөлләрем,
Сачәк аткан гөлләр кебек үтсен синең көннәрең.
Җир җиләген табалмадым, инде каян эзләргә?
Якты тормыш, ак бәхетләр теләп калам сезләргә.
Син дустымнан аерылгач, мин бик җаман суладым,
Бөрелеп үскән каеннарга карадым да җыладым.
Сандугачлар сайраганда килер миңа бер хәбәр,
Синең өчен җанкайларым ник өзелә букадәр?
Безнең урам зур булса да, уртасында гөл түгел,
Син бәгырем булмагач, бер дә күңелле түгел.
Кулымдагы балдагымның исемнәре – Кадерем,
Югары алма тиз коела, шулай булма, бәгырем. ■

Мөһаҗирлектәге милләттәшебезнең «Тәрҗемәи хәлем» әсәре

Хатыйп Миңнегулов, филология фәннәре докторы



Хәсән Хәмидулла (1900-1988) үзен еш кына «Хаҗи Хәсән Низамеддин Хәмидулла (Кулик)» дип тә йөртә. Аның шактый озын гомер юлының тәүге 15 елы Сергач төбәгендәге Актук (Яңапар) авылында уза. Калган өлеше, нигездә, Финляндиядә. Әүвәл күбрәк бу илнең төньягындагы (башкаладан 860 чакрым ераклыктагы) Кеми каласында, шулай ук Ваза һәм Терийоки шәһәрләрендә яши. 1950 елның гыйнвар аенда Хельсинкига күченә. Гомеренең ахырына кадәр шунда яшәп, шунда ук җирләнә дә. Хәсән Хәмидулла дөньяның шактый гына илләрендә (Төркия, Алмания, Согуд Гарәбстаны, Польша, Русия һ.б. мәмләкәтләрдә) яши, ике мәртәбә хаҗга да бара. Татар, урыс, гарәп, фин, төрек, швед, немец һәм кайбер

башка телләрне дә белә. Мөһәндис (инженер) буларак та таныла. Хәсән Хәмидулла тормышын, нигездә, сәүдә шөгыле белән алып бара. Балта, тимер, агач эшләрен дә белә, йортын да үзе сала. Китап басу, типография эшенең дә остасы. Аллаһы Тәгалә аңа сәләт-талантны мулдан биргән. Финляндиядә беренче татар газетасы чыгару да бу тынгысыз һәм тырыш зат исеме белән бәйле. «Мәгърифәт» дип исемләнгән әлеге басманың тәүге саны 1925 елның 16 гыйнварында Кеми каласында дөнья күрә. Ул 1943-1977 нче елларда бик бай эчтәлекле «Шималь очкынлары» исемле журнал да чыгарып килә.

Хәсән Хәмидулла – барыннан да элек, әдип. Аның күпләгән шигырь җыентыклары, дистәләгән проза, драма, тарих китаплары бар. Фольклорчы һәм фантаст язучы да. 70 нче елларның башында ул «Хәсән Хәмидулла әсәрләре» исемле библиографик исемлекне бастыра. Анда авторның 45 китабы теркәлгән. Әле аннан соңгы елларда да бу олуг мәгърифәтче үзенең актив эшчәнлеген дәвам иттерә. Гомумән, фәнни әдәбиятта аның 60тан артык китап авторы булуы искәртелә.

Хәсән Хәмидулланың тормышы, күпкырлы эшчәнлеге Хатыйп Йосыф угылының китапларында, күпләгән мәкалә-хезмәтләрендә ярыйсы гына яктыртылган. Безнең тарафтан аның гарәп язуындагы шактый гына әсәрләре, шул исәптән «Яңапар тарихы» монографиясе (Хельсинки, 1954) дә киң катлам укучыларга җиткерелде.

Хәсән Хәмидулланың иҗат мирасында язучының «Үз тәрҗемәи халем...» (ягъни «Тәрҗемәи хәлем») мөһим урынны били. Авторның берничә дистә еллар буе кәгазьгә төшерелеп килгән бу язмалары төрле мәҗмуга-җыентыкларда басылган. Аның, мәсәлән, 1972 елда Хельсинкида дөнья күргән «Ник алай? 5. Финляндия мөселманнарының тарихи материаллары» җыентыгының шактый өлешен «Тәрҗемәи хәлем» язмасы (дөресрәге – аның берничә кыйсеме) алып тора. Без, нигездә, әлеге автобиографик әсәрнең шушы китаптагы тексты белән эш итәрбез.

Әүвәл үк шунысын да искәртик: Хәсән Хәмидулланың бу әсәре, бер яктан, авторның тормыш юлын, күптөрле эш-гамәлләрен күзалларга ярдәм итсә, икенче яктан, гомумән, мөһаҗирлектәге милләттәшләребезнең тереклеген, рухи һәм матди яшәешен, шулай ук халкыбыз тарихын, шул чор иҗтимагый вакыйгаләләрен дә билгеле бер дәрәҗәдә аңларга булыша. Анда башка кавемнәрнең, иң беренче чиратта, финнарның яшәешенә, тормыш-көнкүрешенә мөнәсәбәтле шактый гына факт-мәгълүматлар, күзәтүләр бар. «Тәрҗемәи хәлем» авторы үз язмасында шәхси тормышында зур вакыйга рәвешендә улы Гомәрнең 1928 елның 15 декабрендә тууын да искә ала. Бу уңай белән шунысын да искә төшерик: 1990 елда Финляндиядә өч айлык гыйльми командировка вакытында мин Гомәр әфәнде, аның энесе Хөсәен (1955 елгы) белән кат-кат очраштым; төрле темаларга сөйләшүләр дә истә. Аларның өендә кунакта булырга да туры килде. Хәсән ага Хәмидулла торган йорт үзе бер музей кебек. Анда гаҗәеп күптөрле материаллар, аеруча китап-кулъязмалар, типография җиһазлары һ.б. тупланган. Гомәр һәм Хөсәен әфәнделәргә без бик рәхмәтле. Бу игелекле затлар Хатыйп Йосыф угылына Финляндия татарлары, әтиләре хакында күптөрле факт-мәгълүматлар бирделәр, күпләгән китаплар бүләк иттеләр.

Автор язуынча, аның «Тәрҗемәи хәлем» әсәре, дөресрәге аның I-IV бүлекләре мондый өлешләрдән гыйбарәт: «Сабыйлык дәвере», «Мәктәб дәвере», «Финляндиягә сәфәр», «Оуленбургта», «Терийокида», «Янә Оуленбургта», «Янә Терийокида», «Төркиягә һиҗрәт», «Польша тәмугында», «Варшауда», «Алманиядә», «Төркиядә», «Төрек тәмугында», «Искешәһәрдә». Бүлекләрнең исемнәре генә дә

авторның төрле шәһәрләрдә һәм илләрдә булуын, яшәп алуын, тормыш юлының шактый катлаулы, борылмалы икәнлеген ачык күрсәтеп тора.

Югарыда телгә алынган һәм хәзерге вакытта кулыбызда булган «Ник алай?» җыентыгында (1972) «Тәрҗемәи хәлем» язмасының «Финляндиядә» исеме астында шактый гына зур кисәге бирелгән. Без аның тәүге өлешен (158–163 битләр) «Янә Финляндиядә – Ваза шәһәрендә» дип исемләдек. Ни өчен? Чөнки биредәге вакыйга-хәлләр, нигездә, 20 нче елларның икенче яртысына карый. Мәгълүм ки, автор инде моңа кадәр үк дистә еллап Финляндиядә – Суомида гомер кичерә. Аның үзе язуынча, ул 1926-1927 нче еллар аралыгында елга якын Төркиядә яшәп ала. Күрәсең, анда авторның сәүдә эшләре уңмый һәм ул 1927 елның ноябрендә Финляндиягә әйләнеп кайта [шунысы мөһим: Хәсән Хәмидулла инде бу илне «үз ватаныбыз» дип атый] һәм бераз вакыт Ваза шәһәрендә яшәп ала. Аннан әтисе янына – әүвәл үзе яшәгән Кеми каласына әйләнеп кайта.

Без чит илләрдә сатып-алу белән шөгыльләнгән милләттәшләребезнең эшгамәлләрен, рухи халәтләрен тиешенчә аңлап та бетермибез бугай. Ничектер, бар да җиңел, уңай бара кебек тоела. Хәсән Хәмидулла язмаларында сәүдә эшенең шактый катлаулы, мәшәкатьле шөгыль икәнлеге күзаллана, биредә югалтутабуларның, кайгы-шатлыкларның, борчу-мәшәкатьләрнең еш кына үзара үрелеп баруын күрәсең. Сәүдәгәрлек белем-тәҗрибәне дә, зирәклек-тәвәккәллекне дә таләп итә икән.

«Безнең мирас» журналының 2021 елгы 12 нче һәм 2022 елгы 1 нче саннарында Хәсән Хәмидулланың Хатыйп Йосыф угылы әзерләгән «Совет Русиясендә кунакта» исемле язмасы тиешле шәрех-аңлатмалар, кереш мәкалә белән нәшер ителгән иде. Әүвәл «Милли юл» журналының 1929 елгы саннарында дөнья күргән бу язма да «Ник алай?» җыентыгында «Тәрҗемәи хәлем»нең бер өлеше буларак тәкъдим ителә. Анда авторның «Совет Русиясенә» сәфәренең аерым сәбәпләре, мәшәкать-кыенлыклары аңлатылып та китә.

Гадәт, традиция нигезендә без мөһаҗәрәттә гарәп, өлешчә латин графикаларындагы элеккеге текстларны хәзерге укучыларга тәкъдим иткәндә, аларның имла, тел-стиль хосусиятләрен мөмкин кадәр сакларга тырышабыз. Биредә дә шул принципка тугры калырга омтылдык.

Әмма бу уңай белән шунысын да әйтик: чит мәмләкәтләрдә дөнья күргән татарча текстларның шактые автор ничек язса, редактор, корректорның җентекле тикшерүеннән дә узмыйча, шул килеш басылып та чыккан. Имлада рәсми рәвештә илдә, Казанда кабул ителгән таләпләр дә бик искә алынмый. Тукай чорындагы тел-стиль, язылыш традицияләре дәвам иттерелә. Хәсән Хәмидулла язмаларында да без моны ачык күрәбез. Автор еш кына диалекталь сүз-формаларын да, үз даирәсендә кулланылган гарәп һәм төрек алынмаларын да язмаларына кертеп җибәрә. Мәсәлән, ул базар сүзенә синоним рәвешендә төрек телендәге «чаршы», мишәр диалектындагы «рынок» («рынка») сүзләрен дә куллана. Хәсән Хәмидулла үзе яшәгән җирлектәге кайбер атама-терминнарны да чит итми. Аерым сүз-гыйбарәләрнең язылышында төгәлсезлекләр («опечатки»лар), бәхәсле урыннар да очрый.

Гомумән, гарәп графикасындагы бу төр текстларны хәзерге язуга күчерү шактый авыр, четерекле. Шуңа күрә безнең тарафтан да аерым хаталар, төгәлсезлекләр җибәрелүе гайре табигый күренеш түгел. Андый җитешсезлекләребез өчен укучылардан алдан ук гафу үтенәбез.

[«Ваза шәһәрендә»] кыйсеменнән соң «Кемидә» һәм кайбер башка бүлекләр килә.

Безнен мирас №5 май 2022

«Тәрҗемәи хәлем»

(Аерым бүлек-кисәкләре)

Хәсән Хәмидулла



[Янә Финляндиядә. – Ваза шәһәрендә]

(158 бит) Без әле Финляндиядә. Өмидсез хәлдә Төркиядә яшәб, ким-хур, мескен булыб беткән җан-тәннәремез гүяки инде монда тереләчәк, инде алар безгә төш күрү кебек кенә калачак кеби өмидлар эчендә фин туфракына аякларымызны басканда күңелләремез боек, мондагы кешеләр һәм дустлар арасында мескен булыб, оялыб торуларымыз тиз үк бетмәде. Бу оялулардан, мескенлекләрдән котылыр һәм аларны онытыр өчен инде бу йир туфрагында да күреләчәк газабларымызны вә тормыш белән тартышуларымызны тату кирәк буладыр.

***

Без Һельсинкига фин вапуры (пароходы. – Х.М.) «Арйадани» илә килеб төшкәндә 1927 нче елның ноябрь 21есе иде. Зур дөньялардан кайтыб килгәч, Һельсинки бик кечкенә һәм бик тын, тар урамлы бер авыл кеби, гүяки, урам урта-

сында ятыб йоклаб була кеби тоелды. Элекдә торган Кеми шәһәрендән ара-сыйра Һельсинкигә килгәндә бик зур шәһәр булыб күренгән бу Һельсинки шәһәренең мондый тын һәм кечкенә булуына хәйранга калыб, бераз гакыл җыйгач, Хәсән-Җәмаллар белән бер фикергә килеб, бәяле «Турни» һотеленә такен алыб килдек. Бәяле һотельгә төшүемезнең сәбәбе шул: мондагы халкымыз безне фәкыйрь хәлдә икәнемезне белмәсенләр өчен иде.

Һотельгә төшеб, беренче эшемез юлдан килгән тузан-пычракларымыздан арулану һәм безгә инде бик тансык булган каймак белән фин каһвәсен эчү һәм күземездән очкан, безгә тансык булган финнең «маййәри вуинә» (Тирйоки) белән кара икмәк ашау булды.

Без инде әле финдә, үз ватанымызда, үз якынларымыз арасында булганымызны үземезгә-үземез хис итеб, шадлыкларымызга чыдаша алмыйча килгән хәбәрләремезне белгертер өчен анда-монда телефонлар биреб маташкач, иң беренчегә Хәсән Җәмалның олуг агасы һәм барымызның да дәдәсе һәм терәгемез булган Гыймад Җәмалга җыйнаулашыб килеб, алар белән аглашыб, кочаклашыб күрешкәндән соң, чәй янына ук имамыбыз Вәли Әхмәд Хәким вә «Җәмәгате (Җәмгыяте. – Х.М.) Исламия»нең рәисе Зоһур Таһир бәк килде.

Күрешүләр, шадлыкдан еглашулар мәрасиме бетдекдән соңра, безнең букадәр беткәнебездән, картлык чыраена керүләремездән бәхәс иделеб, серләремезне яшерер өчен: «Төркия һавасы шундый икән, эссе, фәлән», – диеб кенә котыла алсак да, өстләремездәге искерә башлаган киемнәрнең зәгыйфьлелекләре хакында оялуымызны качыра алмый идек.

Әтиемә – Кемигә кире кайтуымыздан телеграмм сугу белән Ваза шәһәренә туганым Хәлимәгә телефон биреб, аларны да шадландыргач һәм, шөбһәсез, без мондан Кемигә барышлый юл өстендә булган Вазага төшәчәгемезне дә вәгъдә биргәч, монда чәй янында инде бөтен хәл вә әхвальләремездән, аз-маз гына Төркияне бик усалланмыйча сөйләшкәч, дәдәмез Гыймад Җәмал һәм шуларга катнашыб имам Зоһур Таһир бәйләр минем инде кире Кемигә торырга кайтмавымны, ул бик ерак һәм кечкенә шәһәр, миңа инде әле, шөбһәсез, яңа бәхет белән башлаб, Вазага төшеб, анда калырга вә эшкә анда башларга яхшырак булыр икәнлеген киңәш итделәр.

Төркиядән фәкыйрь хәлдә булыб кайтканымызны сер итеб тотканымыз өчен, миңа бу әлдә акчалы диеб уйлаган бу дәдәләрнең киңәше бик урынлы булса да, минем кесәм сай икәнен белсәләр иде, бәлки, башка төрле киңәш бирерләр иде диеб эчемдән генә уйлаб, аларның бу яхшы киңәшләренә каршы мин: «Багармыз…, бәлки, шулай яхшы да булыр (159 б.), … бәлки, анда калырмыз да», – диеб кенә җаваб бирдем.

Безне кунакдан-кунакка йөртүләре сәбәбле, безгә монда ике көнгә һотелемездә калырга мәҗбүр булынды. Төрән (поезд. – Х.М.) билетләремезне Вазага кадәрле алыб, Вазага күрешергә китдек.

Хәсән Җәмалның борадәре (туганы. – Х.М.) Гыймад белән ширкәтләре бергәлек булган булыб, бергәлекләрдән Төркиягә киткәндә аерылган заманларыбызда калган кибет (дөкән) ачарга алачаклары калган булуы сәбәбле алар икәүдән икәүгә сөйләшеб, шуларга чыккан өлеше белән дөкан ачарга диеб Турку шәһәренә китделәр.

Басмага филология фәннәре докторы
***Хатыйп Миңнегулов** әзерләде.* ■

Остазыбыз Исхак хәзрәт Лотфуллин

Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Зөлфәт хәзрәт Мингалиев

Исхак хәзрәт Лотфуллинны искә алу кичәсеннән фото һәм видеорепортаж белән журналыбызның сайтында һәм социаль челтәрләрдә таныша аласыз.

Исхак хәзрәт Лотфуллин – үзгәртеп кору чорында зур роль уйнаган шәхесләрнең берсе. 70 ел буена диннән биздерелгән, әдәп-әхлак төшенчәләре дә бик саеккан халыкның дини-милли аңын уяту, югалып барган кыйммәтләребезне кайтару юлында башлап йөрүчеләрдән булды ул. Исхак хәзрәт, милләткә, дингә нинди мөнәсәбәт булуын үз башыннан кичергәнлектән, проблеманы эчтән белгәнлектән, чор биргән форсатны кулдан ычкындырмас өчен бөтен барлыгы белән эшкә чумды. Үзе генә яныпкөймәде, янына фикердәшләр, теләктәшләр дә туплый белде. Кая гына барып чыкмасын, аның янында үзе кебек кыю, туры сүзле, үткен фикерле көрәштәшләре булыр иде. Әмма ул бу эшләргә урау юллар аша килде.

Ленинград артиллерия академиясе һәм Германиядә хәрби хезмәт

Исхак Лотфуллин 1942 елның 25 февралендә Әлмәт районындагы Елховой авылында балта остасы гаиләсендә дөньяга килә. Бу авылга аның дүртенче буын бабасы Хәсән чукындырудан качып килеп утырган була. Әтисе – Мөхәммәтгата, әнисе – Шәһидә. Мөхәммәтгата бабай 1980 нче елларга кадәр үз авылында имам вазыйфаларын башкара.

Дини гыйлемгә омтылыш Исхак хәзрәткә кечкенә вакыттан ук сеңгән. Тик мәктәптә укуын бетерүгә дини уку йортына керергә насыйп булмый аңа. Бөгелмәдә училище тәмамлап, газ-бензин заводында, «Бохара-Урал» газүткәргечендә эшли. Термез шәһәреннән армиягә алына. Пенза югары артиллерия училищесында укып чыга. Булачак хатыны Галия ханым белән дә шунда таныша. Хәрби хезмәтен Хабаровск, Новороссийск һәм Баку шәһәрләрендә үтә. Ленинград шәһәрендәге артиллерия академиясендә белем ала. Хезмәтен подполковник дәрәҗәсендә Германиядә тәмамлый.

«Кабан арты»нда иман нуры

Кабан арты мәчете 1922-1923 нче елларда Болгар дәүләтендә исламның рәсми рәвештә кабул ителүенә 1000 ел тулу уңаеннан төзелгән була. Шуның өчен бу гыйбадәт йорты Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәчет дигән атама астында да танылa. Әмма озак эшләми: 1930 елның 6 февралендә ТатЦИК Президиумы карары нигезендә ябыла. Дини яңарышның гыйльми үзәге булган Кабан

арты мәчете мөселманнарга 1990 елның 12 ноябрендә кайтарыла. Мәчет әһелләре биредә үзләре ремонт ясый, тора-бара иганәчеләр дә табыла. 1991 елның август аенда биредә гыйбадәт кылына башлый. Әлхәмдүлилләһ, шуннан бирле анда намаз уку өзелми. Әлеге тырышлыкның тагын бер нәтиҗәсе – мәчет айлы да була. Кабан арты мәчете манарасының ае Казанда I Бөтендөнья татар конгрессы узган көннәрдә – 1992 елның 20 июнендә яңадан куелды. Шул көннән башлап Кабан күле буенда әллә кайлардан күренеп торган бу күркәм мәчет үзенең асылына кайтты.

«Мәдрәсә ишегеннән атлап керүче милләткә файда итүче булсын!»

1991 елның 11 июлендә СССРның Европа өлеше һәм Себер мөселманнары Диния нәзарәте пленумы «Кабан арты» мәчетендә мәдрәсә ачу турында карар кабул итте. Мәдрәсәне оештыручылар, уку йортын, үзен сыендырган гыйбадәт йортының икенче исеме белән, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә дип атарга карар кылдылар. Шулай итеп, 1991 елның 5 октябреннән Россиядә совет чорыннан соң беренче мөселман дини уку йортында дәресләр башланып китте. Мәдрәсә оештыруны башлап йөрүчеләрдән остаз Габделхак хәзрәт Саматов һәм мөдир Исхак хәзрәт Лотфуллин булды. Мөгаллимнәрдән Зәкәрия хәзрәт Минвәлиев фикһ, сарф, нәһү укыта башлады. Җәгъфәр хәзрәт Мөбарәк шәкертләргә Коръән, тәҗвид кагыйдәләрен өйрәтте. Бирегә укырга килгән беренче шәкертләр арасында Ильяс хәзрәт Җиһаншин да бар иде.

Җитәкчеләребез халык үтенечен колак салды. Барлык тарихи мәчетләр дә мөселманнарга кире кайтарылды. Бу эшләрнең башында Исхак хәзрәт Лотфуллин (уңда) торды.

Бер үк вакытта Исхак хәзрәт дини китаплар бастыру һәм таратуның юл башында торды. 1992 елны Татарстанда Диния нәзарәте оештыруда да ул башлап йөрде. Хәзерге көндә күп имамнар, мөфтиләр Исхак хәзрәт Лотфуллинны остаз дип саный. Аның һәр эш-гамәле системалы, алдан уйланылган иде, диләр. Мәдрәсәне башта ике еллык, аннан соң югары мәдрәсә итеп оештыру максатына эзлекле килдек. Гарәп телен камилләштерү ниятеннән шәкертләрне чит илләргә җибәреп укыту, мәзһәби мәсьәләләрдә телне, динне, гореф-гадәтләрне онытуга юл куймау – уку-укытуга куелган төп принципиаль таләпләре менә шул иде аның. Шәкертләр арасында халык белән эшләү сәләтен күрсәткән, мәхәллә тормышын алып бару таләпләреннән хәбәрдар егетләрне күрә икән, аларны авылларга хәзрәт итеп җибәрү яклы булды.

Гыйлемле имамнарга кытлык зур була ул елларда. Шунлыктан вәгазь сөйләргә осталыгы ачылган, мәҗлесләр алып бару тәҗрибәсенә ирешкән һәр шәкерткә мәхәлләдә хезмәт итәргә хәер-фатыйхасын бирә иде ул.

Шәкертләр күп була мәдрәсәдә. Ул чакта халык күңелендә «Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен» дигән уй-ният көчлерәк иде. Малга ыргылмадылар, акча төшенчәсе, ничектер, бүгенге кебек алгы планда түгел иде. Мәчет-мәдрәсә бусагасын атлап керүче – олы яшьтәме, бик яшьме, тоткынлыктан әле генә азат ителгәнме яисә дәрәҗәле урын билиме – бер уйда, бер теләктә иде: Аллаһы Тәгалә ризалыгына ирешергә омтылу, Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен гыйлем алу. Шунлыктан халык белән эшләү, аңлашу җиңел, ихлас була бу елларда. Дини уяну, күтәрелү чорының тагын бер куанычлы үзенчәлеге: мәдрәсәдә сабак алучылар арасында, вакытны сузмыйча, үз тирәлекләрендә дәрес бирергә, белемне башкалар белән уртаклашырга ашыгучылар, дәгъват эшенә алынучылар күп була. Исхак хәзрәтнең шәкертләр белән эшләү, максатларны дөрес кую нәтиҗәсе болар. Аның өчен иң мөһиме – соңгы нәтиҗә: мәдрәсә ишеген ачып керүче киләчәктә дингә, милләткә файда китерүче булсын!

Булачак дин әһелләре сарык асрады, сыер тотты

Укыту-тәрбия эшендә вак нәрсәләр булмавын белеп оештыра ул мәдрәсә эшчәнлеген. Шәкертләрне эш белән тәрбияләүне максат итә. *«Әгәр шәкерт 24 сәгать буена мәшгуль булмаса, укуын тәмамлаганда аннан кем килеп чыга – моны күз алдына китереп тә булмый. Дин әһеле хуҗалыкта да эшли белергә, ризык та пешерергә өйрәнергә, кешегә салынмыйча, үз-үзенә хезмәт күрсәтә белергә тиеш»,* – дия иде.

Мәдрәсә Кабан арты мәчетендә эшләгәндә, мәчет ихатасы киң, иркен иде. Исхак хәзрәт аның буш ятуына юл куймады: бергәләп алмагач бакчасы ясадык, күп итеп яшелчә утырттык. Монда инде берәү дә эшсез селкенеп йөрми, вакыт узмаудан зарлана алмый. Абзарлар төзеп, сарыклар асрадык, савым сыерларына кадәр тоттык берара. Болар барысы да дәресләрдән соң шәкертләргә бер дигән хезмәт дәресе булды. Бездә укыган шәкерт үз көнен үзе күрә белергә, җәмгыятьтә үз урынын табарга тиеш дигән ниятнең эзлекле төстә гамәлгә ашырылуы иде болар.

Шәкерт тормышын җанландыру, кызыклы һәм файдалы итүне дә кайгырта иде хәзрәт. Егетләр өчен төрле конкурслар оештыру дисеңме, кызыклы шәхесләр белән очрашулармы – болар барысы да милли җанлы, һәрьяктан хәзерлекле кадрлар тәрбияләүгә хезмәт итте.

Шәкерт халык белән булырга тиеш, дигән принципның чишелешен таба иде Исхак хәзрәт: Рамазан аенда шәкертләрне мәхәлләләргә таратып, тәҗрибә туплау, укыганны гамәлдә куллану ысулы үзен аклый. Корбан гаете якынлашканда да өч көн алдан шәкертләр авылларга тарала, мәхәллә белән танышып, гает намазы үткәрә. 1552 елда Казанны Явыз Иван гаскәрләреннән саклап шәһит киткәннәрне искә алу – Хәтер көненә карата, анда шәкертләрне алып баруга да үз фикере, дәлилле карашы бар иде аның. Мәдрәсә шәкертенең Сөембикә манарасына менеп азан әйтүе, аннан соң сабакташлары, җәмәгать илә намаз укып, шәһитләрне дога белән искә алуы, Коръән укуы тиңе булмаган тарих дәресе дә булды.

«Һәр имам ана телен белергә тиеш!»

Исхак хәзрәт Лотфуллин халык белән эшләргә тиешле дин әһелен тормышта актив позицияле шәхес итеп тәрбияләүне күз уңыннан һич ычкындырмады. Ул бик

Исхак хәзрәт Лотфуллинның хатыны Галия абыстай

Исхак хәзрәт Лотфуллинның лаеклы дәвамчылары – Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан Югары Мөселман мәдрәсәсе шәкертләре

еш: *«Динне гадәти, көндәлек тормыштан аерып караудан сак булыгыз. Моның әллә кая алып чыгуы бар. Шушы җәмгыятьтә, шушы тирәлектә башкалар белән аралашып яшәү өчен әзер булыгыз, күпкырлы шәхес булып формалашыгыз. Һәр имам илкөн вакыйгаларыннан да хәбәрдар булырга, халык белән татар телендә аралашырга, ана телен белергә тиеш»,* – дип әйтә иде Исхак хәзрәт. Өйлә намазы тәмамланугa, хәзрәт мөнбәр янына килеп, шәкертләргә сәяси вакыйгалар, татар тарихы хакында сөйләде. Шәкертләрне бернидән дә битараф булмаска өндәп, халыкара хәлләрне, яңалыкларны шәрехләде.

Исхак хәзрәт – тарихи мәчетләрне халыкка кайтаручы

Элеккеге мәчет-мәдрәсәләрне мөселманнарга кайтару өчен көрәшнең бер төре – җитәкчеләр игътибарын җәлеп итү өчен пикетка чыгу иде. 1990 нчы елларда хәзрәт мондый чараларны бик еш оештыручы гына түгел, ә бу эшкә мәдрәсә шәкертләрен дә актив җәлеп итүчеләрдән булып тарихка кереп калды. Шуның нәтиҗәсе буларак, Казандагы Зәңгәр, Иске Таш, Солтан һәм Гали мәчетләре, Мөхәммәдия мәдрәсәсе һәм башка күп кенә тарихи биналар мөселманнарга кайтарылды. Алда әйткәнемчә, Кабан арты мәчетен кайтарып алу да, ташландык биналарны тиз арада төзекләндерү, озакка сузмыйча мәчеткә манара кую – барысы да Исхак хәзрәтнең тырышлыгы белән башкарылды.

Дуслар кирәк дөнья күтәргә

Исхак хәзрәт кемнәндер нәрсәдер көтеп, тартып-сузып эшләүчеләрдән түгел иде. Кыска вакытта таулар күчерергә, күп башлангычларга юл ачарга сәләтле һәм берьюлы әллә ничә эшне алып баручы имам булуы белән бүген дә күпләргә үрнәк-өлге булып тора ул. Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәчетнең беренче указлы мулласы, безнең мәдрәсәнең беренче ректоры буларак та исеме тарихка кереп калды аның.

Кая гына бармасын, аның аралашу даирәсе зур, дус-ишләре күп, теләктәшләре, фикердәшләре бөтен Россия буйлап таралган иде. Шунлыктан, очрашкач та, хөрмәт хисеннән күтәреп кенә алмыйлар иде инде үзен. Равил хәзрәт Гайнетдин, Дамир хәзрәт Гыйззәтуллин, Мөхәммәт хәзрәт Сәлахетдинов, Нәфигулла хәзрәт Аширов, Габделвахит хәзрәт Ниязов, Мөкаддәс хәзрәт Бибарсов, Аббас хәзрәт Бибарсов, Якуб хәзрәт Вәлиуллин кебек дини уяну чорының чишмә башында булучылар белән дустанә мөнәсәбәттә торды ул.

Җеназасын улы Сәиджәгъфәр хәзрәт укыды

Исхак Мөхәммәтгата улы 2007 елның 1 ноябрендә бакый дөньяга күчте һәм Казан читендәге Коры Елга зиратында җирләнде. (30 яшендә бакыйлыкка күчкән уллары Таһир биредә җирләнгәнлектән, гаиләсе шунда дәфен кылырга карар итте.) Мәрхүмнең җеназасын улы Сәиджәгъфәр хәзрәт укыды.

Һәр җәйнең бер матур көнендә Галия абыстай һәм шәкертләре Коры Елга зиратына барып, хәтер яңарта, дога кыла. Гомере буена иренең һәр башлангычына теләктәшлек күрсәтеп, дин исламны күтәрү юлында үзен аямый эшләгән Исхак хәзрәтнең уң кулы булды Галия абыстай. Аллаһы Тәгалә аның ихлас тырышлыгыннан разый булсын! ■

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов

Пекин шәһәрендәге Нуҗе мәчетенең безнең чордагы фоторәсеме

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

Кытай мәмләкәтенә исламиятнең керүе

Бу мәсьәләнең чынлап та мөһим мәсьәлә булуын берәү дә инкяр итә алмас. Риваятьләр буенча, һиҗри I гасыр ахырларында хәзрәте Кутейбе Мәвараәүн-Нәһер, Бохара, Ферганә, Кашгар юлы белән Пекинга кадәр килгән; ислам, башлангыч чорында, һиҗрәтнең 93 елында Кашгарга кергән. Бу хакта сөйләнгәннәрне биредә кабатлап, хөрмәтле укучыларымның зиһеннәрен мәшгуль итеп торасым килми, чөнки болай да бик билгеле нәрсәләр.

Кытайларның исә бу хактагы ышанулары бик сәер. Алар исламиятнең Кытайга Төркестаннан керүен катгый рәвештә инкяр итмиләр итүен, хәтта киресенчә, моны раслыйлар. Ләкин: «Ул хәл инде икенче тапкырында булды, исламият инде аннан да элегрәк, хәтта гасры-сәгадәт[1] чорында Көньяк Кытайдан Кантон шәһәренә кадәр килгән иде. Бу икенче тапкырында Төркестан Кытаеннан Пекинга кадәр килде», – диләр.

Кытайларның бу хактагы ышанулары бөтен тарихларга һәм Пәйгамбәр (с.г.в.) хәдисләренә каршы төшә. Шулай булса да, бөтен Кытай мөселманнары беравыздан шуны кабатлыйлар. Бу турыда язылган китаплары да аз түгел.

[1] Хәзрәте Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) җир йөзендә пәйгамбәр булып яшәгән чор *(тәрҗ.иск.)*.

Кытайга исламият, имеш, заманы-сәгадәттә килгән, хәзрәте Пәйгамбәр (с.г.в.) ул заманда өч кешене бу якларга илче итеп җибәргән. Болар – Саад бине (Эби) Ваккас, Касыйм, өченчесенең исемен әйтеп бирә алмыйлар. Шул ук вакытта Кантон шәһәрендә бу икесенең хәтта каберләрен дә күрсәтәләр. Саад бине (Эби) Ваккасның Хиҗазга кире әйләнеп кайткан булуын әйтәләр.

Бүгенге көндә Кантон шәһәрендә бер иске мәчет бар. Аны Сәйидина Саад бине (Эби) Ваккас мәчете дип атап йөртәләр. Моннан тыш, кытайларда Ван-Куан гаиләсе бар, болар үзләрен Сәйидина Саад бине (Эби) Ваккас нәселеннән дип саныйлар. Имеш, Сәйидина Саад бине (Эби) Ваккас бу җирләрдә яшәгәндә өйләнгән дә, хатынын авырлы килеш аерган. Шул хатыннан баласы һәм тора-бара оныклары туган. Бүгенге көндә нәселе зур гаилә тәшкил итә икән. Әлеге вакыйга шул рәвешле кытайларда ныклы ышану булып яши, киресенә ышандыруны күз алдына да китерерлек түгел. Исламиятнең Кытайга керүе турында кытай телендә бик күп тарихи китаплар язылган. Бу өлкәдә иң танылган тарихчыларының берсе Ван-дай-йу исемле кешенең ислам тарихына багышланган ике китабы бар икән. Әлбәттә инде, икесе дә кытай телендә язылган. Китапларның берсенең исеме – «Җин-җан-ташо», икенчесенең – «Җин-җав-җанҗуван». Болар, бик таралган һәм танылган булганга, китап итеп тә бастырылганнар.

Ван-дай-йу җәнапларының бер әсәрен Йу-нен голамәсеннән бер зат гарәп теленә тәрҗемә иткән һәм «Фусули Әрбаа»[2] дип атаган. Тәрҗемәченең исеме – әш-Шәйх Йусуф. Бу кеше дә кайчандыр бик танылган галим булган.

Моннан башка, үзләре Шикли дип йөрткән бик җентекле гарәпчә тарих китабы да тәрҗемә ителгән. Ләкин, кызганыч ки, эзләнүләремнең нәтиҗәсе күрсәткәнчә, китап итеп басылмаган.

Кытай телендә ислам тарихына караган бик күп китап бар. Болар, нигездә, күп укыла торган басма китаплар һәм кытайлар тарафыннан бик дәрәҗәле хезмәтләр булып санала. Мәсәлән, шундыйларның берсе – «Хэй-хэй-йун-лай» – бик җентекләп язылган тарих китабы. Хэй-хэй сүзендә «х» сүкүнле (ягъни «ыхы» рәвешендә) әйтелә һәм ислам дигәнне аңлата. Японнарның мөселманнарга фуй-фуй диюләре дә бу сүздән үзгәреп барлыкка килгән булырга тиеш.

«Чи-шен-шей-лу» һәм «Кан-ши-зан» дип атала торган «Сийери Нәби»[3] дә моннан 800 ел элек язылган китап итеп танытыла.

«Чай-лун-зан» исә кытай ханнарының берсенең әсәре икән, моннан 200 ел элек язылган. Башта исламиятнең яхшылыгы, матурлыгы турында сөйли дә, исламны Кытай илендә рәсми дин рәвешенә китерә алмавы өчен үкенүен белдерә.

Менә шул югарыда атап үтелгән бөтен китапларда да Кытайга исламиятнең керүе турында халыкта киң таралган риваять урын алган һәм бүгенге көндә дә бөтен кытай мөселманнарында ныклы ышану кебек яши. Мин бу хакта Нанкин шәһәренең тарихчылары белән дә бик күп фикер алыштым. Гаҗәп инде, Кытайның бөтен тарихчылары Нанкин шәһәренә тупланган диярлек. Элекке заманнарда тарихи вакыйгаларны сукырлар ятлый торган булган һәм буыннан-буынга яшәтә килгәннәр. Шул сәбәпле күбесенчә сукырлар тарихчы булганнар. Бу ысул мөселманнарда гына түгел, мәҗүсиләрдә дә киң таралган. Аларның да тарихи вакыйгалары башта телдән өйрәнелә, аннары гына язуда теркәлә икән.

Кытайга исламиятнең керүе турындагы тарихи риваятьләрне без һичбер вакыт ышанып раслый алмаячакбыз. Чөнки, Сәйидина Саад бине (Эби) Ваккас –

---

[2] Елның дүрт фасылы *(тәрҗ.иск.)*.
[3] Хәзрәте Мөхәммәднең (с.г.в.) яшәү рәвеше һәм әхлагы турындагы китап *(тәрҗ.иск.)*.

Пекин. XX гасыр башы

иң бөек сәхабәләрнең берсе һәм гашәрәи мүбәшшәрә[4] арасында бик танылган шәхес булганга, аның тәрҗемәи хәле дә мөселманнарда бик билгеле. Саад бине (Эби) Ваккасның андый илчелеге булган булса, бу вакыйганы, тарихчылардан бигрәк, хәдис гыйлеме белән шөгыльләнүче бөек һәм камил затлар теркәп калдырган булырлар иде. Хәдисчеләрнең хәзрәте пәйгамбәр (с.г.в.) әфәндебезнең сәгадәтле заманында булган хәлләрне, иң-иң кечкенәләренә кадәр, берсен генә дә калдырмыйча, һәммәсен теркәгәнлекләре бу гыйлем әһелләренә бик ачык билгеле.

Әгәр Кытайга кадәр мондый илче җибәрелгән булса, хәдисчеләр моны, һичшиксез, тиешенчә теркәп куйган булырлар иде.

Шул ук вакытта, кытайлар да үз тарихларын алай җиңел генә ялганга чыгарырга теләмиләр. Бу да – гаять табигый хәл. Халыкның борынгы чорлардан бирле яшәп килгән ышануы иманы дәрәҗәсенә җитә язган. Сәбәбе нәрсәдә генә булса да, бер генә милләтнең дә үзен ялганчыга чыгарту түгел, хәтта үз ышануларына каршы төшертәсе дә килми. Бу исә – бик гаҗәп нәрсә, минем фикеремчә, кешеләрнең сукырлыгына бер дәлил булып тора.

Безнең гасырда, ислам голамәсе булып йөрүчеләр арасында үзләрен ниндидер ялган яки ясалма ирекккә ия итеп күрсәтеп, шуны тарихка туры китерергә теләп, хәтта Коръән тәгълиматын да башкача аңлатырга маташулар булган. Болар – шаккатыргыч хәлләр. Фетнәче бичаралар, Көнбатышның белем дөньясында барлыкка килгән һәрбер дәһшәткә шаһит булган саен, аятьләрне үзгәртергә маташканнар, бүгенге белемгә сыйдыра алмаганга, фәрештәләрне дә хәтта башкача аңлатырга җөрьәт иткәннәр. (Аллаһ сакласын!)

Әйе, бу юлдан баручылар бер-ике кеше генә дә түгел. Безнең гасыр ислам голамәсе, барысы да диярлек, үз җаһиллеген шул рәвешле яшерергә маташа. Минем гаҗиз фикеремә күрә, боларның күбесе – күзләренә ислам билгеләре күренмәслек итеп пәрдә корылган кешеләр.

Күпме генә читкә китү булса да, бернәрсә мине боларны кисәтергә мәҗбүр итә.

Биредә төп максатым шуны аңлату: тарихтагы хаталар бер-ике генә түгел, аларны төзәтү өчен тәгълиматларны үзгәртүгә бер генә вөҗдан да риза булырга тиеш түгел.

Бу кешеләр борынгы тарихны түгел, башта, һич булмаса, күзләре алдында була торган бүгенге тарихи вакыйгаларны игътибарга алсыннар иде. Моннан 25-30 ел элек булган Мисыр инкыйлабы нәрсә булды, нинди сәбәпләр аркасында килеп

---

[4] Җәннәт белән бүләкләнгән дип санала торган ун сәхабә *(тәрҗ.иск.)*.

чыкты, нинди сәясәт алып барыла иде, кемнәрнең бармагы уйнады – болар турында катгый рәвештә фикер әйтә алабызмы? Вөҗданыбыз кушканча әйтсәк, боларга җавабыбыз юк, «катгый рәвештә» дип тә әйтә алмаячакбыз.

Аларга кадәр китмичә, моннан берничә ел элек кенә башыбыздан үткән вакыйгаларны сөйләшсәк тә, йөз төрле фикер булачак.

Димәк, тарихларга туры китерергә теләп, катгый тәгълиматларны үзгәртергә теләү турыдан-туры җинаять белән бер. Мондый голамәне голамә дип атау да дөрес түгел, тик ни чара, кеше кытлыгында кеше булган шул болар.

Минем фикеремчә, Шәригате гарраи мутаххара[5] кәефкә бәйле канун була алмый, ул – илаһи канун һәм, кемнәрнеңдер хәтерен саклап, аны үзгәртергә яки башкача аңлатырга ярамый. Бүгенге көндә иң алга киткәне тыйб (медицина) гыйлеме булса да, гыйлем кешеләре тарафыннан уртак фикергә килеп катгый кабул ителгән дарулар бик аз, калганнары күзаллау дәрәҗәсендә генә калган. Шуңа күрә бары тик күзалланган нәрсәләр хакына катгыйлашкан тәгълиматларны төзәтү, үзгәртү һич кенә дә мөмкин түгел.

Төп сүзебездән шактый еракка китсәк тә, хөрмәтле укучыларымның кичерәчәгенә ышанып, боларны да сөйләдем. ИншәАллаһ, вакыты җиткәч, матбугатта болар хакында да әтрафлы фикерләремне ишеттерермен.

Салар хатыны. XX гасырның беренче яртысы

Сала төркиләре[6]

Пекинда яшәгәндә, сала төркиләре турында да бераз мәгълүмат тупларга теләгән идем, ләкин тел мәсьәләсе авыр мәсьәлә булып чыкты, тел белмәвем сәбәпле, бу эш шактый кыен иде. Кайчакларда «Гон-Йан-Бав» газетасын чыгаручы Җав-Йу-Шин җәнаплары ярдәме белән беркадәр мәгълүмат ала алдым. Тик ул христиан иде, шуңа күрә минем өчен кирәкле һәм әһәмиятле нәрсәләр турында аннан алынган мәгълүмат та бик чикле иде.

Беркөнне мәдрәсәдә идем, бер кеше килде. Мөдәррис Нур Мөхәммәт әфәнде белән бераз сөйләшкәннән соң, үзенең Саладан килгәнен һәм шунда яшәвен әйтте. Шунда мөдәррис (укытучы) миңа: «Менә бу кеше сала төркиләреннән, шуннан килгән», – диде. Мин инде болай да, башында чәч үреме булмаганга, безнең мәмләкәт кешесе булырга мөмкин дип уйлап куйган идем. Шуннан соң без бу кеше белән таныштык, кытайча бик матур сөйләшкән кебек, төрки

[5] Нурлы һәм саф шәригать, ягъни исламият, аның кануннары *(тәрж.иск.)*.
[6] Кытайда яшәүче төрки халык – саларлар турында сүз бара. Габдерәшит бабабыз Ибраһимов ул атаманы кытайлардан ишеткәнгә, сала рәвешле язган булырга тиеш. Чөнки кытайлар аны, телләрендә р авазы булмагангадыр, мөгаен, sala zu (сала жу) рәвешендә әйткәннәр *(тәрж.иск.)*.

телдә дә бик матур итеп сөйләшә иде. Бу кеше миңа кардәшем булып тоелды. Төрки кешесе булганга, гомумән дә кардәшлек исбат ителгән иде.

Бу мөхтәрәм зат шактый мәгълүматлы кеше булып чыкты, ни хакында сүз башланса да, шактый киң фикер йөртә иде. Исеме Исмаил иде.

Исмаил әфәнде миңа кытай хөкемдарлары турында мондый мәгълүмат бирде:

«Моннан 500 ел элек кытай ханы безнең милләт кешесе булган. Без ул заманнарда кытайларның хокукларын бераз чикләгәнбез, шәхси һәм милли хокукларын бозган чакларыбыз да булган. Безнең хатын-кызларыбызның милли киемнәре аларныкылар өчен тыелган. Хәзер дә шулай. Аларның киемнәре безнеке белән чагыштырганда гадирәк, кыйммәте ягыннан түбәнрәк булырга тиеш булган. Аннары, хөкемдарлык мангулар кулына күчкәч, безнекеләр баш күтәргән, фетнә чыгарганнар. Нәтиҗәдә, кабат хокукларыбызны саклау шарты белән боерыклары астына керүне кабул иткәнбез. Хәтта төркилегебезне рәсми рәвештә саклау өчен килешү дә төзегәнбез. Катгый рәвештә безгә «мөселман түгел» мәгънәсендә «хита» димәскә тиеш булганнар. Хита/китай/кытай сүзләре – нигезе белән бер үк сүз, «кол» дигәнне аңлата.

Аннары хөкемдарлык манҗу династиясенә күчкәч, без килешүне яңартканбыз, шәригатебезгә кагылмау шарты белән, башка бар тәкъдимнәрен дә кабул иткәнбез.

Маньчжурия боерыгына кергәнлекнең билгесе булган чәч үреме дә безнең өчен мәҗбүри түгел. Тик менә соңгы 200 ел эчендә кайбер өстенлекләребез юкка чыгарылган. Әллә ничә тапкыр сугышканбыз. Мәчетләребезне яндырганнар, хокукларыбызны бозганнар, шулай булса да, дини хокукыбызны саклаганбыз. Бик күп булмаса да, голамәбез дә бар. Без Төркестан белән даими мөнәсәбәттә тордык. Алтышәһәргә, Кашгарга укырга яшьләребезне җибәрдек, аннан безгә голамә килде. Менә шул сәбәпле, Аллаһыга хәмд булсын, без динебезне саклый алдык.

Әйе, Маньчжурия хөкүмәте берара безнең дини хокукларыбызга һөҗүм итеп караган, хәтта мәчетләребезгә, гыйбадәтебезгә тыкшынырга теләгән. «Тәравих намазы өчен төнлә җыелмыйсыз, уразаны да без әйткәнчә тотасыз», – кебек сүзләр сөйләгәннәр. Безнекеләр шулвакыт баш күтәргән, кан коелган. Менә шул вакыйгадан соң, император үзе Пекинда Нуҗе мәхәллә мәчетенә тәравих намазына килгән. Намазның ахырына кадәр шунда калган. Намаз беткәч, мәчет эчендә үк үз кулы белән фәрман язган, безнең динебезгә һичбер вакыт тыкшыну булмаячагын белдергән.

Моннан тыш, мәчет биналарына тышкы яктан төрле хайван рәсемнәрен чокып ясарга тәкъдим иткәннәр. Бу тәкъдим Кытайның бөтен җирендә кабул ителсә дә, Салада кабул ителмәде. Безнең мәчетләребездә андый нәрсәләр юк.

Кытайлар безнең төркиләрдән шактый куркалар. Безнең халкыбыз, аз санлы булса да, бердәмлек, кыюлык һәм көч белән дан казанган бабаларыбызның тырышлыгы аркасында бүген дә тыныч яши алабыз.

Моннан берничә ел элек, безнең төркиләргә бөтен кытайлар җыелышып һөҗүм иткән иде. Аллаһка хәмд булсын, аякта калдык. Мәчетләребезне яндырганнар иде, кабат төзедек. Ләкин ни чара, җаһиллегебез аркасында, үзебезгә мохтарият (автономия) булдыра алмадык.

Бу соңгы чолганышлардан соң бик дәрәҗәле карарга ирешкән идек – ни теләсәк тә бирәселәр иде. Тик ни чара, җаһиллек, берни дә тели белмәдек, шулай үтеп китте. Хәтта дини эшләрдә әһәмиятле булган талак мәсьәләсен дә хәл итеп кире кайтара алмадык. Безнең Кытай мөселманнарында талак юк».

Шул арада мин, аның сүзен бүлеп: «Мәктәп һәм мәдрәсәләрне үзгәртеп кору турында уйлаучылар бармы?» – дип сорадым. Ул сүзен дәвам итте:

«Андый фикер һич юк һәм әле тиз генә була да алмас. Бу соңгы елларда безнең Кытай иленә зур бәла килде – миссионерлар күбәйде. Инде бөтен курыкканыбыз – шулар. Кытай хөкүмәте миссионерларга каршы бер генә сүз дә әйттерми. Киләчәктә ни булачак – мәгълүм түгел.

Әйе, безнең Сала һәм Алтышәһәр мөселманнары үзләрен саклармар. Тик менә бу үзәк мөселманнары бик җаһил, бигрәк тә Пекин һәм аның әйләнә-тирәсе үтә чыккан кире. Мөфти Абдуррахман да милләткә сүз аңлата алмый. Бу милләттә әсирлек ахыргача холык-табигатькә әйләнгән, мәҗүси гадәтләр шәригать урынын алган. Хатын-кызларыбыз белем-тәрбиядән бөтенләй мәхрүм. Аякларын кечерәйтү исә фарыз дәрәҗәсенә җиткән. Инде хөкүмәт тарафыннан бик каты кисәтүләр белдерелде: хатын-кызларга аякларын кечерәйтү катгый тыела. Тик милләт барыбер кабул итми, чөнки аяк кечерәйтү дә холык-табигатьләренә әйләнгән. Боларны уйлап бик кайгырам.

Хәзер бердәнбер өметебез шул: Төркия хөкүмәте тарафыннан голамә җибәрелер, безнең Кытай мөселманнары арасында ислам хакыйкатьләрен аңлатып вәгазьләр сөйләрләр. Бу бик яхшы булыр иде. Узган ел ике мөгаллим килгән иде. Бик файдалы хезмәтләре булды. Ләкин безнең кытайларның ризасызлыклары билгеле, шуңа биредә яшәп кала алмадылар. Али Рыза әфәндедән бик зур хезмәтләр өмет иткән идек, тик ни чара, булмады».

Пекинда шул рәвешле сала/саларйа төрки кешесе белән күрешеп, шактый мәгълүмат алдым.

Кытай голамәсе куллана торган гарәпчә сүзләр

Әйтелешләре:

Ансаләм аләйкун! [Әс-сәламу аләйкум! – Сезгә сәлам булсын!]

Омру? [Кәм омрукә вә кәм синнукә? – Син ничә яшьтә?]

Халәлу фиһ? [Һәл әнтә мутәзәүүиҗ? – Син өйләнгәнме?]

Вәләду? [Һәл ләкә әүлад? – Балаларың бармы?]

Мулко-эй мулко? [Мин-әййи мәмләкәтиһи? – Нинди мәмләкәттән син?]

Манкә? [Әнтә мин әһли Мәккә? – Син Мәккәдәнме?]

Алим фиһ? [Әнтә минәл-уләма? – Син голамә кешесеме?]

Бөтен Кытай голамәсе белә һәм куллана торган гарәпчә сүзләр менә шулкадәр. Моннан артыгын белүче юк дәрәҗәсендә.

Кытай голамәсе һичбер вакыт җаһиллеген танымый, үзләрен галим саныйлар. Үз белгәннәреннән һич баш тартмыйлар. Үзләре күнеккән, ләкин тиешле булмаган берәр нәрсә турында, фикһ китапларыннан күрсәтеп: *«һәзә лә йәҗуз* [Бу тиешле түгел]», – дисәң, китапка карап укый да: *«Нәгам нәгам, ләкин чини адето* [Әйе-әйе, тик кытай гадәте бу]», – ди, һич кабул итми.

Хәтта намаздан соң Аятел Көрси укыганда да: *«Мән зәлләзи йәшфәу индеһа»,* – дип укый. *«Юк, алай түгел, индеһу тиеш»,* – дип төзәтсәң, тагын шулай ди: *«Чини мүслүмани адето»*, ягъни: *«Кытай мөселманнарының гадәте бу»,* – ди дә башка берни әйтми.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

Матбугат ифтары

13 апрельдә «Безнең мирас» журналы редакциясе «Татмедиа» бинасының ашханәсендә инде күркәм традициягә әйләнгән Матбугат ифтары уздырды. Җәлил хәзрәт Фазлыев, Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Нияз хәзрәт Сабиров кебек дин әһелләре, «Татмедиа» генераль директоры Шамил Садыйков, ТР Дәүләт Советы депутаты Камил Нугаев, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров, академик Индус Таһиров, шагыйрьләр – Равил Фәйзуллин, Марсель Галиев, Газинур Морат, Ләис Зөлкарнәй, галимнәр – Тәлгат Галиуллин, Фәйзелхак Ислаев, баш мөхәррирләр, матбугат ветераннары, күпсанлы журналистлар катнашында узган әлеге ифтарда мәшһүребез Г.Тукайның һәм соңгы елларда вафат булган алтмышлап күренекле шәхесебезнең рухына дога кылынды.

Ислам. Дини сүзлек

Ифтар мәҗлесе

Ифтар мәҗлесе (гар. – «авыз ачтыру» мәҗлесе) – рамазан аенда ураза тотучы мөселманнарны, кояш баегач, кичен ашка чакырып сыйлау йоласы.

Элегрәк, шәригать буенча, ифтар мәҗлесенә өендә ашарына-эчәренә ризыгы булмаган мөселманнар гына чакырылганнар. Хәзер исә рамазан аенда ураза тотканнан соң «авыз ачтыру»га хуҗа үзе якын иткән теләсә кемне чакыра һәм кояш баюга, алар өстәл артында бергәләп авыз ачалар. Гыйлем ияләренең Корьән укуларын, вәгазь-нәсыйхәтләрен тыңлыйлар.

«Ислам. Белешмә-сүзлек» китабыннан (1993, Татарстан китап нәшрияты) алынды.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) үзе яшәгән заманда сәхабәләргә рамазан аенда ураза тотучы кешеләрне мәҗлескә җыеп авыз ачтырырга куша. «Авыз ачтырган кеше, – ди ул, – муенын җәһәннәм газабыннан коткарыр, Аллаһы Тәгалә аның белеп һәм белми кылган гөнаһларын ярлыкар. Ураза тоткан берәр кешегә авыз ачарга бер хөрмә яисә баллы су биргән, аны ризыкландырган кешегә Аллаһы Тәгалә ураза тоту савапларын бирер, сусаганга су эчерүчене Гарасат мәйданына чакырмас». Аны тыңлап торган сәхабәләр: «Авыз ачтырырга хәлебездән килми бит», – диләр. Пәйгамбәребез (с.г.в.) аларга сөт ризыклары белән авыз ачтырырга мөмкин икәнлеген әйтә.

Авыз ачтырганда бер кешеме, биш кешеме, тугыз кешеме, туксан кешеме булырга тиеш – андый чикләү юк. Никадәр күп кешене авыз ачтырса, әҗер-савабы да шулкадәр күбрәк булачак. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Кем чакырган җиргә сәбәпсез бармаса, ул миңа каршы килгән була», – ди. Чакырылган җиргә бару-бармау ул – мөселманлык хакы. Сәбәпсез бармаса, гөнаһлы була.

Ураза тотмыйча, намаз укымыйча, хәмер белән кайнашкан кешене ифтар мәҗлесенә чакырырга ярыймы?

Ифтар мәҗлесенең төп максаты – авыз ачтыру. Бу очракта әлеге кеше, ифтар мәҗлесендә катнашса да, аңа авыз ачу савабы ирешми. Әмма аны, гыйбрәтләнсен, вәгазьләнсен өчен, әлеге мәҗлескә чакырырга була.

Габделхак хәзрәт Саматовның «Шәригать: вәгазь, хөкем, фәтва, җавап-савап, киңәшләр» китабыннан (2005) алынды. ■

Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) хәдисләре*

Әхмәдвәли Рәхими

31

Әнәс разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам бәдрәфкә кергәндә әйткән: «Аллааһуммә инни әгуузубикә минәл хубси вәл хабә'ис» («Йә Аллаһ! Сыенамын Сиңа ир шайтаннар зарарыннан һәм хатын шайтаннар явызлыгыннан»).

Укы һәм исеңдә калдыр!

32

Әбү Әюб, Җәбир һәм Әнәс разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам: «Әй әнсар кавеме! Аллаһы Тәгалә сезне, тәһарәтегез хакында, тәһарәткә игътибарлы ирләр дип мактады. Сезнең тәһарәтегез ничек?» – дип сорады. Әнсарлар: «Намаз өчен тәһарәт алабыз, җөнебтән (җенси мөнәсәбәт аркасында госелсез булу сәбәпле) госел коенабыз, су белән истинҗа (зур һәм кече йомыштан соң гаурәтне нәҗестән су белән пакьләү) кылабыз», – дигәч, Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам: «Макталган тәһарәт шул, аннан аерылмагыз», – диде.

Укы һәм исеңдә калдыр!

33

Әбү Һөрәйра разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Госел бозылгач, һәр төк төбендә җөнеб бар. Һәр төкне юыгыз. Шуңа күрә чәчләрегезне һәм тәнегезне тулысынча пакьләгез (җентекләп юыгыз)».

Укы һәм исеңдә калдыр!

34

Гайшә разыйаллаһу ганһә риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Ике сөннәт җире бер-береннән үтсә (әгәр ир кеше хатын-кыз белән җенси якынлык кылса), госел важиб (мәҗбүри) булыр.

Укы һәм исеңдә калдыр!

35

Әбү Һөрәйра разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Һичберегез акмый туктап торган суга хаҗәтен үтәмәсен. Соңра үзе шул суда госел коеныр».

Дәвамы. Башы журналның 12 нче (2021) санында.

*Хәдисләр Шәех әл-Камил Вәли әд-Динмөхәммәд бине Габделхатыйб әт-Тәбризинең «Мишкәтүль мәсабих» китабы буенча әзерләнгән һәм 1913 елда 3 китапта басылып чыккан.

*Текстны басмага **Айсылу Вәлиева** әзерләде.* ■

Безнең мирас №5 май 2022

САБЫЙЛАР ӨЧЕН ДИНИ МИРАС

Дин дәресләре

Сөнгатулла Бикбулат

Унберенче дәрес

Ибраһим пәйгамбәрнең (г.с.) Исмәгыйль (г.с.) белән Һәҗәрне Гарәбстанга илтүе. Зәмзәм чишмәсе. Ибраһим пәйгамбәр (г.с.) белән Исмәгыйль пәйгамбәрнең (г.с.) икәүләп Кәгъбәтуллаһны бина кылулары. Кәгъбәне бина кылганда аларның догалары. Аллаһы Тәгаләдән Исмәгыйль (г.с.) нәселеннән бер пәйгамбәр җибәрүен сораулары. Ул доганың кабул булуы

Мөгаллим: Ибраһим пәйгамбәрнең (г.с.) ничә улы булган әле?

Шәкерт: Ике улы булган.

Мөгаллим: Алар яхшы кешеләр булганнармы, әллә яман кешеләрме?

Шәкерт: Бик яхшы, бик изге булганнар. Алар икесе дә пәйгамбәр (г.с.) булган.

Мөгаллим: Исмәгыйль пәйгамбәрнең (г.с.) нәселеннән кем туган?

Шәкерт: Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) туган.

Мөгаллим: Дөрес әйттең. Аңардан шул пәйгамбәрләрнең ахыргысы һәм иң олугы булган Мөхәммәд (с.г.в.) туган.

Мөгаллим: Ә Исхак пәйгамбәрдән (г.с.) кемнәр туган?

Шәкерт: Аның нәселеннән бик күп пәйгамбәрләр килгән.

Мөгаллим: Шулай, дөрес. Мин үткән дәрестә сезгә Ибраһим пәйгамбәр (г.с.) турында сөйләгән идем. Инде бу дәрестә аның белән Исмәгыйль пәйгамбәр (г.с.) хакында сөйлим. Ибраһим пәйгамбәр (г.с.) ул Канган (Фәләстыйн) дигән җирдә торган. Аллаһы Тәгалә аңа бер улын Канган җиреннән ерак бер җиргә урнаштырып, шундагы халыкларны тугры юлга күндерергә, аларга дин вә шәригать хөкемнәрен өйрәтергә кушкан. Ул җир Гарәбстан җире булган. Ибраһим пәйгамбәр (г.с.) карт хатыны Сараны Канганда калдырып, Һәҗәр белән Исмәгыйльне (г.с.) әлеге җиргә алып киткән. Ул вакытта әле Исмәгыйль (г.с.) имчәк баласы гына булган. Ибраһим пәйгамбәр (г.с.) боларны хәзерге Мәккә шәһәре урынында калдырып киткән. Ә ул вакыт анда шәһәр дә, авыл да – бернәрсә дә булмаган. Ул урын комлыктан, чүлдән гыйбарәт булган. Анда һичбер су әсәре табылмаган. Хәзрәти Һәҗәр суга бик аптыраган: анда йөгергән, монда йөгергән, ләкин су таба алмаган. Шулвакыт Аллаһы Тәгаләнең әмере белән бер фәрештә, шунда килеп, җиргә суккан да, әлеге җирдән бер чишмә чыккан. Бу чишмә Зәмзәм дип аталган. Сезнең Зәмзәмне ишеткәнегез бардыр бит?

Шәкерт: Бар.

Мөгаллим: Зәмзәм шул вакыттан калган чишмә инде. Исмәгыйль (г.с.) әнә шул җирдә үскән. Ул әлеге тирәдәге халыклар белән аралашкан, алардан кыз алган.

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2021) санында.

Андагы халыклар гарәп милләтеннән булганнар. Исмәгыйль пәйгамбәр (г.с.) дә алар белән бергә яшәп, гарәпләшеп киткән. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) дә Исмәгыйль пәйгамбәрнең (г.с.) нәселеннән, ул да гарәп булган. Хәзерге гарәпләр дә Исмәгыйль пәйгамбәрдән (г.с.) таралганнар.

Бишбалта бистәсенең 2 нче җәмигъ мәчете. Казан сәүдәгәре Сөләйман Аитов акчасына төзелгән. 1898 ел

Мөгаллим: Байтак еллардан соң, бервакыт Ибраһим пәйгамбәр (г.с.), улының хәлен белү өчен, Мәккәгә килгән. Шулвакыт Аллаһы Тәгалә аңа шунда бер гыйбадәтханә салырга кушкан. Шунлыктан алар, аталы-уллы икәүләп, бер гыйбадәтханә төзегәннәр. Әлеге гыйбадәтханә хәзер дә бар. Ул Мәккә шәһәрендә. Аңа Кәгъбәтуллаһ диләр. Менә иң башлап шул мәчетне Ибраһим пәйгамбәр (г.с.) белән Исмәгыйль пәйгамбәр (г.с.) бина кылганнар. Ибраһим пәйгамбәр (г.с.) бинаны үз кулы белән салган, Исмәгыйль (г.с.) аңа булышкан, кирпечләр биреп торган. Менә хәзерге көндә безнең кыйблабыз, ягъни намаз укыганда юнәлә торган урыныбыз булган Кәгъбәтуллаһ моннан ничә мең еллар элек Ибраһим белән Исмәгыйль пәйгамбәрләр (г.с.) тарафыннан бина кылынган. Ул соңыннан төзәтелгән генә. Аның урыны – шул урын, нигезе дә – шул нигез. Кәгъбәтуллаһны бина кылган чакта Ибраһим пәйгамбәр (г.с.) белән Исмәгыйль пәйгамбәр (г.с.) ошбу рәвешчә дога кылганнар: «Ий безнең Раббыбыз, безнең ошбу эшебезне кабул ит! Ий Раббыбыз, безне Үзеңә итагать итүдән, баш июдән аерма. Балаларыбызны да Үзеңә итагать итүче өммәт кыл. Кимчелекләребез булса, ярлыка, гафу ит. Ий Раббыбыз, безнең балаларыбыздан бер пәйгамбәр (г.с.) җибәр. Ул аларны начар эшләрдән, начар гадәтләрдән арындырсын. Аларга дин вә шәригать өйрәтсен. Синең кодрәтеңнең, хикмәтеңнең иге-чиге юк!» Аллаһы Тәгалә аларның догаларын кабул иткән. Хәзрәти Исмәгыйльнең (г.с.) нәселеннән бөтен дөнья халкына сөенеч булган бер пәйгамбәр (с.г.в.) җибәргән ки, ул Ахырзаман пәйгамбәре – Мөхәммәд (с.г.в.). Бина тәмам булгач, хәзрәти Исмәгыйль (г.с.) вә аңа ияргән кешеләр анда кереп гыйбадәт кылганнар, аны зиярәт кылыр өчен төрле җирдән килә торган булганнар. Шул вакыттан бирле ул гыйбадәт урыны булып киткән. Хәзерге көндә дә дөньяның бөтен тарафыннан ел саен мөселманнар бер вакыт анда барып гыйбадәт кылалар. Сезнең кайсыларыгызның хаҗга барган кешеләрне күргәне бар?

Шәкерт: Безнең абзый хаҗга барган. Аңа хаҗи диләр.

Мөгаллим: Әнә ул шул Кәгъбәтуллаһка барып гыйбадәт кылып кайткан инде. Бу турыда без киләчәктә тагы да сөйләрбез әле.

*Текстны басмага **Мәдинә Әбделганиева** әзерләде.* ■

Безнең мирас №5 май 2022

КАРА ТӘКЪДИР

(Ачы язмышлы шәхесләр)

ОЗЫНБАШЛЫ ӘМӘТ (1893-1958)

Кырымтатар язучысы, мөгаллим, табиб-невропатолог Әмәт Озынбашлы 1893 елның 10 февралендә Бакчасарайда (Симферопольдә) язучы сәет Абдулла Озынбашлы гаиләсендә туган. Күпмедер вакыт Исмәгыйль Гаспралы типографиясендә рәссам-бизәүче булып эшләгән.

Әмәт Озынбашлы 1928 елның апрелендә НКВД тарафыннан кулга алына һәм шул ук елның декабрендә атарга хөкем ителә. Соңыннан хөкем карары үзгәртелеп, 10 елга колониягә җибәрелә. 1934 елда азат ителә. 1947 елның сентябрендә аңа кабат хөкем карары чыгарылып, ул 25 елга төрмәгә ябыла, әмма 1953 елда иреккә чыгарыла. Әмәт Озынбашлы 1958 елның 4 декабрендә Ленинабад каласында вафат була. Соңыннан аның җәсәден Кырымга алып кайталар һәм, үзенең васыяте нигезендә, Исмәгыйль Гаспралы кабере янына җирлиләр.

ТИМЕРГАЛИН АДЛЕР (1931-2013)

Татар язучысы Адлер Камил улы Тимергалин 1931 елның гыйнварында Татарстанның Сарман районындагы Иске Минзәләбаш авылында туган.

1950 елның 2 гыйнварында, университетның икенче курсында укыган чагында, Сталин сәясәтенә ачыктан-ачык каршы чыкканы – «Сталинга үлем!» дигән листовкалар язып таратканы өчен кулга алынган. Әтисенең тырышлыгы нәтиҗәсендә, төрмәгә ябылмыйча, психик авырулар хастаханәсенә салынган. Бер елдан артык шунда тотылып чыккач, аңа укуын Казанда дәвам итәргә рөхсәт итмәгәннәр, шул сәбәпле Ташкентка китәргә мәҗбүр булган.

Адлер Тимергалин 2013 елның 16 гыйнварында Казанда вафат булды.

Дәвамы. Башы журналның 10 нчы (2020) санында.

Безнен мирас №5 май 2022

ТИНЧУРИН КӘРИМ (1887-1938)

Татар драматургы, режиссер һәм артист Кәрим Гали улы Тинчурин 1887 елның 15 сентябрендә хәзерге Пенза өлкәсенең Демьян Бедный районындагы Таракан (Белоозерка) авылында туган.

1937 елның 17 сентябрендә НКВД кешеләре К.Тинчуринны кулга ала һәм Казандагы Пләтән төрмәсенә яба. Елда ике ай барган тикшерүдән соң, Тинчуринга җиде пункттан торган гаепләү акты игълан ителә һәм ул 1938 елның 15 ноябрендә атып үтерелә.

ТОЛЫМБАЙ ГОМӘР (1900-1938)

Татар язучысы, тәнкыйтьче Гомәр Толымбай (Габделхак Җәләлетдин улы Шаһимөхәммәтов) 1900 елның 14 апрелендә Татарстанның Буа районындагы Толымбай (Адав-Толымбай) авылында туган.

Ул 1937 елның 8 июнендә кулга алына һәм 1938 елның 8 маенда Пләтән төрмәсендә атып үтерелә.



ТУФАН ХӘСӘН (1900-1981)

Татар шагыйре Хәсән Фәхрулла улы Туфан 1900 елның 9 декабрендә (иске стиль белән 27 ноябрьдә) Казан губернасының Аксубай өязе (хәзерге Аксубай районы) Иске Кармәт авылында туган.

Нахак яла ягылып, ул 1940 елның 18 ноябрендә кулга алына һәм 1956 елның җәенә кадәр Себердә тоткынлыкта була.

Хәсән Туфан 1981 елның 10 июнендә Казанда вафат булды.

УСМАНОВ ШАМИЛ (1898-1937)

Татар драматургы, язучы Шамил Хәйрулла улы Усманов (Госманов) 1898 елның 26 декабрендә Саратов губернасының Кузнецк өязендәге (хәзерге Пенза өлкәсенең Кузнецк районы) Татар Пәндәлгәсе авылында туган.

Ул 1937 елның 7 апрелендә кулга алына һәм, солтангалиевчелектә гаепләнеп, берничә ай Пләтән төрмәсендә тотыла. 1937 елның 3 декабрендә сорау алган вакытта һәлак була. 1955 елның 30 декабрендә реабилитацияләнә.

*Текстны басмага **Рабит Батулла** әзерләде.* ■

БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫНА 30 ЕЛ

Әдипләр һәм сәнгать әһелләре карары

Ләбиб Лерон

Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең Бөтендөнья татар конгрессының беренче корылтаенда чыгыш ясаган чагы. Июнь, 1992 ел. ***М.Козловский фотосы***

1992 елның 19-21 июнь көннәрендә Казанда Бөтендөнья татар конгрессының (башкарма комитеты рәисе – Индус Таһиров) беренче корылтае узды. 20 июньдә исә корылтай үз эшен секцияләргә бүленеп дәвам итте. Татарстан Язучылар берлеге йортында Бөтендөнья татар конгрессына нисбәтле секция утырышы булды. Мәдәният, әдәбият һәм сәнгать әһелләре катнашында үткән әлеге утырышта, көн тәртибенә куелган күптөрле мәсьәләләр буенча фикер алышканнан соң, карар чыгарылды. Кыскасы, «Татар мәдәнияте һәм әдәбияты үсеше проблемалары» секциясенең карары моннан гыйбарәт:

1. Милләттәшләребезнең күпчелеге Татарстан Республикасыннан читтә яшәвен искә алып, БДБнең татар халкы күпләп гомер иткән республикалары, өлкәләре, шулай ук чит ил хөкүмәтләре белән милли мәдәният үсеше турында ике яклы килешүләр төзергә;
2. Россия Федерациясендә һәм чит илләрдә татарлар күпләп яши торган төбәкләрдәге мәдәният үзәкләренә нәтиҗәле ярдәм күрсәтү өчен милли оешмалар турында белешмә бастырып чыгарырга;
3. Татар халкының тарихи-мәдәни һәйкәлләре тупланмасын булдырырга;
4. Татарлар күпләп яшәгән төбәкләр һәм дәүләтләр белән мәдәни багланышларны киңәйтү өчен түбәндәгеләрне эшләргә:

- татар халкы тарихына һәм мәдәниятенә кагылышлы экспонатларны тулырак күзаллау өчен, Татарстандагы һәм чит илләрдәге музей тупланмалары турында белешмә бастырып чыгарырга;
- яшьләрнең бөтендөнья фольклор фестивален, «Казан ярминкәсе» дип аталган бөтендөнья халык һөнәрчеләре күргәзмәсен ел саен үткәрүне гамәлгә ашырырга;
- Россия Федерациясенең Төмән, Сембер, Әстерхан өлкәләрендә һәм БДБнең башка төбәкләрендә үзешчән һәм профессиональ театрлар, фольклор коллективлары оештыру эшендә ярдәм итәргә;

ТР Президенты М.Шәймиев, ТР Югары Советы рәисе Ф.Мөхәммәтшин, ТР вице-президенты (1991-1995) В.Лихачев һәм Бөтендөнья татар конгрессының беренче рәисе (1992-2002), академик И.Таһиров. Июнь, 1992 ел. *М.Козловский фотосы*

1990-1995 нче елларда Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары, Татарстанның Мамадыш районындагы Түбән Ушмы авылы тумасы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (2009), Татарстанның халык шагыйре (2014) Зиннур Мөҗип улы Мансуров (1949)

- татар халкының этник группалары (керәшен һ.б.) профессиональ фольклор ансамбльләре оештыруны көн тәртибенә куярга;
- «Казан» милли-мәдәни үзәге бинасында (элекке Ленин мемориалы) татар мәдәнияте музееен оештыруны хәл итәргә;
- татар рәссамнары оешмасына бина бирергә;

5. Бөтендөнья уку-укыту тәҗрибәсен файдаланып, Көнчыгыш һәм Көнбатыш илләрендә белем эстәү өчен, талантлы яшьләрне сайлап алу системасын булдырырга, сәнгатьнең бөтен төрләре буенча дәреслекләр һәм аңлатма-кулланмалар бастырып чыгару эшен җайга салырга, бу максатта халкыбызның барлык интеллектуаль көчләрен файдаланырга;

6. Халыкара мәдәни хәрәкәтендә лаеклы урын алу өчен, Бөтендөнья татар мәдәнияте фондын оештырырга;

7. Милли-мәдәни хәрәкәтне координацияләү максатында Бөтендөнья татарлары үзәген (клубын) оештырырга. Шундый ук максатларны күздә тотып, Татарстан хөкүмәте каршында махсус дәүләт структурасы булдырырга, татарлар күпләп яши торган җөмһүриятләр хөкүмәтләренә дә шундый структуралар төзүне сорап мөрәҗәгать итәргә;

8. Татарлар күпләп яши торган төбәкләр һәм чит илләрдәге милли-мәдәни бәйләнышларны җайга салу өчен, мәгълүмат үзәге булдырырга;

9. Милли кадрларны күпләп әзерләү максатыннан чыгып, Казан дәүләт консерваториясе, Мәдәният институты, сәнгать училищелары һәм мәктәпләренең укыту эшен үзгәртеп корырга, аерым алганда, алдагы уку елында Казанда, Чаллыда, Әлмәттә һ.б. шәһәрләрдә татарча укытыла торган сәнгать мәктәпләрен ачуны тәэмин итәргә;

10. Мәдәни көчләрне бергә туплау һәм культура эшен координацияләү йөзеннән, татар мәдәнияте эшлеклеләренең ассоциациясен төзүне һәм аның концепциясенең төп юнәлешләрен хупларга.

Сүзебезне йомгаклап, әлеге карар проектын, утырышта яңгыраган күпсанлы фикерләр нигезендә, Татарстан Язучылар берлегенең ул чактагы рәисе урынбасары Зиннур Мансуровның башкарып чыгуын әйтүне мәслихәт санадык. ■

Истә, һаман да истә!

Язучы Азат Ганиевның туурына 80 ел

Язучы Азат Ганиев (Азат Вәли улы Мөхәммәтганиев) 1942 елның 1 маенда Татарстан АССРның Әлмәт районындагы Кама-Исмәгыйль авылында укытучы гаиләсендә туган.

Азат Ганиев укучыларга «Тагын күченәбез» исемле хикәяләр җыентыгы (1969) һәм «Сүзсез җыр» (1971) дигән повесте белән таныш.

1977 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы булган А.Ганиев 2012 елның 6 октябрендә вафат булды һәм туган авылы зиратында җирләнде.

Гобойчы Мөбарәк Батталовның туурына 110 ел

Татар дөньясында беренче гобойчы, педагог, ТАССРның атказанган артисты (1957) Мөбарәк Вазыйх улы Батталов 1912 елның 15 маенда хәзерге Алексеевск районына кергән Урта Тигәнәле авылында туган.

Татарның күренекле уллары Салих (1905-1995) һәм Габдулла (1916-1944) Батталларның бертуганы М.Батталов, Казан татар сәнгате техникумына укырга кергән чакта, профессор А.Литвинов: «Син гармунда түгел, гобойда уйнарга өйрәнәчәксең», – дип, аның киләчәк язмышын билгели.

1941-1942 һәм 1946-1971 нче елларда ул М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры оркестры артисты һәм солисты була.

М.Батталов 2006 елның 8 декабрендә вафат булды.

Шагыйрә Флера Тарханованың туурына 75 ел

Шагыйрә, тәрҗемәче, филология фәннәре кандидаты, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТРның Журналистлар (1995) һәм Язучылар (1998) берлекләре әгъзасы Флера Габдерахман кызы Тарханова 1947 елның 25 маенда Чистай районының Яушырмә авылында туган.

Басылып чыккан китаплары: «Синең кайнар сулышлар» (1998), «Уңган кыз» (1998), «Йөрәгемә яшерелгән серләр» (2001), «Серле дөнья» (2002), «Өч кайрый» (2003), «Яшьлек эзем калган сукмаклар» (2005), «Алтын уклар» (200?), «Язмышлар язылганда» (2007).

Ф.Тарханова 2018 елның 31 июлендә Казанда вафат булды.

Рәссам Чыңгыз Әхмәровның туууына 110 ел

Рәссам, график, монументаль сәнгать остасы, педагог, сәнгать фәннәре кандидаты, профессор, СССР дәүләт премиясе (1948) һәм Үзбәкстан ССРның Хәмзә исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (1968), Үзбәкстан ССРның (1964) һәм Татарстанның халык рәссамы (1992) Чыңгыз Габдерахман улы Әхмәров 1912 елның 12 маенда Оренбург өлкәсенең Троицк каласында туган.

Чыңгыз Әхмәров – Үзбәкстанда монументаль сәнгатькә нигез салучы. 1955-1956 нчы елларда М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры фойесын һәм диварларын («Бию», «Музыка» һәм «Сәнгать» композицияләре), 1957 елда Казан елга порты фасадын мозаикалар белән бизи, «Татар хатыны» (1968), «Йосыф һәм Зөләйха» (1975) картиналарын яза, «Мәрҗани Үзәк Азияд»ә, «Сөембикә Үтәмешгәрәй белән», «Габдулла Тукай», «Тормыш», «Татар кызы», «Татар биюе» дигән хезмәтләрен иҗат итә.

Ч.Әхмәров 1995 елның 13 мартында Ташкент шәһәрендә вафат булды.

Актер Нәҗип Гайнуллинның туууына 110 ел

Актер, ТАССРның халык (1950), РСФСРның атказанган артисты (1957) Нәҗип Сәмигулла улы Гайнуллин 1912 елның 15 маенда хәзерге Оренбург өлкәсенә караган Троицк шәһәрендә туган.

1936 елда ул Татар сәнгать техникумының театр бүлеген тәмамлый. Нәҗип Гайнуллин 1957-1963 нче елларда – Татар академия театрында директор һәм сәнгать җитәкчесе.

Уйнаган рольләре: Камал («Тукай», Ә.Фәйзи), Насыйри (шул исемдәге пьеса, М.Гали һәм Х.Уразиков), Уразмәтов («Хәерле юл», Г.Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар» романы буенча), Шмага («Гаепсездән гаепләләр», А.Н.Островский) һ.б.

Нәҗип Гайнуллин 1952-1962 нче елларда Бөтенсоюз театр җәмгыятенең Татарстан бүлеген җитәкли.

Н.Гайнуллин 1969 елның 14 июлендә Казанда вафат булды.

Мәгърифәтче Ибраһим Терегуловның туууына 170 ел

Мәгърифәтче, педагог, дәүләт киңәшчесе, Казанда Шәрык клубын оештыручы һәм аның беренче рәисе (1906), Сәмәрканд педагогия институты профессоры (1920-1921) Ибраһим Вәлиулла улы Терегулов 1852 елның 29 маенда Уфада туган. 1878 елда ул Казан ветеринария институтын тәмамлый.

Ибраһим Терегуловның татарча фәнни терминнар булдыруда зур хезмәте бар. «Йолдыз» газетасын чыгаруда катнаша. Мәскәү һәм Оренбург якларында татар мәктәпләре булдыруда аның өлеше зур. 1906 елның 5 маенда куелган татарча беренче спектакльгә дә рөхсәтне ул ала.

И.Терегулов 1921 елның 22 ноябрендә Сәмәркандта вафат булды.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Асыл җырчыбыз

Алсу Хәкимова



Татар опера сәнгате өлкәсенә зур өлеш керткән, татар, рус һәм чит ил композиторларының классик әсәрләрен, лирик җырларын, халык көйләрен үзенә генә хас моң, осталык белән озак еллар тамашачыга җиткергән күренекле җырчы, Татарстанның халык артисткасы Әлфия Галимованың туума быел 30 майда 100 ел тула. Эчке дөньясыннан, тышкы кыяфәтеннән ниндидер затлылык, зыялылык бөркелеп торган, бөтен тормышын сәнгатькә багышлаган Әлфия Әхәт кызы Галимова гомеренең соңгы елларында да әле һаман иҗат дәрте белән янып яшәде.

Әлфия апа белән аралашырга, аның өендә дә булырга туры килде миңа. Ул шунда үзенең бик матур портретын бүләк иткән иде. Әле студент елларында ук билгесез автор тарафыннан ясалган бу рәсеме хәзер Филармония музеенда урын алган. Әлфия апа шулай ук үзенең концерт костюмын, бик күп җыр-нота җыентыкларын да безгә бүләк итеп тапшырды ул чакта. *«Үземә, иҗатыма һәрчак таләпчән булдым һәм бу мине гомерем буе озата килде»,* – дигән иде Әлфия апа бер очрашуда. Аның һәрчак камиллеккә, белемгә омтылуы, куйган максатларына ирешә баруы затлы, асыл гаиләдән чыгуын-

Җ.Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясеннән бер күренеш. Сулдан уңга: Фәхри Насретдинов (Галимҗан), Мәрьям Рахманкулова (Җиһан), Әлфия Галимова (Сәрвәр). 1954 ел

нан килгәндер. Ул – мәгърифәтче Садыйк мулла нәселеннән. Заманында аның бабасы Садыйк, Кама Тамагының Олы Карамалы авылында мәктәп ачып, балалар укыткан. Шушы мәктәптә әтисе Әхәт тә белем ала, укытучы һөнәрен үзләштерә, әнисе Шәмсеҗиһан татар балаларына рус теле укыта. Аларның гаиләсенә төрле төбәкләргә күченеп яшәргә туры килә. Моның сәбәбе – әтиләренең партия эшлеклесе булуында. Чистайда яшәгәндә алар Укытучыларның мәгариф клубында эшләүче җыр түгәрәгенә Әлфияне дә алып баралар. Ул шунда беренче тапкыр музыка аһәңнәрен ишетә, фортепиано буенча дәресләр ала. Өйгә кайткач, балалар үзара җырлыйлар, шигырьләр сөйлиләр. Аннары кичләрен гаиләләре белән радио аша татар концертларын тыңлыйлар, Әлфия хәйран гына җырларны хәтерендә калдыра. Ләкин аңа гел иркә генә булып үсү бәхете тәтеми. Буа шәһәренә күченеп банк идарәчесе булып эшләгән вакытта әтисе репрессиягә эләгеп, кулга алына һәм бер гаепсезгә атып үтерелә. Әнисе дә, шик астына алынып, Теләче районына сөрелә, кечкенә кызы белән ул шунда китә. Әлфия энесе белән Буада туганнарында яшәп кала, чөнки укуын дәвам итәргә кирәк була. Сугыш башлангач, энесе фронтка китә, Әлфия исә, мәктәпне тәмамлап, Кайбыч урман хуҗалыгына эшкә урнаша. Бераздан әнисе Казанга тимер юл төзелешенә эшкә килә, Әлфияне дә үзе янына ала.

1944 елда Казанга килгәч, театр яныннан узып барганда Әлфия апа игъланнар тактасына игътибар итә. Анда: «Мәскәү консерваториясе каршындагы опера студиясендә уку өчен җырчылар сайлау бара», – дип язылган була. Ул елларда Казанга югары белемле яшь кадрлар кирәклеге көн тәртибенә кертелә. Әлфия, кыяр-кыймас кына, үзен сынап карарга була. Ул Нәҗип Җиһанов, Мансур Мозаффаров, Асия Измайлова кебек күренекле шәхесләрдән торган комиссия алдында Мансур Мозаффаровның Муса Җәлил сүзләренә язылган «Җиләк җыйганда» дигән җырын башкара, икенче һәм

Әлфия Галимова 90 яшьлек юбилей елында «Җыр осталары» концертында чыгыш ясый. Татар дәүләт филармониясе. «Филармониада» халыкара музыка сәнгате фестивале. 2012 ел

Әлфия Галимова (уртада) бер төркем сәнгать осталары белән Тимер юлчылар клубындагы концерттан соң. Мәскәү. 1963 ел

өченче турларга узып, югары бәяләнә. Мәскәүдәге опера студиясенә укырга керергә теләүче 400 кеше арасыннан егерме бише генә сайлап алына. Әлеге бәхетлеләр арасында Әлфия Галимова да була.

Ниһаять, алар Мәскәүдә. 1944 ел. Укулар декабрь аенда башлана. Әлфия апа башта тәҗрибәле педагог Дмитрий Львович Аспелунд классында укый. Ул бик олы яшьтә була инде, икенче уку елында вафат була. Шуннан соң Әлфия Галимова укуын Дора Борисовна Белявскаяда дәвам итә. *«Үземне аңа гомерем буена бурычлы саныйм. Әлеге искиткеч нечкә күңелле оста педагог минем киләчәк язмышымны билгеләде, тавыш мөмкинлегемне ачты, тавышымны куя алды. Аның классында уку миңа соңыннан опера солисткасы булу мөмкинлеге бирде. Илебездә танылган беренче югары уку йортында уку, Мәскәү культурасын алу, зур шәхесләр белән аралашу миңа әйтеп бетергесез бәхетле мизгелләр бүләк итте. Тормыштагы авыр тойгылар, михнәтле балачак, ачлык вакытлары әллә кая икенче планга чыкты, яшәү рәвешемне бары тик җыр, сәнгать биләде...»* – дип искә алган иде Әлфия ханым әлеге еллар турында. Консерваториядә ул Рөстәм Яхин, Азат Аббасов, Венера Шәрипова, Суфия Саттарова һәм Василий Жарковлар белән бергә укый.

Бу уку йортын бик яхшы билгеләргә генә тәмамлап, Әлфия апа «Опера һәм камера җырчысы» дигән белгечлек алып чыга. Ул уку елларында ук Мәскәүнең зур сәхнәләрендә чыгыш ясап, берникадәр тәҗрибә туплый. Мәсәлән, 1950 елда танылган җырчы, педагог Антонина Нежданова вафат булгач, аның белән хушлашу концерты була. Әлфия апа анда татар халык җыры «Тәфтиләү»не башкара.

П.Чайковский исемендәге Мәскәү дәүләт консерваториясенең зур залында шул уку йортын тәмамлаучылар концертында катнаша. Ул, Рөстәм Яхинга (фортепиано) кушылып, Нәҗип Җиһановның «Алтынчәч» операсыннан һәм Римский-Корсаковның «Кар кызы» («Снегурочка») операсыннан арияләр башкара.

Әлфия Галимова 1950 елда Казанга кайтып, Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрына эшкә урнаша. Анда солист булып унбер ел эшләү чорында ул, катлаулы партияләрне башкарып, опера сөючеләрнең мәхәббәтен яулый. Алар арасында Н.Җиһановның «Алтынчәч» операсында – Алтынчәч, Җ.Фәйзинең «Башмагым»ында – Сәрвәр, Дж.Россининың «Севилья чәчтарашы»нда («Севильский

цирюльник») – Розина, Глинканың «Иван Сусани»ында – Антонида, Ш.Гуноның «Ромео һәм Джульетта»сында – Джульетта һәм башка партияләр бар.

Әлфия Галимова 1957 елда театр коллективы составында Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында катнаша, ул анда Н.Җиһановның «Алтынчәч» операсыннан Алтынчәч ариясен җырлый. Декадага барырга әзерләнү өчен театрга баш режиссер булып Нияз Даутов чакырыла. Театрның яңа уңышларында әлеге талантлы шәхеснең роле зур була.

1961 елда Әлфия апага Мәскәүдә уку мөмкинлеге килеп туа. Ул, Мәскәү дәүләт консерваториясенең аспирантурасына укырга кереп, тагын да югарырак белем алып чыга. Аны тәмамлап, Казанга кайткач, Әлфия апа музыка училищесында укыта башлый, шул ук вакытта Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе концертларында да чыгыш ясый. Әлфия Галимова 1966 елда укыту эшен калдырып, Филармониядә әдәби-музыкаль лекторий бүлеге солисты булып эшли башлый, татар композиторларының әсәрләрен, бөтендөнья күләмендәге музыкаль әсәрләрне пропагандалый. Ул концертларда төрле опералардан катлаулы арияләр, аерым күренешләр, романслар һәм татар халык җырларын башкара.

Язучы Гомәр Бәширов, Әлфия Галимованың җырлавына сокланып, үзенең фикерләрен һәм киңәшләрен аңа һәрвакыт хатлар аша җиткерә. Әлфия апа әлеге хатларның кайберләрен безгә истәлек итеп тапшырган иде. Аның иҗаты олуг язучы тарафыннан югары бәяләнгән шул хатларның кайберләрен бу язмада күрсәтеп үтәсе килә.



«Хөрмәтле Әлфия туташ!

Һич көтмәгәндә шушындый хат белән китап килеп төшүе, бәлки, Сезне гаҗәпләндерер? Шул сәбәпле, күрәсең, берникадәр аңлатып бирергә кирәктер. Мин – Сезнең чыгышларыгызны көтеп алып яратып тыңлаучыларның берсе. Сез халык җырларын да, шулай ук катлаулы арияләрне дә зур осталык белән, ифрат талантлы башкарасыз. Әмма Сез җырлаган әсәрләрдән мине аеруча дулкынландырганы «Гөлҗамал» икәнлеген әйтмичә уза алмыйм. Минем бу гаҗәеп җырны бервакытта да дулкынланмыйча тыңлый алганым юк. Нинди бай эчтәлекле соклангыч көй бу! Анда ниләр генә юк! Минем аңлавымда «Сибелә чәчәк», «Зиләйлүк», «Карурман» кебекләр белән бергә, бу көй – татар халкының катлаулы музыкаль талантының бик матур бер үрнәге, ул гүзәл талантның сокланcгыч җимешләреннән берсе. Бу көйләрдә халык үз рухының бөеклеген, гомер буена хөрлекне сөюен, аны тәкъдир итеп килүен, яшәешнең вак-төягеннән өскә күтәрелеп, бөтен тарихы буенча нииндидер якты бәхеткә-сәгадәткә, камиллеккә омтылуын сокланcгыч тирән моң белән, ифрат дәрәҗәдә оста итеп әйтеп бирә белгән. Бәлки, бу минем коры хыялым гынадыр, бәлки, белгечләр күзлегеннән чыгып, нечкә үлчәүләргә сала башласаң, бу алай ук та

түгелдер? Әмма сәнгать әсәрен һәркем үзенчә аңлый, һәркем үзенчә тәм таба. Аның асыл кыйммәте дә шунда. Мәгълүм ки, «Гөлҗамал»ны башкалар да җырлый. Шулай да, минемчә, бу җырдагы моңның иң нечкә нюансларын, иң нәфис һәм шул ук вакытта иң тетрәткеч борылышларын Сез һәммәсеннән дә тирәнрәк, күңелгә үтемлерәк итеп бирә аласыз. Менә шулар өчен һәм, гомумән, Сезне яратып, тыңлаучыларга бик күп кадерле һәм куанычлы минутлар бүләк итүегез өчен, Сезгә чын күңелдән бик зур рәхмәт!

Сезгә бүтән китапны түгел, нәкъ менә шушы китапны бүләк итүемнең сәбәбе шул: бу мәшһүр артистка да – Сезнең кебек, үзенең бөтен гомерен, барлык иҗади көчен сәнгатькә багышлаган сөйкемле талантларның берсе. Шунлыктан бу китап, бәлки, Сезгә ошап китәр дигән идем. Әле генә башланып киткән Яңа ел Сезгә зур шатлыклар, куанычлы иҗат уңышлары алып килсен, бу ел Сезнең иң бәхетле елларыгызның берсе булсын!

Сезгә зур ихтирам белән, Гомәр Бәширов.
25 гыйнвар, 1968 ел, Казан».

«Хөрмәтле Әлфия!

Хатыгызга соңгарак калып җавап бирәм, гафу итегез. Дөнья мәшәкатеннән бушап булмый, картайган саен эш күбәя генә бара. Мин Сезнең хәзерге хезмәтегезнең никадәр кыен һәм хөрмәтле дә, җаваплы да икәнлеген чын-чыннан менә шушы хатыгыздан гына аңладым. Гомумән, Сезнең хезмәтегез бик авыр, кайберәүләр аның кадерен дә белеп җиткермиләр. Авылдан-авылга йөк машинасында чабучы, бер көндә икешәр концерт бирүче Филармония артистларын күреп, җаным әрни. Алар бит шундый шартларда өс-башларын гына түгел, затлы кием-салымын да, тавышын да, нәфислеген дә сакларга тиеш, авыр юллардан соң да күңелен төшермәү генә түгел, бөтен залның күңелен күтәрергә, матурлык, нәфислек, гүзәллек үрнәкләрен күрсәтергә тиешләр. Андый шартларда коточкыч авыр вазыйфа бит бу! Нигә кайгыртмыйлар икән азрак? Теге дәшүегездә бара алмадым. Бик пычрак та, уңайсыз да вакыт иде. Шуның өстенә, бәлки, Ленинградка Сез дә барасыздыр дибрәк уйлаган идем. Алай икән. Мин үзем кешенең исемен түгел, бәлки, кешелеген һәм талантын ихтирам итүчеләрдән. Шул сәбәпле Сезгә ихтирамым бик зур. Сезнең хакта, һичшиксез, язарга телим. Ләкин бу араларда булмый әле. Хәзер бездә мәхшәр, съезд башлана. Ничек тә булса шуннан соң. 26 майда шимбә көн радиодан «Җыр канаты – исәр җилләр, агар сулар» дигән бер тапшыру бирергә җыеналар. Шуны тыңлап карый алмассызмы? Сезгә ошар микән? «Язарга телим» диюем мактану булып аңлашыла күрмәсен. Мин бит музыка белгече түгел, ничек аңласам, шуны гына яза алам. Тырышып карар идем, диюем. Хатыгыз өчен рәхмәт. Мин Сезгә чын күңелдән уңышлар телим. Җай килеп чыкса, һич кыенсынмыйча хат языгыз.

Бик күп сәламнәр белән, Гомәр Бәширов.
10 май, 1979 ел, Казан».

Әлфия Әхәт кызы 1986 елда лаеклы ялга чыга, әмма иҗат эшчәнлеген туктатмый, иҗат концертларын үткәреп килә, Татарстан радиосында күп кенә язмалар калдыра. 80 яшьлек юбилей кичәсен ул Дәүләт зур концерт залында үткәрә. Үзенең 90 яшьлек юбилей елында да, «Филармониада» халыкара музыка сәнгате фестивале кысаларында, Татар дәүләт филармониясендә «Җыр осталары» концертында чыгыш ясап, зур соклану уяткан иде асыл җырчыбыз. Ул, 2015 елның 25 мартында бакыйлыкка күчеп, Казан шәһәрендә җирләнде. Рухы шат, урыны оҗмахта булсын мәрхүмәнең! ■

Тарихта калган дусларны искә алып...

Нәзифә Кәримова

Нәзифә һәм Илгиз Кәримовларның иң истәлекле көне

Бу фотосурәт беренче карашка әллә ни сөйләми дә кебек. Бер парның өйләнешү чарасы, шул тантанага килгән кунаклар... Шуннан ни?.. Бу ике яшь –Илгиз белән мин. Безнең йөзләр бик җитди. Бу – язылышуыбызны теркәүче ханымның, яңа тормышка аяк басуның җаваплылыгы турында сөйләп, безне куркуга салган мизгелләредер, күрәсең. Әлбәттә, мин туй турында язарга җыенмыйм....

Язмам ирем Илгиз ягыннан туебызда шаһит булган дустыбыз – рәссам, скульптор, Аракчинода әнисенең йорт биләмәсендә үз хисабына төрле диннәрнең храмын төзегән искиткеч талантлы кеше – Илдар Ханов турында булыр. (Фотода ул Илгизнең сул ягына баскан.) Илгизнең болай дип сөйләгәне бар иде: «Илдарга өйләнешергә җыенуыбыз турында әйтеп: «Туйда минем яктан шаһит итеп сине чакырам, ризамы?» – дип сорагач, Илдар, ияген сыпырып: «Кырынырга туры килер инде, әйеме?..» – диде». Шуны сөйләгәч, Илдар гына шулай әйтә ала, дип көлгән идек. Чөнки котлау сүзе дә, шаккату да юк. Менә шулай... Илдар шундый кеше иде.

Нәзифә Кәримова

Татарстанда зур үрләр, олуг хөрмәт яулаганчы, аңа иҗаты өчен бик зур авырлыклар, газаплар, җаны кыйналуларны кичерергә туры килде.

Илдар Ханов…

…Мин элекке фотоларны карап, таныш йөзләрнең кем икәнлеген ачыкларга яратам. Менә әле дә Илдар хакында яза башлаганчы, башта бу фотодагы таныш чалымлы шәхесләрне сезгә дә танытасым килә. Иң беренче күзгә ташланганы, – әлбәттә, Илгизнең әтисе Мостай Кәрим. Ул минем янда баскан дустым, теркәлүдә минем яктан шаһит булган, хәзер инде Татарстанның атказанган артисткасы Зәйтүнә Яруллина артында тора. Әткәйнең сул иңе ягыннан Илгизнең сеңлесе Әлфиянең башы күренә. Әткәй белән Зәйтүнә арасындагы ялтыраган күзләр Мостай Кәримнең тәрҗемәчесе Елена Николаевскаяныкы. Диварга аркасын терәп, түшәмгә күзләрен төбәгәне – Илгизләр ягыннан булган кунак – Юрий Кривоносов. Алга китеп шуны да әйтим: язылышканнан соң, Мәскәүдәге бер бүлмәле фатирда туй үткәргәндә барыбызны да көлдереп, ул болай дип шигырь сөйләгән иде (фотода шул шигырне уйлап торган мәледер, бәлки, дип уйлыйм хәзер):

«Мустай Карим не повторим,
Но есть еще Ильгиз Карим.
Он род Каримовых быть может,
Как на ротаторе размножет!»

Юраның әнисе Роза Ароновна белән каенатай сугыш вакытында фронтта дуслашканнар. Алар гомер буе дус булып яшәделәр. Без дә аларда еш була идек. Хәзер инде 100 яшькә якынлашып килгән Юрий Кривоносовның янына барып хәлен белеп торабыз.

Фотосурәттәгеләрне карауны дәвам итик әле. Илдарның уң як иңе өстендә Клара Хәйретдинованы күрсәк, сул ягында – Римма Ибраһимова. Римма белән рәттән сиам игезәкләре кебек басып торучы кыз – Надия Низамиева. Ул биюче Фердинанд Гыймадиевка кияүгә чыкты. Эстрадада аз эшләде. Калганнарны бары тик белгәннәр генә таный алыр. Кызлар артында – Мәскәүдән укып бетереп кайткач вафат булган биюче мәрхүм Рөстәм Юнысов, Клара артындагы егетләр – Виктор Шәрәфетдинов белән Мөнир Мөхәммәтдинов. Калганнары инде – безнең Мәскәү дусларыбыз.

Бу фотосурәт ясалган көн – 1970 елның 19 августы. «Бөтенрусия эстрада сәнгате иҗат остаханәсе»ндә укуны тәмамларга бары өч ай вакыт калган. Өч айдан алар, берүземне калдырып, барысы да Казанга – Филармониягә кайтып китәчәк. Ә мин, алар белән бергә ике елга якын Мәскәүнең театр-концерт залларын бер итеп йөргән сүз остасы, яшь артистка, Мәскәүдә калачакмын. Бу көннәр минем язмышымда иң кискен борылыш ясаган вакытлар. Тормыш юллары бормалы-бормалы дигән сүзләр юкка гына әйтелмәгәндер, күрәсең.

Уку елларында Мәскәүдә танышкан дусларымның берсе иде ул Илдар Ханов.

Аның белән мине Илгиз таныштырды. Әле өйләнешкәнче, Илгиз белән Илдарның Мәскәүнең нәкъ уртасындагы остаханәсенә еш барып йөрдек. Анда шагыйрьләр, артистлар, рәссамнар җыела иде. Илдарның: «Әле кичә генә Владимир Высоцкий остаханәмдә кунып китте», – дип сөйләгәнен хәтерлим. Остаханәсендә ул безне үзенең картиналары, скульптураларының кечкенә макетлары, яңа эшләре белән дә таныштыра иде. Ә менә аның «Хиросима» дип аталган берничә зур-зур картинадан торган сериясен беркайчан да онытасым юк. Хиросимага атом бомбасы ташланганнан соң, халыкның шул афәттән котылырга тырышуы, үлем ачысы газаплары тасвирланган иде ул картиналарда. Аның ул эшләре Казандагы күргәзмәләрдә күрсәтелдеме икән – миңа билгеле түгел. Шунысын гына яхшы хәтерлим: ул полотнолар, куяр урын булмаганга, бер йорт идарәсенең подвалында саклана иде. Бик үзенчәлекле ысул белән ясалган картиналар иде алар. Илдар ул картиналарны пумала белән түгел, буяуларын сиптергечкә салып ясый торган ысул белән эшләгән иде. Илдарга хас булган монументализм алымнары аның әлеге «Хиросима» дип аталган картиналар сериясендә яхшы күренә иде. Шунысы кызганыч: ул картиналар үзләре дә фаҗигале язмышка дучар булды. Зур күләмле картиналарның күбесе, йорт подвалында торба шартлап, кайнар суга манчылудан зур зарар күрде. Илдар әлеге югалтуны бик авыр кичерде.

Илдарның шул эшләренә бәйле тагын бер истәлек. Бәлки, кемнәрдер хәтерлиләр дәдер – Мәскәүдә нәшер ителә торган «Дружба народов» дигән бер журнал бар иде. Ул журналда безнең илдәге күптөрле милләт язучыларының тәрҗемә әсәрләре басылып килде. Әлеге журнал бары тик милли язучыларның рус теленә тәрҗемә ителгән әсәрләрен бастырыр өчен генә уйлап табылган журналдыр дип уйлыйм. Тәрҗемәчегә дә эш, язучыларның әсәрләрен рус теле аша башка милләтләр дә таный ала. Хәзер бармы ул, юкмы – белмим. 70 нче еллар башында шуның баш мөхәррире, рус язучысы Сергей Баруздин Бразилиягә командировкага барган. Шунда язучылар, сәнгать әһелләре белән очрашуда аннан: «Сез Илдар Хановның иҗатына ничек карыйсыз?» – дип сораганнар. Ул, Илдар хакында ишеткәне булмаса да, кем соң ул, дип сорамаган, яхшы карыйм, бик талантлы кеше, дигән. Ә инде Мәскәүгә кайткач, Илдарны эзләп табып һәм аның алты картинасының фоторәсемнәрен, шул исәптән Хиросима турында-

Илдар Хановның Чаллыдагы «Ватан-Ана» сыны. ***Фото autotravel.ru сайтыннан алынды.***

гыларын да «Дружба народов» журналында бастырып чыгарган. Илдар безгә шуның өчен 300 сум гонорар түләгәннәрен, үзенең баштан-аяк киенүен бик шатланып сөйләгән иде. «Художник ач-ялангач булырга тиеш» дигән гыйбарәне искә төшерсәк, Илдар ул хәлләрне тулысы белән кичергән кеше.

Илдар үзенең укытучысы итеп Мексиканың монументаль скульпторы Давид Сикейросны атый иде. Аның да шул ысул белән иҗат иткән әсәрләре күп. Илдарның иң зур эшләренең берсе итеп яңа гына төзелә башлаган Чаллы шәһәре уртасына салынган «Ватан-Ана» скульптурасын әйтергә кирәк.

Ул скульптура 1975 елда берничә ай эчендә Җиңүнең 30 еллыгына багышланып эшләнә. Биш катлы өй биеклегендәге бу зур монументаль әсәрне бик күп кеше катнашында 3-4 айда башкарып чыгалар. Мондый зур, һәйкәл генә түгел, корылма өчен бу вакыт бик аз, әлбәттә. «Ләкин без бертуктаусыз эшләдек, бәйрәмгә өлгертергә тырыштык һәм эшебез барып чыкты!» – дип сөйләгән иде Илдар.

Шул вакытта яңа төзелә башлаган шәһәрне үз күзләре белән күрергә Чаллыга КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы әгъзасы, партиянең Үзәк Комитеты секретаре Андрей Кириленко килә. Әлбәттә, аңа яңа гына төзелеп беткән шушы зур һәйкәлне күрсәтәләр. Кириленко, «Ватан-Ана» дип аталган һәйкәлне күрүгә, бик нык ачуланып: «Мондый һәйкәл булмый, булырга да тиеш түгел, моны кичекмәстән шартлатырга кирәк!» – дигән катгый карарын әйтә. Әлбәттә, сынчы Илдар Ханов җитәкчелегендә эшләгән, бу һәйкәлне төзегән йөзләгән кешенең эшен шартлатмадылар, Аллаһ рәхмәте. Ләкин комиссия артыннан комиссия, тикшерү артыннан тикшерү белән Илдарны йөдәтеп бетерделәр. Ул бу һәйкәлнең һәр комиссия өчен күптөрле макет-модельләрен хәтта бронзадан да ясарга мәҗбүр иде. Ни өчен мин аны тәфсилләп язам, чөнки барысы да безнең күз алдында булды. Ул,

безне чакырып: «Карагыз әле, берәр фикер әйтегез әле, кай төше килешмәгән?» – дип сорый иде. Ул, «Ватан-Ана» канатлары астына сыенган образлар турында сөйләп, язып, күпме тикшерүчеләргә үзенең иҗат эшенең яшәргә хаклыгы турында дәлилләр китереп, яклап кала алды. Ләкин Илдарга шушы җәнҗалдан соң күп еллар дәвамында Татарстанда эшләргә рөхсәт итмәделәр.

Дөнья шул ягы белән әйбәт: ул үзгәрүчән. Искеләр китә, яңалар килә... Әкрен-әкрен каткан җаннардагы бозлар эри, заманнар үзгәрә. Илдарга иҗатын күрсәтү, күргәзмәләр оештыру мөмкинлекләре дә тудырылды. Ләкин бу әле Илдарны күтәреп алдылар дигән сүз түгел иде.

Тик шулай да ул Казанга күчеп китте. Без аның белән күп кенә еллар очрашмадык. Бервакыт Казанда Илдарның күргәзмәсе турында игълан күреп, мин күргәзмәләр галереясенә килдем. Илдар да анда иде. Ул, кичә генә аерылышкан кебек, елмаеп, элеккечә: «Парин, ни хәл син?!» – дип, кочаклашып күреште. Һәм шунда ук миңа: «Бавырыңны тикшерт әле син, яме», – диде.

Мәскәүдә чакта әле без Илдарның экстросенсорлык сәләте барлыгын белми идек. Күп еллардан соң ул, Мәскәү метросында аның иҗат остаханәсенә безнең белән йөри торган уртак дустыбызны очраклы туры китереп, хәлләрен сорашкан. Дустыбыз улының сәламәтлегеннән зарланган. «Улың белән барысы да әйбәт булачак, үзеңне кайгырт», – дип, ул аңа сәламәтлеге өчен бик файдалы киңәшләр биргән.

Илдар бу сәләтен өч-дүрт яшьлек чагында яшәү белән үлем арасында ятканда аңлап ала. Төшенә Гәйсә пәйгамбәр (г.с.) керүен, аңа оҗмахларны күрсәтүен, ләкин синең җирдә эшең бетмәгән әле, дип, аны җиргә озатуын безгә беркайчан да сөйләгәне булмады.

Ни булса да булгандыр инде, Илдар гадәти кеше түгел иде. Аның үз акчасына, бары тик үз хезмәте белән Аракчинода әнисенең йорт биләмәсендә барлык диннәрнең храмын төзи башлавы, соңгы елларын шуңа багышлавы шул турыда сөйләмимени?! Аның миңа: «Ярдәм кирәк түгел, комачауламасыннар гына иде!» – дигәне булды.

Мәскәүдән Казанга поездда кайтканда вагондагы юлчылар, Казанга экскурсиягә баручылар, әле Казанга килеп җиткәнче, поездддан күренә торган бу ачык һавадагы музейны күрер өчен, тәрәзәгә ябырылалар. Алар инде белә, әле күргәннәре булмаса да, ишеткәннәр, шуларны якыннан күрер өчен Казанга ашыга алар.

Мин дә карыйм, күпме генә карасам да, кабаттан күрәсем килә. Шул диннәр «җитәкләшкән» манаралар арасында Илдар да йөри сыман тоела миңа. Ул урын хәзер – Казанның иң матур, иң кызыклы, каланың яңа тарихы урыны. Илдарның кул җылысы белән генә түгел, җан җылысы белән барлыкка килгән бу храмнар, манаралар Татарстанга, Казаныбызга дан өсти. Аны безнең талантлы яшьлек дустыбыз, минем якташым, тумышы белән Мамадыш ягыннан булган Илдар Ханов төзегән. Әнисенең йорт биләмәсендәге дөньякүләм танылган сәнгатьче, рәссам, сынчы Илдар Хановның кочагына сыйган бу музей аның үзенә салынган һәйкәл бит ул.

Менә шушы кечкенә генә фотосурәт илле ике ел элек булган вакыйгаларны искә төшереп истәлекләрне яңартты да, мине бүгенге көнгә кайтарды.

Бакыйлыктагыларның рухлары шат булсын, дөньялыктагылар бәхетле яшәсен иде. Амин! ■

Җуелмас хәзинә

«Өй артында шомыртым» җыры

«Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр».

Габдулла Тукай

Тәртип радиосы

Өй артында шомыртым

(Татар халык җыры)

Өй артында шомыртым бар,
Яннарында бөрлегән шул,
Яннарында бөрлегән;
Бөрлегәндәй матур булып
Чәчәк ата ил генәм.

Өй артында шомыртым бар,
Чәчәкләр яннарында шул,
Чәчәкләр яннарында;
Без туганбыз илебезнең
Иң матур таңнарында.

Өй артында шомыртым бар,
Яннарында чияләр шул,
Яннарында чияләр;
Чияләр дә безгә карап:
«Сез бәхетле!» – дияләр.

«Өй артында шомыртым» җыры 1945 елда Гөлсем Сөләйманова тарафыннан язып алынган.

Бу җыр җырчыларыбыз Римма Ибраһимова, Венера Ганиева, Гөлнара Тимерҗанова, Сиринә Зәйнетдинова һәм Диләрә Курамшина репертуарына кергән.

Язучы Камил Кәримовның шул исем белән аталган китабы да («Мәгариф» нәшрияты, 2003) бар.

ТАССРның атказанган (1978) һәм ТАССРның халык артисты (1984), Татарстан Республикасының М.Җәлил исемендәге премиясе лауреаты (1984), Татарстанның Балтач районындагы Түбән Кенә авылы тумасы, «Өй артында шомыртым» җырын башкаручыларның берсе Римма Мөбарәк кызы Ибраһимова



«Өй артында шомыртым» җырының нотасы

Сәхифәне, «Тәртип» радиосында яңгыраган «Саф вә раушан көзге» тапшыруы (авторы һәм алып баручысы – Гөлфия Мөхәммәтгәрәева) материалларына нигезләнеп, Ләбиб Лерон әзерләде. ■

Шомырт

Шомырт – куе ябалдашлы, биеклеге 10 метрга җитә торган агач яки зур куак. Кәүсәсенең кайрысы кара-соры, яшь ботакларыныкы кызгылт-көрәнсу.

Шомырт сүзен борынгы төрки телдәге *уймуру* (йомры) сүзеннән чыккан дип исәплиләр: җиләкләре кап-кара төстә – йомры бит.

Себер татарлары аны *муел* дип атый.

Халкыбыз шомырт агачына үтә сак карашлы, без моны сынамышларда ачык күрәбез. Мәсәлән, телебездә «Шомырт уңса, иген уңмас» яисә «Шомырт уңдымы, ел ач булыр» кебек гыйбарәләр әле дә яшәп килә.

Шомырт агачын безнең халык өй каршына утыртырга ярата. Моның бер сәбәбе – аның язын шау чәчәккә күмелеп, тирә-юньгә хуш ис таратып утыруы.

Халкыбыз аның бу матурлыгын җырларга да керткән. Мәсәлән, «Өй артында шомыртым», «Шомырт» кебек җырларыбызны гына искә төшерик.

Шомыртның өлгереп җиткән җиләге, баллы, витаминнарга бай булуы аркасында, халкыбыз көнкүрешендә шактый актив кулланылышта йөри. Аннан тәмле компотлар әзерлиләр. Шомырт оны ясап, кышка хәстәрләп куялар. Элек шул оннан әчлек ясап, кышларын бик тәмле шомырт бәлешләре пешерәләр иде. Кипкән шомыртны әле дә кул тегермәнендә тарттырып, кышка онын әзерләп куючылар бар.

Шомыртның тагын бер үзенчәлекле «вазыйфа»сы – аның белән әбиләребез һәм әниләребез теге яисә бу яшелчәне утырту вакытын билгели торганнар иде. Шомырт чәчәк атып бетерми торып, суган утыртырга ярамый, дигән сынамыш шуннан килә. Бу инде шомырт чәчәк койгач кичке салкыннар, таң алды кыраулары булмау белән бәйле. Әле тавыкларның чеби чыгару вакытларын да шомырт чәчәк атып бетәр вакытка чамаларга тырыша торганнар иде. Бу да яңа чыккан чебиләрне төнге салкыннардан саклау мәшәкате булдырмауга бәйле.

Сәхифә «Татар халкы традицияләрен саклау һәм үстерү «Татар ядкярләре» шәхси учреждениесе (җитәкчесе – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе ***Фәнзилә Җәүһәрова****) белән берлектә әзерләнде.* ■

Шомырт турындагы видеоязманы шушы QR-код ярдәмендә кереп карарга мөмкин.

Шомырт дәвалый

Медицинада шомыртның җимешләре, сирәк кенә кайрысы кулланыла. Җимешләрендә флавоноид һәм антоциан матдәләр, алма һәм лимон кислоталары, С витамины, каротин, шикәр, дуплау матдәләре, эфир мае бар. Моннан тыш, төшләрендә, шулай ук чәчәкләрендә, яфракларында һәм кайрысында глюкозага һәм иң агулы матдәләрнең берсе булган синил әчелегенә (кислотасына) таркалучы амигдалин гликозиды бар.

Балачакта эч йомшаган вакытта әбиләребез келәттә эленеп торган янчыктан кипкән шомырт алып бирә торганнар иде.

Шомырт кайрысы эч киткән очракларда табигый дару буларак кулланыла. Мәсәлән, аның үт һәм сидек кудыру сәләте бар; кайрысыннан ясалган төнәтмә радикулит булганда ярдәм итә, яфракларыннан ясалганы тамак төбе авыртканда һәм йөткергәндә файдалы. Подагра авыруы һәм диабет булганда шомырт дәвасы тәкъдим ителә. Бу җимешнең төнәтмәсе теш сызлавын киметә (берничә җиләген чәйнәп, авырткан урынга куеп торырга була), шулай ук аны күзләрнең лайлалы тышчасы ялкынсынганда да кулланалар.

Шомырт төнәтмәсенең баш авыртканда да файдасы тия. Моның өчен мондый рецепт белән төнәтмә әзерләнә: шомыртның 10 г коры кайрысы алына, аны ваклап, 1 стакан суга салырга һәм кайнатырга кирәк. Шуннан соң сыгып сөзәргә, беренче күләменә кадәр җитәрлек итеп кайнаган су өстәргә. Кабул итү тәртибе: ашар алдыннан көненә 3 тапкыр 1/3 стакан эчәргә.

Халык медицинасында шомыртны потенцияне күтәрү чарасы дип исәплиләр. Моның өчен кайнар суга 25 җимеш салып ясалган төнәтмәне ярты сәгать җылыда тоталар һәм көненә 4 тапкыр 2шәр аш кашыгы эчәләр. Әлеге төнәтмә эчәклек яки ашказаны эшчәнлеге бозылганда да ярдәм итә.

Витаминнар һәм микроэлементлар мәсьәләсенә килгәндә, шомыртта магний, бакыр, тимер, цинк, марганец; С, Е һәм Р витаминнары; лимон һәм алма кислоталары шактый күләмдә.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Көлке куа килә...

Бари Рәхмәт (1897-1957)

Хатын орыша

Мәхәббәт турында яз, диләр,
Андый җырлар бездә аз, диләр.
Мин үзем язарга тырышам.
Язып булмый... Хатын орыша.
«Мине сөйгән чакта язмадың,
Инде карт көнеңдә язма!» – ди.

Фәнзаман Баттал.
Зөлфәт Хәйруллин шаржы

Фәнзаман Баттал (1939-2015)

Кем беләндер бит...

Фәхри Насретдинов, яшь җырчы Рафаил Җаббаров белән очрашкач, тиздән гастрольгә чыгачагы турында әйтә.

– Ә-ә, мин бу хакта ишеттем инде, Фәхри абый, – ди Рафаил. – Сара апа Садыйкова белән чыгасың икән.

Фәхри Насретдиновның хәтере кала. Авызын Рафаилның колагына ук терәп, ул:

– Юк, энем, ялгыш аңлагансың. Сара минем белән чыга! – дип, зәһәр пышылдый.

Нишлисең бит, сәнгать кешесе үзен икенче яки өченче итеп күз алдына да китерә алмый. Ул һәрвакыт беренче!

Мөхәммәт Мәһдиев (1929-1995)

Икесе дә ялгыша

Җыелышта берәү үзенең начальнигын тырышып-тырышып мактый икән. Аңа:

– Син аны мактыйсың-мактыйсың да, ул сине гел сүгә бит, яманлый, – дигәннәр. Тege кеше:

– Ихтимал, без икебез дә ялгышабыздыр, – дигән.

Нияз Акмал (1954-2007)

Чырам булса...

(Пародия)

Чырам булса, горур йөрткән
башымны имәс идем.
...Бергә булсак, сине, бәлки,
букадәр сөймәс идем.

Равил Фәйзуллин

Бергә булсак... Әй кадерлем,
Мин учак ягар идем, –
Шырпым булмаса да, бер-бер
Чарасын табар идем.

Бер чара тапмаганда да
Бер чыра табар идем,
Бергә булсак!... Мин, чынлап та,
Бер учак ягар идем...

Илдар Юзеев.
Зөлфәт Хәйруллин шаржы

Илдар Юзеев (1933-2004)

Ике эпиграмма

Мансур Вәлиевкә
Авторларның ятканы
Мактап язу... һәм мәйдер.
Заман тәнкыйтьтән дә түбән,
Тәнкыйть – кирәксез шәйдер.

Георгий Ибушевка
Рәхмәт тә юк Ибушка –
Җырлап йөри... и бушка!

Земфира Гыйльметдинова (1967-2021)

«Бишек биюе»

Зөфәр Билалов белән Зәйнәп Фәрхетдинова төркеме озак вакытка гастрольләргә чыгып китә. Гастрольләр вакытында, гадәттә, һәркем нинди дә булса эш белән мәшгуль. Кайсысы шәһәр карап йөри, кемдер репетиция ясый, кайсылары исә йокы симертә. Шундый көннәрнең берсендә биючеләр ду килеп репетиция ясыйлар. Аз гына черем итим дип яткан тавыш режиссеры Саша Королев һич йокыга китә алмый. Түзмичә бүлмәсеннән чыга да:

– Карагыз әле, сезнең «Бишек биюе»гез юкмы? Булса, шуны биегез әле! – ди.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■



БЕЗ БАРЫБЫЗ ДА – БАЛАЧАКТАН

«Балачак мирасы» сәхифәсе – иң әүвәл сезнең өчен, өлкәннәр. Халкыбызның күңел җәүһәрләрен – такмак-такмазаларны, табышмак-башваткычларны, әкиятләрне, әдипләребезнең хикмәтле һәм гыйбрәтле, мәгънәви һәм тәрбияви әсәрләрен хәтерегезгә сеңдерегез, аларны, озын-озакка сузмыйча, балаларыгызга һәм оныкларыгызга җиткерегез, нәниләргә бишек җырларын көйләргә дә онытмагыз. Кыскасы, укыгыз, уйланыгыз һәм бер нәтиҗә ясагыз да... һәрвакыт безнең «Балачак мирасы» белән бергә булыгыз!

Бари Рәхмәт (1897-1957)

Май ае

Майдан да ямьле ай,
Җанлы ай юк бугай.
Беренче май белән
Башлана шул бу ай.

Һәр агач, һәр үлән
Чәчәккә күмелгән.
Әйтерсең, аларга
Ислемай түгелгән.

Аларның хуш исен
Киң сулап иснисең.
Бәйрәме дә майның
Күңелле ич, дисең!

Мәрзия Фәйзуллина (1930-2021)

Яз бәйрәме

– Шомырт, кемне яраттың,
Кем өчен чәчкә аттың?
– Ямьле язгы ай өчен,
Яз бәйрәме – Май өчен!

– Бик матур итеп шулай,
Ник җырлыйсың син, тургай?
– Олылап язгы айны,
Котлап Беренче Майны!

Әминә Бикчәнтәева (1913-1986)

Колын

– Иркен яшел болында
Чабасың да чабасың,
Син яшь кенә бит әле,
Аякларың талмасын!

– Юк, сез алай димәгез –
Көчем арта күп чапсам,
Ничек мин зур үсәрмен,
Көн буена тик ятсам?!

Заһирә Гомәрова (1930-2002)

Әби, укып бир әле

– Әбекәем, килсәнә,
Күзлегеңне кисәнә.
Язу язып утырдым,
Дәфтәремне тутырдым.

Үзем яза белсәм дә,
Күзем яхшы күрсә дә,
Укый белмим бит әле,
Әби, укып бир әле.



Ике табышмак

Сыер нигә ята?
(Утыра алмаганга.)

***

Каз, судан чыккач, нишли?
(Коры җиргә баса.)

Кызыклы арифметика

Өч малай һәм өч тиен

Әмир, Әхәт һәм Азат кибеткә бара. Юлда алар 5 сум акча таба. Әгәр Азат кибеткә үзе генә киткән булса, күпме акча табар иде?

(Җавап: шул ук 5 сумны.)

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

АПРЕЛЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● 6 апрельдә «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, Ульяновск шәһәрендә сәфәрдә булып, РФнең атказанган табибы, хирург, Буа районының Толымбай авылы тумасы Сәйдәш Миргасыйм улы Шәмсетдиновтан интервью алды.

● 11 апрельдә К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театрында шагыйрь Ләис Зөлкарнәйгә 60 яшь тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә (сценарий авторы – Рәдиф Сәгъди, режиссеры – Зөфәр Харисов) булып узды. Кичәдә юбилярны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат Зарипов, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, шагыйрьнең каләмдәш дусты Газинур Морат һәм сыйныфташлары, шәрикләре котлады, Тинчурин театры артистлары исә, әдипнең «Кыргын» дигән хикәясенә нигезләнеп, тарихи тамаша күрсәтте. Җырчыларыбыз Рөстәм Маликов һәм Гөлзада Сафиуллинаның, шулай ук Кытайда туып-үскән татар егете Базарбай Бикчәнтәевнең җырлавы нур өстенә нур булды.

● 13 апрельдә Казандагы А.Алиш исемендәге 20 нче гимназиядә (директоры – Рәхимә Арсланова), балалар шагыйрьләре – Эльмира Шәрифуллина, Ләбиб Лерон, Йолдыз Шәрәпова, Равилә Шәйдуллина-Морат катнашында, әдәби-музыкаль кичә үтте. Мәктәп укучылары әлеге каләм әһелләренең шигырьләрен яттан сөйләде. Чара «Туган тел» җырын күмәк башкару белән тәмамланды.

● 13 апрельдә легендар диктор, Татар театр техникумы (1949) һәм Казан педагогика институты (1963) студенты, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1977), Кемерово өлкәсенең Юрга районындагы Сарсаз авылы тумасы Мәрьям Ислам кызы Арсланова (Фәйзуллина) 96 яшендә вафат булды.

● 14 апрельдә Арча районының Кышкар авылында «Безнең мирас»журналының баш мөхәррире, шагыйрь, прозаик һәм драматург Ләбиб Лерон белән очрашу булып узды. Чарада «Нур» халык театры әдипнең әсәрләреннән өзекләр уйнады, җырлар башкарды, әдип үзе шигырьләрен укыды һәм тамашачыларның сорауларына җаваплар бирде.

● 15 апрельдә бер төркем татар зыялысы Татар бистәсе зиратында Габдулла Тукайны искә алды. ТР Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла алып барган әлеге чарада Апанай мәчете имам-хатыйбы Нияз хәзрәт Сабиров олуг шагыйрь рухына дога укыды, ТР мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, шагыйрьләр – Зиннур Мансуров, Мөхәммәт Мирза, Ләбиб Лерон, артист Илдус Әхмәтҗанов бөек шагыйребезгә нисбәтле нотыклар тотты.

● 15 апрельдә Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының баш режиссеры Фәрит Рәфкать улы Бикчәнтәев «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон белән очрашып, аның сорауларына җавап бирде.

● 16 апрельдә «Туфан Миңнуллин фонды» рәисе, драматург Данил Салихов «Миллият» кафесында ифтар уздырды. Ифтар вакытында Татарстанның халык язучысы, мәрхүм Туфан Миңнуллин рухына дога кылынды.

26 апрельдә Г.Тукай премиясенең быелгы лауреатлары игълан ителде. Ул Ләбиб Леронга («Җил көймәсе» (2009), «Әкиятче малай» (2016) китаплары өчен) һәм Анатолий Егоровка («Казан өстендә ай» («Над Казанью луна») гобеленнар циклы өчен) бирелде.

Лауреатларга премияне Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсеннән Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов тапшырды.

Бүләк ияләрен ихлас күңелдән котлыйбыз, сәламәтлек, иминлек һәм иҗат уңышлары телибез! ■

МИРАСВОРД

- Чумарның бер төре
- Гарәп артикле
- Кавказда әйләнештә йөргән борынгы көмеш тәңкә
- Бозаулыйсы сыер
- Ял итү өчен тукталыш (бор.)
- Ашлык әрҗәсе
- ... кагы
- Б.э.к. Кара диңгез буенда яшәгән күчмә кабиләләр
- Кытай (иск.)
- Гарәп хәрефе
- Язучы ... Бакиров
- Шагыйрь ... Имаев
- Каенана (диал.)
- Төрле төстән буй-буй сугылган киндер
- Берничә элмәкле дар
- ... Дәүли
- ... Гыйззәт (әдәбият галиме, тәнкыйтьче)
- Тарихчы Наил ...
- Юпитер иярчене
- Чыңгыз, Батый
- Язучы, журналист ... Кәримова
- Госманлы империясендә офицер титулы
- ... Урда
- ... Шәфигуллин
- Мәхмүт Хәсәновның «Язгы ажаган» романындагы герой
- Конфуций Ватаны
- Урта гасыр үзбәк шагыйре
- Шәрык илләрендә таралган кыллы уен коралы
- ... сикереш (балалар уены)
- Габдерәхим ... Имәни
- Ив Сен-... (француз модельеры)
- Тәтегә басу
- Сай эчтәлекле көлкеле пьеса
- Шагыйрь ... Шәфи
- Ерак басуда эшләүчеләр-нең күчмә өе
- Корабның җил, агым тәэсирендә юнәлешен үзгәртүе
- Шәрык поэзиясендә ике юллык шигырь
- ... Мөхәммәтшин (ТР Дәүләт Советы рәисе)
- Әхмәд ибн ...
- Язучы ... Хафизова



4 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: Гата, Анри, Таҗи, кич, Бану, киләп, Солтан, Немо, Карл, утлар, «Аида», Сидней, Делиб, диване, гондола, Мар, Янка, мәрә, Ан, Җәвад, Әйди, Ив, ислах.
Өстән аска: сак, Гамбәр, аса, Норадын, Рада, Гатауллин, әни, девон, таҗ, калай, «Аникин», дая, «Ил», ди, Нәҗми, Бикчәнтәев, пел, лама, Вил, Марина, Ава, шор, Бермуд.

Рәис Габдулла төзеде.

«Безнең мирас»

елъязмасы / май

Алмыш хан (IX гасыр ахыры-X гасыр башы) Багдад илчелеген кабул итә. 922 ел.
Фиринат Халиков рәсеме

1100 ел элек (922)

21 майда Идел Болгарстанында ислам дине рәсми рәвештә кабул ителә.

790 ел элек (1232)

Мәшһүр шагыйрь Кол Гали «Кыйссаи Йосыф» әсәрен иҗат итә. («Татар энциклопедия сүзлеге»ндә 1236 ел дип күрсәтелгән.)

725 ел элек (1297)

Татар әдибе, дин эшлеклесе Мәхмүд Болгари (якынча 1297-1360) дөньяга килә.

410 ел элек (1612)

Лейпцигта беренче татарча басма китап дөнья күрә.

160 ел элек (1862)

18 майда төрки телләр белгече, этнограф, профессор Николай Федорович Катанов туа.

125 ел элек (1897)

29 майда балалар шагыйре Бари Рәхмәт (Габделбари Сибгатулла улы Рәхмәтуллин, 1897-1957) дөньяга килә.

100 ел элек (1922)

22 майда Казан аграр университеты төзелә. Оешкан көненнән – Казан авыл хуҗалыгы һәм урманчылык институты, 1930 елдан – Казан авыл хуҗалыгы институты, 1995 елдан – Казан авыл хуҗалыгы академиясе, 2006 елдан хәзерге исемен йөртә.

100 ел элек (1922)

Казанда айлык әдәби-нәфис һәм иҗтимагый сәяси журнал – «Казан утлары»ның беренче саны басылып чыга. Аның берничә мәртәбә исеме алмашына: 1922-1930 нчы елларда – «Безнең юл», 1930-1932 нче елларда – «Атака» һәм «Яңалиф», 1933-1965 нче елларда – «Совет әдәбияты», 1965 елдан – «Казан утлары».

90 ел элек (1932)

Казанда авиация техникумы оештырыла.

80 ел элек (1942)

1942 елда Казанга эвакуацияләнгән «Төньяк балкышы» Ленинград парфюмерия фабрикасы нигезендә «Аромат» (ААҖ) төзелә. «Аромат» фабрикасы хушбуйларны, одеколоннарны, парфюмерия җыелмаларын, сыек һәм декоратив косметика әйберләрен зур ассортиментта чыгара һәм БДБ илләренә сата.

*Журналга **Айдар Закиров** әзерләде.* ■

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Содержание. Май 2022

И останется в мире слово моё...: Кул Гали.

Историческое наследие: «Когда и каким образом волжские булгары принимали ислам?» Ф.Хузин; «Золотая Орда и суфизм». И.Миргалиев; «Дневник Миркасима Усманова».

Татарский мир: «Мы кто или Размышления об одной книге». И.Тагиров; «Фарит Мухамметшин: «Самое главное – сохранить в себе человека!»; «Фарит Бикчантаев: «Сегодня театр существует, а завтра может стать историей».

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов; «Наш наставник Исхак хазрат Лутфуллин». И.Зиганшин, З.Мингалиев; «Ислам. Религиозный словарь»; «Хадисы пророка Мухаммеда (с.г.в.)». А.Рахими; «Уроки религии». С.Бикбулат.

Литературное наследие: «Религиозная литература в духовной жизни». Р.Исламов; «Произведение «Тәрҗемәи хәлем» («Автобиография») нашего соотечественника-эмигранта». Х.Миннегулов; «Мгновение». М.Галиев.

В глубинах памяти: «Решение литературных и художественных деятелей». Л.Лерон; «В памяти, до сих пор в памяти!»

Художественное наследие: «Наша благородная певица». А.Хакимова; «Вспоминая друзей, оставивших след в истории...» Н.Каримова.

Природное наследие: «Черемуха».

Алхәбәр:

Колынчакларның нәсел дәвамчысы Александр Куприн үзенең эш бүлмәсендә. Гатчина, 1912-1913 нче еллар
(«Морза Колынчакларның утарында». Ренат Абянов, Марат Сәфәров)

Болгар ядкярләре — 1827 елда

Рәсемнәрне «Архитектурные чертежи развалин древних Болгар. Сняты с натуры в 1827 г. архитектором А.Шмидтом» (1832 ел) исемле китаптан Рәйсә Шәрәфиева тәкъдим итте.



СӘЛАМ УЛСЫН СИҢА, БОЛГАР,
ОЛУГ ДАНЛАР КҮТӘРДЕҢ,
МӘДӘНИ ШӘҺӘР УЛДЫГЫН
ЯУРОПАГА КҮСТӘРДЕҢ*.

*Күстәрдең – күрсәттең.

Олы һәм Кече манараларның рәсемнәре «Архитектурные чертежи развалин древних Болгар. Сняты с натуры в 1827 г. архитектором А.Шмидтом» (1832 ел) исемле китаптан алынды.

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 51), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларынннан сатып алырга мөмкин.